КАЛӘМ ИЗГЕГӘ ТАРТЫР

Мәдәни Җомга

№1 (128)
2 гыйнвар
1998 ел.

5 елның июленнән
башлап чыга

Атналык гәзит

بسم الله الرحمن الرحيم

Бүгенге санда:

2 *Минтимер ШӘЙМИЕВ.* Безнең рухи, мәдәни яңарыш өлкәсендә хәл итәсе проблемалар шактый күп әле, шуңа да карамастан, без барыбыз да күзгә күренеп үзгәрәбез, хәзер инде без үз язмышыбызга үзебез хуҗа булып киләбез.

4 *Барлас КАМАЛОВ.* Татарлыгын паспортында күрсәтүдән өркеп калучылар табыла икән, хет марсиан булып теркәлсеннәр, милләтебез әтрәк-әләмнән сафланыбрак китәр.

6 *Морат СИРАЗИН.* Гасырлар буе куылып, сөрелеп, изелеп читтә яшәгән татарларга исә үстенлекләрен исбатларга икеләтә тырышырга туры килә.

14 *Мәсгудә ШӘМСЕТДИНОВА.* Безнең татар көйләре һич тә Аурупа халыкларыныкыннан ким түгел, киресенчә, үзәкләрне өзәрдәй моңы, ә кайвакыт дәртле ритмнары белән күпләрне сокландыра.



Кул тотышып Яңа еллар белән,
Үр менәрбез әле тагын да...

Президент Минтимер Шәймиевнең Татарстан халкына Яңа ел мөрәҗәгате



Кадерле ватандашлар!

Катлаулы үзгәртеп кору елларының тагын берсе тәмамлана. Кемгәдер ул уңышлы, шатлыклы ел, ә кемгәдер кыенлыклар һәм акланмаган өметләр елы булгандыр. Шәхсән аны ничек кенә бәяләмик, гомумән алганда, 1997 ел безнең өчен сәяси һәм социаль-икътисади өлкәләрдә акрынлап уңай үзгәрешләр башлану елы булды. Низаг чыккан җирләрдә кан кою туктады. Гомумән, җәмгыятьтә сәяси каршылыклар кими башлады.

Башкарылган эшләребезгә якыннан күз салсак, күчеш чорының барлык авырлыкларына да карамастан, республикабыз быел иҗади хезмәт белән яшәде дияр идем.

1997 елда Татарстанның Русия Федерациясендә, ерак һәм якын чит илләрдә абруе сизелерлек үсте. Аның икътисади һәм мәдәни элемтәләре киңәйде. Республикада милләтара татулык тагын да ныгый төште. Низагларны җайга салу юнәлешендә безнең эш-гамәлләребез дөнья күләмендә танyла.

Очрашып сөйләшүләрдән һәм сезнең язган хатларыгыздан күренгәнчә, республика дәүләт органнарының реформалар уздыру сәясәте, тулаем алганда, халкыбызның күпчелегендә хуплау таба. Без аны киләчәктә дә шулай булыр дип өметләнәбез. Сезнең теләктәшлек безнең өчен бик мөһим һәм һәрвакыт кирәк.

Быел да промышленность өлкәсендә беркадәр үсеш дәвам итте. Шунысы куанычлы, машина төзелеше тармагында да алга китеш бар. Авыл эшчәннәре безне рекордлы уңыш белән шатландырды. Халкыбыз моны бик югары бәяли һәм авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренә зур рәхмәтен белдерә.

Быел без агропромышленность комплексын тирәннән үзгәртеп кору эшен башладык. Һичшиксез, бу – авыл эшчәннәренә җирнең тулы хокуклы хуҗасы булырга бөтен мөмкинлекләрне ача.

Хөрмәтле дуслар! Татарстан бүген гаять зур төзелеш мәйданын хәтерләтә. Кама елгасы аша күпер салына, Казанда метро, Түбән Камада нефть эшкәртү заводы корыла. Республикада күпсанлы торак йортлар, мәчет һәм чиркәүләр, мәдәният, көнкүреш объектлары төзелә. Казан аэропортын реконструкцияләү дәвам итә. Быел Татарстанда 4 меңнән артык гаилә тузган торактан яңа фатирларга күчте. Шуларның өч мең ике йөзе – казанлылар. Тагын бер тарихи мәсьәләнең уңай хәл ителүен хәбәр итәсе килә – Кремльне һәм башкалабызның үзәген яңартып кору эшләре югары темплар белән дәвам итә.

Район үзәкләре, авыллар күзгә күренеп үзгәрә. Юллар, яңа мәктәпләр, йортлар салына. Аларга махсус программа нигезендә авыл кешеләренең хыялында гына йөргән табигый газ кертелә.

Югары һәм махсус урта белем бирү, сәламәтлек саклау, фән, мәдәният һәм спорт өлкәсендә дә күп кенә яңалыклар барлыкка килде. Халыкның кереме аз булган катлауларына социаль ярдәм итү сәясәте дәвам иттерелде. Минималь хезмәт хакы яшәү минимумына тикле күтәрелде. Ел ахырына без бюджет тармакларында эшләүчеләргә, пенсионерларга бурычыбызны тулысынча түләп бетердек.

Хөрмәтле ватандашлар!

Башкарылган эшләребез никадәр мөһим булмасын, безне тагын да зуррак, катлаулырак бурычлар көтә. Хәрби заводларда, җиңел промышленность тармагына караган күп кенә предприятиеләрдә хәлнең читенлеге, анда хезмәт хакын вакытында түли алмау мәсьәләләре безне нык борчый. Сугыш һәм хезмәт ветераннары мәнфәгатьләре өчен башкарасы эшләребез дә байтак әле.

Предприятиеләрне үзгәртеп коруны тизләтү, бюджетны тиешенчә үтәү, инвестиция, бизнес процессларын активлаштырыр өчен уңай шартлар тудыру – киләсе елда да безнең төп бурычыбыз булып кала. Болар барысы да икътисадтагы киеренкелекне бетерүгә ярдәм итәргә тиеш.

Хөрмәтле ватандашлар! Безнең рухи, мәдәни яңарыш өлкәсендә хәл итәсе проблемалар шактый күп әле. Шуңа да карамастан, без барыбыз да күзгә күренеп үзгәрәбез. Хәзер инде без үз язмышыбызга үзебез хуҗа булып киләбез. Җәмгыятьтәге тирән үзгәрешләрнең һәрберебезгә тәэсире зур. Кеше хокукын чикләгән киртәләр җимерелә. Һәм без һәр кешенең сәяси азатлык белән бергәттән икътисади иреккә ирешүе өчен барлык мөмкинлекләрне булдырырга тиешбез.

Хөрмәтле дуслар! Дәүләт Советы, Министрлар Кабинеты исеменнән һәм шәхсән үз исемемнән сезне ихлас күңелдән Яңа ел белән котлыйм! Сезгә бәхет, исәнлек-саулык, иминлек һәм яңа шатлыклар телим!

Яңа ел белән сезне, кадерле ватандашлар!

31 декабрь, 1997 ел.

Барлас **КАМАЛОВ**

Яңа елда да салават күпере балкыр

1997 ел белән хушлашабыз. Ул мәңгегә тарих чоңгылына чума. Галәм хисапчысы, әнә, счетта тагын бер төймәне сул якка тартты. Әмма ике атна буена, искечә Яңа ел җиткәнче, бизәүле купшы чыршылардан аерыласыбыз килмәс әле.

Яңа 1998 ел планета аренасына аяк баса.

Саубуллашу һәрчак моңсу. Каршылау һәрвакыт күңелле. Без сагыш аралаш куаныч кичерәбез. Сөенүләребез Яңа елны бәйрәм итүдән генә түгел, үтеп киткән елда кылган игелекле гамәлләребез һәм алар китергән казанышлар өчен дә. Мин, татар язучысы, болай дигәндә, һәммәсеннән дә әүвәл, туган республикам Татарстандагы мәгълүм алгарышны күз уңында тотам.

Соңгы дистә елда хәлләр чибәрдән булмады. Матди кыйммәтләр җитештерү кими барды, гөрләп эшләгән предприятиеләрнең тыны кысылды, гүя аларга астма чире йокты да буылу өянәкләре гадәти манзарага әверелде. Кайбер предприятиеләр туктап ук калдылар, ябылдылар. Эшсезлек дигән шыксыз күренеш җәмәгатьчелекне тетрәндерерлек кимәлгә җитте. Тискәре күренешләр ишәйде. Мәчет-мәдрәсәләр саны күбәя барса да, әхлаксызлык кимеми.

Туксан җиденче ел да яшәешебезнең агониягә йөз тоткан халәтен тылсымлы таяк селтәп дәррәү үзгәртә алмады. Шулай да җитештерү өлкәсендә ташның таудан тәгәрәве туктатылды. Алай гына да түгел, уңай якка кечкенә генә булса да адымнар ясалды.

Бүген дә республика халык хуҗалыгында хәлләр ал да гөл булудан бик ерак тора. Әмма өмет туды, өмет бар, өмет яшәтә.

Белеп яшибез: предприятиеләргә капитал урнаштыру – инвестицияләр кризисы күз алдында, җитештерелгән кадәр продукцияне урнаштыру кризисы да факт, бурычларны түләүдә кризис ап-ачык, сәламәтлек саклау, мәгариф һәм фән ике аяклап аксый, эшсезлек бәгырьне иги, милләтара чәбәләнүләр аркасында килеп туган миграция дә хафага сала. Русиядә дә, элек союздаш республикалар булган төбәкләрдә дә бәлага тарыганнар күпме?! Аларның җан өшүдән иңрәүләре Татарстанга да килеп җитә.

Хәлләрен бик аңлыйбыз, мәгәр ихластан теләктәшлек итүдән әллә ни узарлык мөмкинлегебез күп түгел. Үз көнебезне күрми дә чарабыз юк бит әле. Дөрес, чичән туганнарга матди булышлык та күрсәтеп бактык. Аның өчен таулар төбәгендәге кан кардәшләребезнең рәхмәтен ишеттек.

Үткән елгы олы мактанычыбыз – Татарстан Республикасының авыл хуҗалыгында казанган уңышлары. Кыр батырлары – механизатор-игенчеләр һәм белгечләр 1997 елда фидакярлек пьедесталына менделәр. Гектарыннан – 35-45-әр, хәтта 50 центнердан артык уңыш җыеп алган хуҗалыкларны могҗиза тудыручылар дими ни дисең?! Татарстан тарихында беренче тапкыр буларак, ашлыкның тулай җыемы 6 миллион 300 мең тоннага җитте. Дәүләткә мул сатарга да, яхшы сыйфатлы орлык салырга да, колхоз-совхоз эшчәннәренең үзләренә кирәгенчә бирергә дә, терлекләрне тук кышлатырга да, страхование фондлары булдырырга да чөмәкәй-түбәләмә җитәчәк хәзинә бу!

Яңа гына озаткан елда халык интеллигенциясе дә – һәркем үз өлкәсендә – матур эшләр башкарды. Яшь буынга белем һәм тәрбия бирүдә, халыкның сәламәтлеген-саулыгын саклауда, инженерлык өлкәсендә, икътисадта, фәндә, сәнгатьтә, мәдәниятта, спортта алга китеш бәхәссез булды.

Язучылар да кул кушырып утырмадылар. Аларның иң зур күпчелеге, гомумән, каләм тибрәтми тора алмый. Язмый яшәү әдип өчен тормыштан китү белән бер. Иҗади хәрәкәттә, – иҗади бәрәкәт!

Ә басылып чыккан китаплар күп булдымы соң? Әлеге сорауга җавап биргәндә күкрәк сугар җай юк. Бик бәхетле авторлар гына укучыларына рухи сый бирә алдылар. "Тормыш җаен белеп җиткермәгән" каләм осталары кульязмаларын кочаклап утырдылар һәм тагын бик озак утырырлар әле. Күпме гомер итеп тә шомара алмаган язучының әле үлмәгәнлеген, исән икәнлеген әдәбият сөючеләргә хәбәр итүнең юлы бер генә: ул республикабызда чыгып килә торган гәзитләр һәм журналларда басылырга, радио һәм телевидение аша чыгыш ясарга әрсезләнү. Рәхмәт матбугат органнары җитәкчеләренә, радио-телевидение башлыкларына, алар каләм осталарына хәерхаһ позициядә.

Янә ассызыклыйк: кәгазь кытлыгы дигәнебез – асылда сыныкка сылтау ул. Дикъкать иткәнегез бардыр, урыс телендә түләүсез таратыла торган күпме гәзит чыга? Аларга кәгазьне бүтән планетадан җибәрәләрме соң әллә?

Моны зар түгү, еламсырау, мескенләнү дип аңлау кирәкмәс, чынбарлыкка иннек-кершән якмый, хушбуй сипми генә әйтү буларак кабул иткән хәерле.

Гомер агышында канатландырырлык куанычлар да, сыкрап-сыктап яшәрлек җитешмәгәнлекләр дә була тора. Шуның өчен дә мәгыйшәт инде ул. Күпләгән вакыйга, күренеш, фактлар өеменнән бик югары баш калкытып торган биниһая зур әһәмиятле вакыйганы читләтеп узып булмый. Ул – Икенче Бөтендөнья татар конгрессы.

1997 елның 28 августында ачылган бу конгресска дөньяның кеше яши торган барлык кыйтгаларыннан 80 ил вәкилләре – 459 делегат сайланган иде. Русия хөкүмәтенең рәсми вәкиле булып вице-премьер Рамазан Абдулатыйпов килде.

30 августта конгресс делегатлары һәм кунаклары Татарстан Республикасының суверенлык турында Декларация игълан итүнең 7 еллыгын бәйрәм итүдә катнаштылар. Гаять тирән мәгънәгә ия иде бу күренеш.

Мин дә, дулкынлануымнан канатланып китеп, көндәлегемә болай язганмын:

"Бәйрәм ит, газиз халкым татар! Сират кичкән, күпме какканны вә сукканны кичергән татар! Адаштыргыч буранга да, өермәле давылга да, гөҗләп яуган бозлы яңгырга да бирешмәгән татар!
Дию пәриләре корган киртәләрне дә җиңеп, алга барырга кодрәтеңнән килгән татар!
Планетаның гомере күпме булса, шул тикле яшәргә тиешле татар!"

(Ахыры 4 нче биттә).

Без агышта юлдарыстан көчлебез,
Без тынычта аттан артык эшлибез...
Г. Тукай

ВАКЫЙГАЛАР ХӘБӘРЛӘР ЯҢАЛЫКЛАР

Җидегән 5 6 7 1 2 3 4

Мөнәсәбәт

Мәрхәмәтле бул, Юлбарыс елы!..

Яңа елга аяк басканда адәм баласына яңа омтылышларга ымсыну, матур уй-хыялларга бирелү, елны изге, саф теләкләр белән башлау хас. Ни генә булмасын, һәр Яңа ел кешелек дөньясына илаһи аклык-пакьлек алып килә. 1998 елга кергәндә дә без ялгыз калмыйча, шушы әкияти бәйрәмне бергә-бергә, күмәкләшеп уткәрсәк иде. Чөнки бер елның икенчесе белән алмашыну чорын дуслык ае дип йөртәләр. Аннары Юлбарыс елы да, әлеге кодрәтле җанварның холык-фигыле дә кешеләрдән бергәлекне таләп итә шикелле. Кыскасы, һәр изге эштә бердәмлек кирәк.

Әлгәрләребез искәртүенчә, беренче чиратта, Юлбарыс елында гаилә ныклыгы, түбәнең, диварларның ышанычлы нигездә булуы сорала. Шуның өстенә, һәр коллективның билгеләнгән максатка ирешү өчен тупланганлыгы, бердәмлеге кирәк. Илнең киләчәген хәл итә торган сыйфатлар да бердәмлеккә, эш сөючәнлеккә, бер-береңә таяныч, ышанычлы дус булуга кайтып кала бит. Табигать китерә торган бәла-казаларга һәм кешеләр үзләре уйлап тапкан "техник казанышлар"ның афәтмихнәтләренә бары тик бердәм рәвештә иңне-иңгә куеп кына каршы торырга мөмкин.

Иң мөһиме, быелгы ел изге Рамазан аеннан – өһле исламның уразага керүеннән, гөнаһ-харам гамәлләрдән тыелып, чистарыну-тазарынудан, күңелгә иман нуры сеңдерүдән, савап җыюдан башланып китә.

Юлбарыс ничек кенә кешеләрне сынарга тырышып караса да, Алла боерса, изгелектән башланган елны имин генә тәгәлләрбез, дөньябызны аз гына булса да төзекләндереп, янә: "Исәнме, 1999 ел!" – диярбез. Ә хәзергә: "Юлбарыс елы, мәрхәмәтле бул безгә, көчең һәм зирәклегең белән ватандашлар тормышына аз гына булса да җиңеллек китер!" дип, Яңа елның ак-пакь кары өстеннән атлап үтәсе килә.

Сәрмәдия СӨЛӘЙМАН.

Казан консерваториясе җиңүче

"Культура" гәзите узган елда Русиядәге музыка югары уку йортлары арасында үткәрелгән бәйгедә Казан консерваториясе иң яхшылардан, дип язып чыкты. Җиңүчене махсус бүләк көтә. Телевидениенең 5 нче каналы исә уку йорты турында фильм төшерергә әзерләнә.

Мәскәүдәге рәсми очрашулар

Татарстан Президенты М.Шәймиев Федерация Советының 27 нче утырышы эшендә катнашты. Төньяк Кавказ республикалары белән, аерым алганда, Чичән Республикасы Ичкерия белән үзара мөнәсәбәтләр турындагы мәсьәләне тикшерү барышында М.Шәймиев, анда хәл чынлап та бик җитди, дип күрсәтте.

М.Шәймиев Русиянең "Газпром" компаниясе җитәкчесе Р.Вяхирев белән очрашты һәм икътисади хезмәттәшлек мәсьәләләрен тикшерде.

М.Шәймиев "түгәрәк өстәл" утырышы эшендә катнашты. Утырыш Кремльдә Русия Президенты Б.Ельцин рәислегендә барды. Дәүләт башлыгы "түгәрәк өстәл" утырышын ачканда чыгыш ясады һәм, илдә җир базарының киләчәге Җир кодексының нинди булуына бәйле, дип күрсәтте.

"Түгәрәк өстәл" утырышында катнашучылар М.Шәймиевнең республикабызда аграр сәясәт һәм Татарстанда әзерләнә торган Җир кодексы турындагы чыгышын зур кызыксыну белән тыңладылар.

Шул ук көнне М.Шәймиев Машина төзүчеләр халыкара берлеге президенты И.Силаев белән әңгәмә үткәрде.

Милләттәшебезнең Кытайга бүләге

Мәскәүдә Кытай Халык Республикасы илчелегендә КХР Рәисе Цзян Цзэминь портретын шушы ил вәкилләренә тапшыру тантанасы булды. Дәүләт җитәкчесенең әлеге портретын милләттәшебез М.Саттаров эшләгән. Шунысын әйтеп үтәргә кирәк, бу рәссамның портрет һәм пейзажлары Русиядә, шулай ук ГФР, Финляндия, Швеция һ.б. илләрдә оештырылган экспозицияләрдә күрсәтелде.

Тамәлләре дә үзебезчә

Сембер. Иске Кулаткы районында яшәүчеләрнең 98 проценты – татарлар. Бирелдә элегрәк заманча җитештерү ширкәтләре бөтенләй юк иде диярлек. Яңа җитәкчелек моңа аеруча игътибар итте. "Кулаткы" исемле шифалы су сату оештырылды. "Акташ" исемле ширкәт табигатьнең минераль байлыкларын үзләштерә башлады.

Тукай фәйләсүфләрне җыя

Габдулла Тукайның Казандагы музеенда фәлсәфә фестивале үткәрелде. Бу юлы фәлсәфәче-рәссам Фларит Зариф аның төп каһарманы булды.

Казан остасы "Галәмнең гомуми картинасы һәм Дөнья фикеренең төп эволюцияләре" дигән исем астында туплап, үзенең тиңе булмаган рәсемнәреннән торган күргәзмәсе белән гавамны шаккатырмакчы.

Монда шулай ук фәлсәфә, фән, сәнгать һәм диннең гомуми проблемалары буенча кызыклы фикер алышу узды. Фестивальдә катнашучылар Дөнья Зирәклеге Сарае – Пансофион проектын да уртага салып сөйләштеләр. Киләчәктә әлеге корылма җөмһүрият башкаласында корылыр, дигән фикердә калдылар.

Адәм баласына эш кирәк

Татарстанның статистика дәүләт комитетыннан алынган мәгълүматларга караганда, 1997 елда бездәге югары уку йортларының көндезге бүлеген барлыгы 8560 кеше тәмамлап чыккан. Шуларның нибары 4892се (57,1 проценты) эш урынына юллама алган.

Хезмәтендә язмышы чагыла

М.Горькийның Казандагы әдәби-мемориаль музеенда Чаллыда яшәп иҗат итүче рәссам Виктор Сынковның шәхси күргәзмәсе ачылды.

График-авангардчы иҗат иткән әсәрләр сәнгать алымнарының чисталыгы, эчке мәдәнилеге, сафлыкка һәм гармонияга омтылышы ягыннан гавамны үзенә тартып тора. Рәссамның натюрморт һәм пейзажларында бу аеруча ачык чагыла. Виктор Сынковның картиналарыннан шулай ук сагыш, көенеч тә сирпелә. Бусы Чаллы остасының драматик язмышыннан да килә бугай.

Ул ата-ана назы күрмичә үскән, бала чагыннан ук рәсем ясарга һәвәс булган. Балалар йортында тәрбия алып чыккач, Виктор Лениногорскидагы сәнгать училищесын тәмамлый һәм Чаллыдагы автогигантка күчеп килә.

Мәктәпләр бәйгесе

Русия Федерациясенең Мәгариф министрлыгы тарафыннан үткәрелгән Бөтенрусия конкурсында җиңеп чыгып, Татарстанның Лениногорски каласындагы 4 нче мәктәбе – "Ел мәктәбе", ә аның җитәкчесе Рафаил Ситдыйков "Ел директоры" дигән мактаулы исемгә лаек булды.

Әйткән сүз – аткан ук

Олег МОРОЗОВ,
РФ Дәүләт Думасы депутаты:

"Котылгысыз күрәзәлек белән әйтергә туры килә, 1997 елда да, элекке биш елдагыча, Русия җәмгыятенең хроник тостә сырхаулавы дәвам итте. Күзгә күренерлек уңышларга да ирешмәдек, зур тетрәнүләр дә кичермәдек. Барысы да уртача. Әйтик, ике дистә елдан соң искә төшерсәк, үтеп киткән елның тотып алырлык берәр якты вакыйгасы да булмастыр кебек. Ә, бәлки, мондый хәл аның яхшы ягыдыр да әле. Әйе, гайре табигый вакыйгалар булмады. Аллага шөкер."

("РТ").

Хезмәтенә күрә хөрмәте

Русия Федерациясе Президенты Указы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Федерация Советы Рәисе урынбасары **ЛИХАЧЕВ Василий Николаевич Жуков медале** белән бүләкләнде.

* * *

Татарстан Республикасының Казакъстандагы вәкаләтле вәкиле, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты әгъзасы **КӘРИМОВ Морат Габделхәй улы "Достык" ("Дуслык") ордены** белән бүләкләнде.

* * *

Русия Федерациясе Президенты Указы нигезендә фән өлкәсендәге уңышлары өчен тарих фәннәре докторы, Казан дәүләт университеты профессоры **БУСЫГИН Евгений Прокопьевичка;** техник фәннәр докторы, А.Туполев исемендәге Казан дәүләт техник университеты ректоры, профессор **ДЕГТЯРЕВ Геннадий Лукичка;** физика-математика фәннәре докторы, профессор, А.Туполев исемендәге Казан дәүләт техник университетының кафедра бүлеге мөдире **ПОЛЬСКИХ Юрий Ехилевичка "Русия Федерациясенең атказанган фән эшлеклесе"** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Татарстан Президенты Указы нигезендә Түбән Кама нефтехимия көллияте укытучылары: укыту эшләре буенча директор урынбасары **МОНАСТЫРСКАЯ Надежда Семеновна,** икътисад бүлеге мөдире **НУРЕТДИНОВА Эльмира Әзһәр кызы** Татарстан Республикасының **Мактау грамотасы** белән бүләкләнде.

* * *

Татарстан Президенты Указы нигезендә Түбән Кама нефтехимия көллиятенең фәнни-методик эшләре буенча директор урынбасары **МАКАРЬЕВА Зинаида Ивановнага "Татарстан Республикасының атказанган мәктәп укытучысы"** дигән мактаулы исем бирелде.

Җомгадан – җомгага

ҖӨМҺҮРИЯТ ЕЛЪЯЗМАСЫНА ҖӨМЛӘЛӘР

Татарстан Президенты М.Шәймиев катнашында Казанда Сәүдә-сәнәгать палатасында эшкуарларыбызга Русия Федерациясе дипломнарын тапшыру булды.

Республикада "Компьютерная Казань" дигән яңа гәзит чыга башлады.

Татарстан Президенты М.Шәймиев башкалабызның Азино-1 микрорайонында яңа торак йортлар белән танышты, яңа фатирларга күчүчеләр белән очрашты

Казан дәүләт университетының юридик факультеты командасы Түбән Новгородта үткән Бөтенрусия студентлары олимпиадасында җиңү яулады.

Башкалабызда "Казан бистәсе" музей-тыюлыгы гамәлгә куелды.

Казанда узган X Бөтенрусия пианистлар бәйгесендә башкалабыз консерваториясен тәмамлаган, хәзер Мәскәүдә аспирантурада укучы Р.Кудояров – икенче, З.Мостафина (Казан) һәм Т.Абрамова (Новосибирски) өченче урынга лаек булдылар, ә беренче бүләк бирелмәде.

Татарстан Фәннәр академиясенең Тарих институтында "Идел буе һәм Урал татарларында тукучылык" дигән китапны тәкъдир итү булды.

Республиканың Сәламәтлек саклау министрлыгы Министрлар Кабинеты белән берлектә "СПИД: вакцина юк, әмма аннан котылу мөмкин" дигән теманы яктыртучы язмаларга конкурс игълан итте.

Казан Кремлендә республика фән һәм халык мәгарифе, сәламәтлек саклау, авыл хуҗалыгы, промышленностьның төрле тармаклары хезмәткәрләренең зур бер төркеменә Президент кушуы буенча Татарстан вице-премьеры И.Хәйруллин дәүләт бүләкләре тапшырды.

Сәхифәбездә редакциябез журналистлары, авторларыбыз, "Татар-информ" һәм башка чыганаклар хәбәрләре файдаланылды.

Беренче биттә – **Ринат ХӘСӘНШИН коллажы.**

Яңа елда да салават күпере балкыр

(Ахыры. Башы 2нче биттә).

Сине үтермәк булып кемнәр генә ялманмады да, кемнәр генә йонлач кулын сузып карамады? Сине кимсетергә теләп, денеңнән-динеңнән биздерергә тырышып, тәре күтәреп килүчеләр сине бәкегә батырып та, утта яндырып та карадылар, иген иккән, мал-туар асраган уңдырышлы җирләреңнән кудылар, олы юлдан кырык-илле чакрымда гына торагыңны корырга рөхсәт иде, телеңә ай-балта чапмак булдылар. Кяферләрнең әфәлем төрлеләре ни тузындылар, ни ерткычландылар. Син баш имәдең, бил бөкмәдең, татарым!

Русия өстенә афәт килгәндә, сине бик кирәксенделәр, татар. Наполеонга каршы орышка да, немец фашистларына каршы сугышка да сине беренче чиратта чакырдылар. Һәм син бардың, Русия колачында гына түгел, дөнья масштабына гаярьлегеңне күрсәттең, берәүдән дә калышмавыңны һәм калышмаячагыңны яу кырында да, имин елларда да күрсәтә алдың.

Халыкның кемлеге кешеләр саны белән үлчәнмәвен дә син исбатладың, мәгърур татар!Фашистларга каршы дәһшәтле сугышта каһарманлык күрсәткән Советлар Союзы Геройлары саны ягыннан халык санына нисбәттә алганда син беренче урында бит, татар! Моннан да артык дәлил кемгә кирәгер икән?! Кадерен белмәгәнгә читкә киткән Нуриевларның, Русия Президенты йөрәгенә операция ясап, аның гомерен саклап калган Акчуриннарың бар синең. Андый кыюларны, уңганнарны тормышыбызның һәммә өлкәсендә күпләп күрсәтә алабыз. Шуңа да башыңны югары тот, милләттәшем, тик бер үк масаеп китә күрмә. Кайчак мондый йомшаклыгың да үзен сиздереп куйгалый бит. Бер үк аңышып яшик, җәмәгать!

Тулаем әйткәндә, син – Кеше, татар.

Моны мин генә әйтмим. Мин кем, мин нәрсә? Татар халкына югары бәяне дөньякүләм абруйлы дәүләт эшлеклеләре, сәясәтчеләр бирә. Мәсәләнгә мисал: Бөекбританиянең данлы шәхесе – "тимер леди" Маргарет Тэтчер "Аргументы и факты" газитенә 1996 елның августында биргән интервьюсында түбәндәгеләрне белдергән иде:

"Татары – это очень гордые люди, хотят больше независимости. Они ведь не хотят жизни без России. Они хотят свободы".

Леди хак әйтә. Татарстан Русияидән кубып, очып чыга алмый, ә азатлык, мөстәкыйльлек, яшәешенә чит куллар тыкшынмаган тормыш бик-бик кирәк аңа!

Үзенә-үзе хуҗа булып яшәү, кулаякларының чишүле булуы, үзал фикерләгәндә муен тамырына төеп торучыларның булмавы безгә халкыбызның үзаңын тагын да үстерү өчен, елдан-елга манкортлардан арына бару өчен, туган телебезне, милли әдәбиятыбызны һәм сәнгатебезне, динебезне саклап калу өчен генә түгел, тагын да үстерә, камилләштерә бару өчен зарур.

Без, татарлар, кемнәндер өстен булыйк, акыллырак булыйк дип көчәнмибез, һич юк! Без фәкать татар халкының бүтән милләт халыклары белән бер дәрәҗәдә булуын расларга телибез. Һәм раслап киләбез дә!

Әйтик, үтеп киткән елда гөлтләп күтәрелгән һәм башланып киткән елда да тиз генә телдән төшмәс бер мәсьәлә – яңа паспортлар мәсьәләсе төрле фикерләр тудыра. Сүз, башлыча, гражданлык һәм милләтне күрсәтү-күрсәтмәү тирәсендә бара.

Байтак фикерләр әйтелде. Сөземтә, һәрхәлдә, мондый булырга тиеш кебек. Милләтне ап-ачык күрсәтү кирәклеген шик астына алу бөтенләй урынсыз. Татарлыгын күрсәтүдән өркеп калучылар табыла икән, җаннары теләгәнчә яздырсыннар, хет марсиан булып теркәлсеннәр. Әтрәкәләмнең милләтеннән ыштан салып качуыннан милләтебез сафланыбрак китәр.

Гражданлыкка килгәндә, без, барыннан да әүвәл, Татарстан гражданнары.

Ике гражданлык дигән төшенчә бар. Димәк, кеше Татарстан гражданына игезәк хокук итеп Русия гражданы да булырга тели икән, Русия паспортын да алсын.

Гражданлык һәм милләтне күрсәтү мәсьәләсендә Татарстан Президенты М.Шәймиевнең фикере нигез итеп алынырдыр. Һәм ул үзе үк гражданлык турында Закон кабул итү зарурлыгын әйтте. Моны сузмаска иде.

1997 ел үтеп китте. Гомер дисбесенең янә бер төймәсен чигердек. Тормышыбыз юлында тагын бер чакрым баганасын уздык. Иске ел тәмамланмаган байтак эшләрне иңнәребезгә салып калдырды. Ел алмашынды дип кенә аларны тәгәлләми булдыра алмыйбыз.

1998 ел җитте. Хыял манарасына менеп, алдагы көннәрне күрәсе килә. Яңа елда да салават күпере күк гөмбәзен иңләр, дөньяны кочар дип ышаныйк.

Яңа ел мөбарәк булсын, мөхтәрәм милләттәшләр!

Салават күпере ешрак балкысын!

Шәхесләр һәм шәрехләр

■ Мәскәү мэры Юрий Лужков башкалардан нык аерылып торган холкы, күп вакыт кепка киеп йөрүе, спорт сөюе белән дә халык күңелен яулады. Әмма башкала мөселманнары аны Поклонная Горадагы мәчет өчен 66 млдр.сум акча биргәне өчен ихтирам итәләр.

■ Татарстан Президенты Минтимер Шәймиевнең атлар яратуы республикада яңа бер тармак – нәселле атлар үрчетүгә юл ачты. Ипподром төзелгәч, ат ярышлары еш уздырыла башлады. Спортның бу төренә игътибар республика хуҗалыкларыннан сөрелеп бетә язган эш атларына да игътибарны арттырды.

■ Финанс министры Рөстәм Миннеханов үзе Биектау районы хакимияте башлыгы чагында ук автодром төзеткән иде. Хәзер анда Татарстан, Русия беренчелегенә чемпионатлар уздырыла. Узган ел Рөстәм Миннеханов спортның шушы төре буенча Татарстан чемпионы булды. Дөрес, халык арасында "ат, машина ярышлары"н өнәмәүчеләр дә бар. Әмма ничек кенә булмасын, спортның бу ике төре дә киләчәктә үсеш алачак, Татарстанны чит илләргә танытуда зур роль уйнаячак.

■ Биектау автодромындагы ярышларның берсендә Татарстанның халык артисты Салават Фәтхетдинов машинасы капланды. Тамашачыларның тыны кысылды, кан басымнары күтәрелде. Машинаны урынына утыртып, кабина ишеген ачкач, Салават килеп чыкты. Халык, яраткан җырчысының исән-сау икәнен күргәч, иркен сулыш алды. Аның интервьюсы да истә калган. "Спорт ярышлары ярыш кына түгел, тамаша да бит әле ул. Тамашачылар аны спектакль кебек карый. Ә спектакльдә комедия дә, драма да булырга тиеш", – диде ул.

Күптән түгел Салават Чаллыда үзе исемендәге автокросс оештырды һәм аннан кергән акчаны тулысынча ятимнәргә бирде.

■ Яңа Савин районы инвалидлар җәмгыяте рәисе Нажия Баталованың күңел яктылыгы бөтен Казанга җитәрлек. Ул магнит кебек үз янына җылы сүзгә, якты йөзгә һәм матди ярдәмгә мохтаҗларны җыя. 1 группа инвалид, ике култык таягы ярдәмендә көч-хәл белән генә йөрсә дә, аның 36 еллык хезмәт стажы бар. 4-5 елда инвалидлар өчен 135 эш урыны булдырды. Инвалидларны гына түгел, сәламәт кешеләрне урамга, язмыш кочагына чыгарып ташлаган предприятие хуҗаларына менә кемнән үрнәк аласы бар.

■ Фларит Зарипов – хәрби диңгезче, рәссам һәм философ, бөтен илләр фәлсәфәсен, милләтләр менталитетын өйрәнгән һәм шуларның асылын символлар аша күрсәткән сәнгатькәр. Бер бүлмәле фатирында яшәп, эшләп иҗат итә ул. 200дән артык сәнгать әсәрләре бар. Казанда бөтендөнья Акыл Сарае төзергә хыяллана. Әмма әлегә бу хыял гына булып кала бирә...

■ Рафаэль Бәзертдинов Әзәрбәйҗаннан Казанга күчеп кайтты. Һөнәре буенча экономист. Яңа ел алдыннан өч китабы дөнья күрде. Тулы бер фәнни-тикшеренү институты эшләрдәй "Татары, тюрки – потрясатели вселенной" дигән бу хезмәтен ул... өч бүлмәле фатирын сатып, КамАЗ китап нәшриятында чыгарды.

Күрәсезме, дуслар, тирәбездә күпме яхшы кешеләр яши икән. Борыннарны салындырмыйк, соңгы елларда начарлык, ялган, алдау, талау белән еш очрашкан күңелләр күтәрелеп китсен әле. Уйлап карасаң, үзебез үк пычраткан бу михнәтле дөньяны агартырга һәрберебез күпмедер өлеш кертә ала бит. Яңа елда һәркемгә күңел аклыгы, сәламәтлек һәм бәхет телибез. Мәрхәмәтле булыйк, бер-беребезгә ярдәм итешеп яшик!

Яңа елның холкы

Шәрекъ календаре буенча 1998 ел – Юлбарыс елы. Бу елда туганнар – тирән уйланучан, күңел ачуларга, хисләргә бирелүчән, изге теләкле, әмма еш кына ярсып китүчән кешеләр. Алар ихтирам казаналар, ләкин өлкәннәр, җитәкчеләр белән еш бәхәскә керәләр. Бу кешеләр тәвәккәллек күрсәтә алмыйлар, ашыгалар һәм дөрес хәл иткән мәсьәләләре аз була. Бик шикләнеп карыйлар, эгоистлык та бар. Әмма нигездә алар кыю, көчле ихтыярлы кешеләр.

Юлбарыс елында туган кешеләр ат, аждаһа, эт елында туганнар белән дус яки гомер юлдашы буларак тәңгәл киләләр.

Юлбарыслар күсе, эш үгезе, йорт куяны, юлбарыс, сарык, әтәч, кабан дуңгызы елында туганнар белән азмы-күпме туры киләләр.

Әмма елан, маймыл елында туганнар белән юлбарыслар капма-каршы кешеләр, бер-берсенә бары тик бәхетсезлек кенә китерәләр.

Дуңгызлар кими башлады...

Узган елның 11 аенда республикада мөгезле эре терлек саны 63,5 мең башка кимеде. Татарстан статистика дәүләт комитетыннан алынган мәгълүматларга караганда, шулай ук дуңгызлар саны – 36,7 (6 процентка), сарык – 56,6 (28 процентка), кош-корт 1190,2 мең башка кимегән.

Әмма шәһәр халкы өчен шикләнер нәрсә юк. Терлек-туар киму мәгълүм дәрәҗәдә аның продуктлылыгын күтәрү бәрабәренә компенсацияләнә. Узган елның 1 декабренә, бер терлеккә күчереп исәпләгәндә, һәр сыердан сауган сөт 215 килограммга (8 процентка) артты. Симертүдәге маллар, 1996 елның гыйнвар-ноябре белән чагыштырганда, күзгә күренеп көрәя. Артым алу исә 5 процентка күбрәк.

Узган елның 11 аенда республика хуҗалыкларында барлыгы 42,2 мең баш мөгезле эре терлек, 59,7 мең дуңгыз, 19,7 мең сарык үлде. Бу саннар да, алдагы елның шул чорындагыга караганда, 16, 13 һәм 30 процентка кимрәк.

Түләмәсәң – яндыралар...

Билгесез бәндәләр Казанның академик Павлов урамындагы коммерция киоскы сатучысы өстенә бензин сибеп ут төртәләр...

Башкаланың 7 нче янгын сүндерү отрядыннан алынган мәгълүматларга караганда, киоск янына әлеге хәлгә кадәр берничә егет-җилән килеп туктый һәм сатучыдан акча даулый башлый. Тегесе, әлбәттә инде, күнмәгән. Шуннан соң бу вәхши адәм актыклары китеп барган. Вәләкин ярты сәгать үткәч, тагын шушында килеп баса болар. Кулларындагы пластик шешәдә – бензин. Нәни тәрәзә аша бичара сатучы өстенә шуны сибәләр һәм эчкә ут ыргыталар. Бәлагә тарыган тәнгә сатучы тәненең 60 проценты нык пешкән хәлдә республика клиник хастаханәсенә озатыла.



Виктор ФЕДОРОВ рәсеме.

Узган ел Татарстан моңарчы күрелмәгән уңыш җыеп алды. 6 миллион 200 мең тонна! Бу республикада 1991-1995 еллардагы күрсәткечтән 62 процентка күбрәк. 1996 елда республика буенча 28,2 центнер уңыш алынса, 1997 елда бу сан 37 центнерга җитте, ягъни җан башына 1,6 тоннадан артык дигән сүз. Бөртеклеләрне иң күп җыючы районнарны саный китсәң дә никадәр урын алыр иде. Арча, Балтач, Азнакай, Биектау, Әтнә районнары бөртекле культураларның һәр гектарының 50-55әр, Буа, Теләче, Октябрь, Питрәч, Кукмара, Апас, Ютазы, Алексеевски, Сарман районнары 47-40ар центнер уңыш җыеп алдылар. Татарстан игенчеләренең бу җиңүенә Русия дә күз йомып кала алмады. Президент Борис Ельцин егермедән артык кешегә хөкүмәт бүләкләре өзерләде. Тау-тау алтын көшелләр үстереп биргән игенчеләр гадиләр һәм беекләр. Юлбарыс диагностикасын үткәрдек, минераль ашламалар керттек, дип җавап бирергә дә булыр иде, әлбәттә, болар иң мөһим чаралар, игенченең әлифбасы. Әмма алардан да мөһимрәге – җирне яратырга, һәр карыш җирне игенченең җан җылысы белән сугарырга кирәк. Шушы мәхәббәткә ул мул уңыш белән җавап бирә. Безнең җирне олы мәхәббәт белән яратучы кешеләребез күп. Зөфәр Мөхәммәтдинов 1734 тонна ашлык суктырып беренче урынга чыкты. Гөлниса белән Рәфкать Хәбибуллиннар үзләре кебек тырыш, намуслы, эшчән 5 бала тәрбияләп үстерәләр. Гаиләләре бөтен авылга бер тату гаилә. Рәфкать тракторчы, Гөлниса сыер савучы булып эшли. Гөлбинур белән Зарифҗан Калимуллиннар да нинди эшкә тотынсалар, шуны булдыралар. Тимерче Нәгыйм абзый Сәфәров көнне төнгә ялгап эшли. Илсур Гарипов – укытучы, ә урак өстендә менә дигән комбайнчы. Төлгать Мөхәммәтҗанов, Радик Сафиуллин, Җәгъфәр Ибәтуллиннар, Мәгыйз Сәфәров, бертуган Данил, Равил һәм Рамил Корбановлар һәм тагын бик күпләр тырышлыгы белән өелде ул сары алтын таулары.

– Бер савымчы әйткән ди бит: һәр сыердан бшар мең литр да саварга мөмкин, ул чагында тач су була бит ул, дип. Сиксән икешәр центнер ашлык алу өчен күпме минераль ашлама керттегез инде? Икмәгегез тач нитрат түгелме?

– Әйтеп та карыйсың соң, Юлбарыс

"Акчишмә"нең йөзе ак

Татарстанда иң күп ашлык үстергән күмәк хуҗалыкка юл тотты. Ул Арча районының "Северный" совхозыннан моннан 9 ел элек аерылган "Акчишмә" күмәк хуҗалыгы булып чыкты. Хуҗалык рәисе НӘФЫЙК ЛОТФУЛЛИН бик эшчән гаиләдә үскән, буразнадан чыккан авыл кешесе. Җирне, терлекләрне бик ярата. Һәр эштә үзе башлап йөри, тынгысыз, хезмәтнең рәтен, төмен белә, башкалардан да шуны таләп итә. Шул сыйфатлары һәм игелекле, мәрхәмәтле булуы белән халык мәхәббәтен яулаган да.

– Нәфыйк дус, кая урнаштырып бетердегез бу кадәр ашлыкны? – дип, Юлбарыс теленә килгән беренче сорауны бирде.

– Һи, булсын гына, урынын табабыз аның! Һәр гектардан 54әр центнер ашлыкны дәүләткә тапшырдык. Чәчүлек орлыгына дигәнен аерым урнаштырдык. Пенсионерларга өчәр центнер исәбеннән бушлай өләштек, үзебезнең эшчеләргә килосын 550шәр сумга сатып бирдек, терлекләргә җитәрлек фураж өзерләдек.

– Моннан 20 ел элек "Коммунизмга" гәзитендәге сводкаларны өйрәндем. 1977 елда "Искра" колхозы бөртеклеләрнең һәр гектарыннан 23, "Игенче" – 20,2, "Известия" – 17,3әр центнер уңыш җыеп алган. "Северный" совхозы 2 еллык халык хуҗалыгы планнарын үтәү буенча 37 хуҗалык арасында иң соңгы урында. Ә 1997 елда "Акчишмә" һәр гектардан 82,4әр центнер уңыш җыеп алды. Шул ук җир, ә аерма – җир белен күк арасы. Әллә быел күрше Мари Иле буразналарындагы ашлыклар да сезгә күчеп беттеме? Бу кадәр уңышка ничек ирештегез, диюем.

– Соравыңа, Юлбарыс туган, алдынгы технология кулланып иң яхшы сортлы культуралар чәчтек, туфракка анализ ясап үсемлекләр

әфәнде. Мактаганда тешләреңне күрсәтмәсәң дә була бит инде! Буа районы хакимияте башлыгы Габделхәй Хәйруллов бервакыт, һәр гектардан 50шәр центнер уңыш алу өчен гектарга файдалы матдәсе булган 100 кг минераль ашлама гына җитми икән, тагын да күтәрү өчен кыюлык җитмәде, дигән иде. Әйе, ашламалар белән сак эш итәргә кирәк. Син әйтмешли, "тач нитрат" булуы бар. Ашламаның бер тоннасы бик кыйммәт тора, һәм бездә аның кадәр ашлама куллану мөмкинлеге дә чамалы. Шуннан үзең уйлап кара инде.

– Белоруссия президенты Александр Лукашенко бөтен республикага данлыклы бер совхоз директорын эшеннән куды. Сәбәбе – директор абзый үстергән уңышларын күпертебрәк күрсәткән икән. Ничек уйлыйсың, Нәфыйк дус: республика хуҗалыклары дәүләткә тапшырган икмәк ничә елга "нз" була алыр икән?

– Ну, хитри да инде син! Тел төбеңдә "приписка" ясамадыгызмы, дәүләт амбарларына тапшырган икмәгегез өреп кабартылган куык кебек шартламасмы, ачлык килсә, халык ачка кырылмасмы, дигән шик ята бит! Барлык хуҗалыклар өчен җавап бирә алмыйм. Заманалар авыр, еллар арык булган очракта да 1921 ел фаҗигасе кабатланмас дип уйлыйм. Һәрхәлдә "Акчишмә"нең үз икмәге үзенә җитәрлек.

– Юлбарыс елында бары уңар,һич югында, тары уңар, ди халык. Минем ел да сезгә муллык алып килсен.

Арча районы "Акчишмә" күмәк хуҗалыгы рәисе Нәфыйк Лотфуллин.
М.ШАКИРҖАНОВ фотосы

Бер сорауга – бер җавап

– 1997 ел шәхсән үз тормышыгызда нинди сөенеч-шатлыклар, борчу-мәшәкатьләр, нинди уңышлар белән уздыгыз? Яңа елга нинди өметләр белән керәсез? Илдә көндә нинди уңай үзгәрешләр көтәсез?

Ислам ӘХМӘТҖАНОВ, Татарстан мәгълүмат һәм матбугат министры:

– Бусагасында басып торган туксан сигезенче елда да барча басмаларны саклап калып, сүз кебек ифрат куәтле коралны Татарстаныбызның абруен күтәрү, анда яшәгән халыкларны берләштерү өчен, игелекле максатта гына файдаланырга иде. Чөнки сүз белән кешеләрне берләштерергә дә, сүз белән бүрелештерергә дә мөмкин. Сөйдергән дә, биздергән дә сүз, дип сөйли бит халкыбыз. Иҗат басуының – болай дигәндә гәзит-журналларны күздә тотам – башаклары мул булсын. Кайчагында бәһасе сукыр бер тиеннән узмаган вак нәрсәләр хакында бәхәсләшеп китәбез ләбаса. Беткәнмени халкыбызның күңелен кузгатырдай җитди мәсьәләләр?! Соңгы вакытларда татар матбугатында тешле-саллы язмалар сирәк күренә дигәнрәк фикерләр ишетелгәли. Килешмим! Агыйделнең аръягында бер энәгә бер сыер диләрме әле?! Күршенеке һәрчак калкурак күренде. Безнең татар телендә нәшер ителә торган басмаларыбыздагы язмаларны урыс теленә тәрҗемә кылсак, күбебезнең "Кара әле, кара, шәп нәрсә бит бу!" рәвешендә тел шартлатачагына иманым камил.

Яңа елда КИТАП сүзе сүрелмәсен. Шөкер, рухи якка әзме-күпме караш үзгәрә башлады. Уңайга таба. Әмма җитәрлек түгел әле бу. Дөрес, моның тамырлары тирәндә, бик тирәндә ята. Ахыр чиктә ул икътисадтагы кыенлыклар, чишелергә тиешле булып та чишелми яткан төеннәр белән бәйле.

Яңа 1998 ел халыкның өметен сындырмасын иде. Тормыш итүләре авыр дип ничек кенә сызлансак та, барыбер уңай якка үзгәрешләр, алга китеш бар. "Мәдәни җомга"ны укучыларга җан тынычлыгы, игелек, ипиле ел телим! Теләкләрегез тормышка ашсын!

Шәхси тормыштагы сөенеч-шатлыклар, борчу-мәшәкатьләр турында язып тормадым. Эшлим... Борчылам... Кайчагында сөенәм...

Ул безне "Мәдәни җомга"лы итте

Утыз елга якын гомеремне Апас торак төзү һәм ремонтлау участогында эшләп үткәрдем. Хәзер пенсиядәмен. Әмма үземне коллективтан читтә дип уйламыйм. Онытмыйлар безне, җыеннарга, бәйрәмнәргә чакырып торалар. Участок начальнигы Әнәс Нургалиев бик тә кешелекле, мәрхәмәтле зат.

Ә бүген кулыма каләм алуыма участок начальнигының тагын бер игелеге сәбәп булды. Коллективта 25 пенсионер исәпләнә, миллион сумнар тотып, һәркайсыбызга гәзит яздыра. Мин үзем чуаш милләтеннән, татар телен дә туган итәм. Менә ике ел инде участок бүләк иткән "Мәдәни җомга"ны сөенеп укыйм. Әйбәт гәзит, эчтәлеге бай. Миннән күршеләр дә алып тора. Анда язылганнар турында милләттәшләремә дә сөйлим.

Пенсионерларның 25есе дә "Мәдәни җомга"ны яратып укый. Бу хакта Әнәс Нургалиевнең үзенә дә сөйләдек һәм 1998 елга тагын шул гәзиткә яздыруын сорадык. Рәхмәт үзенә, үтенечебезне канәгатьләндерде. Гыйнвардан "Мәдәни җомга" тагын килә.

Предприятиенең төрле чагы булды, билгеле. Кая матбугатка яздыру, очын-очка ялгый алмаган чаклар да бар иде. Чөнки җитәкчеләрнең дә төрлесе булды. Хәзер, җитәкче булып Ә.Нургалиев килгәч, тәртип сизелә. Кирпечне дә ыгы-зыгысыз җитештерәләр, сыйфаты да канәгатьләндерә. Элек сезонлы эшчеләрне райсовет карары белән колхозлардан куалап китерәләр, алар сезон буе эленке-салынкы йөриләр иде. Хәзер заводны үзләре эзләп киләләр, чөнки Ә.Нургалиев хезмәт хакын вакытында бирергә тырыша. Миллионлаган данә кирпеч сугалар. Участок алардан үз эшчеләренә һәм сату өчен фатирлар төзи.

Предприятие эшчеләре сәер хәлләр турында сөйлиләр. Участокка районнан бензин, солярка, ташкүмер бирмиләр икән. Күрше районнардан эзләргә мәҗбүрләр. Нигә шулай, дибез. Участок районга, халыкка эшли ич инде. Булыш, ул гади халыкка күбрәк тә ярдәм итәр. Үткән көздәге очрашуыбызда Әнәс Нургалиев һәр эшчегә 30 миллион сумлык тауар җитештерелүе турында сөйләде. Бергә җыйсаң, миллиардлар ич ул. Күктән төшми, хезмәт куеп алырга кирәк.

Көнкүрешләре дә яхшыра. Гомер булмаганны, Әнәс Нургалиев ашханә ачып җибәргән, әбәт өчен мең сум гына түлисең, зур чыгымын предприятие үзе күтәрә. Теплица төзеп куйганнар – үз яшелчәләре була. Шофер халкы гаражларның киңәйтелүенә сөенә. Яңа фатирларга күчкән эшчеләрнең дә шатлыгы күп. Ә безнең куаныч барыннан да зур: кулыбызда тагын "Мәдәни җомга", рәхәтләнеп, Әнәс Нургалиевкә рәхмәтләр әйтеп укыйбыз аны. Бу рәхмәтебезне аңа яраткан гәзитебез аша да җиткерәсе иде.

Анна КОМИССАРОВА,
хезмәт ветераны.
Апас районы.

Бер сорауга – бер җавап

Венера ГАНИЕВА, Татарстанның һәм Русиянең халык артисты, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе:

– Узган ел өч зур вакыйга белән хәтердә калды: минем тыйнак хезмәтемне Тукай бүләгенә лаек дип таптылар. Дания, Голландиянең байтак шәһәрләрендә Пуччининың "Богема" операсында җырладым. 17 спектакль куйдык, һәм Казан җырчыларын, шул исәптән мине дә, бик яратып калдылар. Өченче шатлыгым – энемнең улы Булат туды һәм ул сабый иң зур, күтелгән бүләк булды.

Яңа ел минем өчен иң күркәм, сихри бәйрәм. Салкын, кар-бураннар өшетсә дә, яңа яуган ак кар кешеләр күңеленә сафлык, пакьлек алып килә. Мин аңа сабыйларча шатланам. Җырчының иң зур хыялы нәрсә? Әлбәттә, җырланмаган иң матур җырлар, яңа партияләр башкарасым килә. Минем дә шундый хыялым бар. Доницеттиның "Лючия Ди Ляммермур" операсында төп рольне итальянча башкарасым килә.

Яңа ел искесеннән бәрәкәтлерәк, мәрхәмәтлерәк булсын. "Мәдәни җомга" укучыларына бәхет, сәламәтлек телим!



Рашат САФИН, Татар иҗтимагый үзәге рәистәше:

– Узган елның төп вакыйгасы – Бөтендөнья татарларының икенче конгрессы дип исәплим, һәм ул халык хәтеренә шулай кереп калыр да. Татар милли хәрәкәте сүлпәнләнгән бер чорда конгресс бик зур импульс бирде. Анда без керткән тәкъдимнәрнең барысы да диярлек кабул ителде.

Яңа елга зур өметләр баглыйм. Халкыбыз дәүләтчелекне торгызу юлына басты инде, әмма аны гамәлгә ашыру өчен һәркем үзеннән хәл кадәренчә өлеш кертергә бурычлы. Сәясәтчеләрнең күпчелегенә геосәясәтне, ягъни дөньяви үсеш тенденцияләрен истә тотып эшләү җитми. Әмма иң борчыганы – милли хәрәкәттәге таркаулык. Рәсми органнар, иҗтимагый-сәяси һәм дини оешмалар киңәшләшеп эшләми, бергәләп хәрәкәт итми. Яңа елда шушы бергәлеккә омтылышта яңа адымнар көтәм.

Җәһәт әңгәмә

Зимагурлар токымы

Үгез елы тәмамланугa, эстафетаны Юлбарыс алды. Гәзитнең беренче санына җәһәт әңгәмә аласын исенә төшереп, алга ыргылды. Кемнәр белән әңгәмә корасын уйлап баш ватмады: әлбәттә, үзенә тиңнәр белән генә сөйләшәчәк. Менә ул Биектау районында урнашкан Коркачык станциясенә килеп җитте. Гайдар урамын тиз эзләп тапты. Калын бетон диварлар эчендә икән ул урам. Мондагы плакатлар, өндәмәләр!

"Капиталистик хезмәт алдынгыларына дан!"

"Жить надо так, чтобы помнили и сволочи. Ф.Раневская".

"Руководитель – диктатор во время работы.В.И.Ленин".

"Татарстан экспериментал ь специальләшкән күчмә механикалаштырылган колоннасына 1996-2000 елларда эшче куллар кирәкми" һ.б.

Юлбарыс кызыксынып эчкә үтте. Генераль директор кабинетындагы стеллажга ун-унбиш төрдәге эреле-ваклы чиләкләр тезелгән. Предприятие ясап чыгарган буяулар өчен икән. "Әһә, – дип уйлады Юлбарыс, чиләкләрдәге язуларны укуга, – биредә Телләр турындагы законны үтиләр икән. Инглиз, урыс, татар телләрендә язылган. Дөнья стандартты буенча эшләргә тырышалар, димәк. Тик менә генераль директор гына үз фамилиясен дөрес язмаган.

– Ник фамилияңне урысча язып куйдың? Сиразин түгел, Сираҗин диярга кирәк бит, – диде ул монитор аша складларны тыныч кына күзәтеп утыручы директорга.

– Ялгышасың, Юлбарыс әфәнде. Фамилиям бик дөрес минем һәм аның тарихы бик тирәндә. Без – каторжаннар нәселеннән. Әни ягыннан ерак бабам Степан Разин восстаниесендә катнашкан. Анда татарлар күп булган. Восстание бастырылган. Баш күтәрүчеләрнең кайсын атканнар, кайсын асканнар. Бабамны каторгага җибәргәннәр. С.И.Разин хөрмәтенә ул Сиразин фамилиясен алган. Шуннан бирле без – Сиразиннар.Ерак бабам һәм аның кебек бунтарьларның җан авазлары булган җырлар безнең көннәргә килеп җиткән. Менә тыңла әле:

**Иркутски төрмәсендә**
**Җәй булса да кыш кебек.**
**Еллар буе ятабыз без**
**Канатсыз ла кош кебек.**
**Агымсуга чума күрмә,**
**Су төбендә ятьмә күп.**
**Чит илләрдә без йөрибез**
**Адашып калган бөбкә күк.**

Ә бабам Борһан Сиразинны 1937 елда атканнар. Революциягә кадәр зур сәүдәгәр булган. Кулга алынганда "Союзмука" трестында каравылчы булып эшләгән. Омскида аларны, 22 мөселманны, тройка приговоры нигезендә хөкем иткәннәр. Бабама "Мөселманнар арасында советларга каршы пропаганда алып барган" дигән ярлык такканнар. Атылганнарның барысы да элекке эре сәүдәгәрләр. Алар арасында хәзерге Зеленодол районы Танай авылы кешесе Сабитов Абзал Закир улы да бар. Оныклары, туганнары, бәлки, бүгенгәчә аның кайчан, ничек үлгәнен белмиләрдер. КГБ архивларыннан мин дә озак эзләдем бабамны. Алар барысы да реабилитацияләнгән.

– Син үзең дә бабаңнар кебек гаярь егет. Бунтарь каны агадыр, диюем...

– Ага! Зимагур, каторжан каны уйнап тора. Андропов заманында (!) Бухарин клубы әгъзасы идем. Хәзер дә үземне оппозиционер дип исәплим. Кытайларда бер әйтем бар. Сәясәтче зирәк икән, аның барлыгын сизмиләр дә. Бик үк акыллы түгел икән, аны мактыйлар. Акылсыз икән, аннан куркалар. Сәясәтчене мактамас, аннан курыкмас өчен оппозиция кирәк.

– Хуш. Ә сәүдәгәр каны?

– Мин бүген сәүдәгәр генә түгел. Капиталист, буржуй. Һәм капиталга юл ачучы Егор Гайдарны туганымдай якын күрәм. Безнең эшләр, шөкер, гөрләп бара! "Сиразин һәм К" акционерлык җәмгыяте фасад өчен майлы буяулар, эмаль, ярымфабрикат, комлы-цементлы кирпеч, керамзитлы-бетон блоклар, фигуралы тротуар плитәләре, пенопласт һ.б. продукцияләр эшләп чыгара.

– Ә эшчеләрегез бишәр ай хезмәт хакы ала алмый интегәме?

– Беренчедән, акчаны алай тоткарламыйбыз, икенчедән, бездә уртача хезмәт хакы – миллион ярым, яңача – мең ярым сум. Безнең халык – эшчән халык. Мин хәтта "татар милләт түгел, ә профессия" дияр идем.

– Ни өчен?

– Себердә яһүдләр, немецләр белән бәрәттән татарлар конкуренция шартларында еш кына җиңеп чыгалар. Чөнки төп сыйфатларының берсе – тырышлык, үҗәтлек.

Гасырлар буе куылып, сөрелеп, изелеп яшәү теләсә нинди авырлыка каршы тору иммунитетын барлыкка китергән. Читтә яшәүче татарларга исә өстенлекләрен исбатларга икеләтә тырышырга туры килә.

– Мәскәү сәясәтчеләре Татарстанны "коммунизм утравы" диярга ярата...

– Татарстанда коммунизм да, социализм да юк. Халык капитализмы да юк, ә номенклатура капитализмы чәчәк ата. Кайчан аның тамырына балта чабыла, шул чагында халык капитализмына юл ачылачак.

– Сиразин боларның кайсына керә инде?

– Халык капитализмына, әлбәттә. Мин урлашмыйм, ришвәт алмыйм, акционерлык җәмгыяте исәбенә салынган коттеджларым да юк, халык байлыгын туздырмыйм, акча сорап беркая да мөрәҗәгать итмим. Һәм гайбәтемне дә сатмыйлар. Мин намуслы эшмәкәрлек итүчеләр яклы.

– Карале, Сиразин әфәнде, нишләп бөтен җиргә лозунглар, өндәмәләр элеп бетердең син?

– Реклама заманы, Юлбарыс дус, реклама белән генә яшәп, эшләп була хәзер. Менә мин сиңа бер чынаяк бүләк итәм. Анда безнең эмблема да, телефон да бар һәм: "Я самый уважаемый и почетный покупатель краски в СНГ", – дип язылган. Русия, БДБ масштабында эш итә абзаң. Сиңа да күңелле андый бүләкне алу, миңа да рәхәт – үз продукциямне рекламалыйм бит.

– Ярый, сау бул. Уңышлар телим сиңа!

– Әй-әй! Ә интервью биргән өчен кем акча түли, Пушкинмы?

Ләкин Юлбарыс МОРАТ әфәнде СИРАЗИННЫҢ соңгы сүзләрен ишетмәде, ул Арча – Казан юлы – Себер трактты буйлап элдертә иде.

Юлбарыс елында туган
бу шагыйребез дә быел
60 яшен тутырып килә.
Батыр йөрәкле, үзенең рухы
белән дөньяларны таң
калдырган Фәнис Яруллин
хакында кайсыбыз
гына белми икән?!
«Мәдәни җомга»га ул менә
бүген дә әр-яңа шигырьләрен
тәкъдим итә. Котлы булсын
Яңа еллар, котлы булсын
киләчәк бәйрәмең,
мул булсын иҗат табының,
хөрмәтле юлбарыс!



Казаным

Әй Казаным, гүзәл шәһре Казаным,
Синдә үтте күпме көз һәм язларым.
Синдә сөйдем, синдә ярлар сайладым,
Синдә җайсыз тормышымны җайладым.

Шаулыйсың син, кайныйсың син, Казаным,
Дан вә шөһрәт даулыйсың син, Казаным.
Гүяки син океандагы зур кораб,
Юл табасың халкым күңеленә карап.

Үткәннәрең синең бигрәк гыйбрәтле,
Искә алсаң – кайнар айкый йөрәкне.
Туфрагыңда канлы тарих эзләре,
Моңсу Айда – Сөембикә йөзләре.

Аҗаганнар – Колшәрифләр кылычы,
Тавышы юк, ялтырый тик корычы.
Кояшта тап – бу күләгәме канлы?
Әллә инде Шаһгалинеңме җаны?

Мин бит бары бер түгәрәк ташны
Алып менгән идем биек тауга.
Никадәрле ыгы-зыгы купты,
Әверелде дә ташым якты Айга.

Каз өмәсе

Фәрештәләр каз өмәсе ясый,
Күктә бүген хәйран-тамаша.
Бөтерелеп очкан ак мамыктан
Баш әйләнә, күзләр камаша.

Күктән килә шаян җыр тавышы,
Бу җырлардан йөзләр нурлана.
Муеннарга кызлар кулы булып
Ак мамыклы буран урала.

Урала да буран, җибәрми һич,
Алып менеп китә биеккә.
Фәрештәләр казлар йолыкканда
Эш табыла һәрбер егеткә.

Ә берәүләр сугышмый да,
Шуышмый да;
Бәхет өчен хөтта өз-мөз
Тырышмый да.

Бәхет үзе килеп ава
Өсләренә,
Белми кеше бәхет белән
Нишләренә.

Байлыгына басып калган
Байлар төсле,
Гомер буе чәбәләнә
Мондый кеше.

Котыла алмый ләкин аннан
Һичбер вакыт.
Чөнки байлык гел түбәнгә
Тора тартып.

* * *

Суындың, дип әйтәсең син,
Беттеме, дисең, утың.
Ничек инде дөрли алсын
Учакта сыңар утын.

Сүнмәсен дисең бу ялкын,
Һич югы бер тының өр.
Сулышыңны да кызгансаң,
Учагымнан читтә йөр.

* * *

Керми киттем каен урманына,
Каен урманнары ак иде.
Керер идем, күңелемә минем
Кара уйлар тулган чак иде.

Аңламады мине ак каеннар,
Миңа рәнҗү саклап калдылар.
Матурлыкны безнең күрмәдең, дип,
Шәфәкъларга кушылып яндылар.

Шәфәкъ уты күкне биләп алды,
Күктә купты яфрак бураны.
Уйларымны яшереп, читкә чаптым,
Озатып калды каен урманы.

Керми киттем каен урманына,
Тыелып кына утырып еладым.

Фәнис ЯРУЛЛИН:

“Без кайтырга тиеш хаклыкка!”

Нигә бетми бу кара тап кояшта?
Искәртәме вөҗданнарны сатмаска?
Күтәрелә һәр чат саен манара,
Канлы яшен сөртеп, Казан яңара.

Тик шулай да җаннарда юк тынычлык,
Чөнки әле богауларда корыч нык.
Басалмыйбыз һаман җиргә туп-туры,
Аска тарта безне богау чылбыры.

Карап торсаң: Казан шаулый, Казан шат,
Ала-сата – кайнап тора һәрбер чат:
Кешеләрнең үткәннәрдә юк гаме,
Тик бүгенге борчый кебек гавамне.

Юк, шулай да күңелләрдә өмет бар,
Туып тора җиргә яңа бөркетләр.
Тотмаса да җаннарында алар үч,
Беләкләрдә өкрен генә җыела көч.

Шомлы еллар үтәрләр дә китәрләр, -
Үз төхетенә кайтыр Сөембикәләр.
Кайтмаса да тарихтагы ханлыкка,
Бер кайтырга тиеш халык хаклыкка.

Мин бары тик...

Мин бары тик түгәрәк ташны
Тәгәрәтеп менгән идем тауга.
Ә ул ташым кулдан ычкынды да,
Әверелде дә куйды ап-ак Айга.

Төнге ауга чыккан киекләр дә
Туктап калды барган юлларыннан.
Фәрештәләр көмеш сөйлән сипте,
Чумырып алып Айның нурларыннан.

Якынрак торган йолдызлар да
Айның яктысында коендылар.
Йолдызларның ап-ак төннәреннән
Ак тамчылар җиргә коелдылар.

Төн югалтты үзенең каралыгын,
Угрыларның күренеп китте йөзе.
Җен-пәриләр таңга үрмәләде,
Кулларына тотып утлы гөрзи.

Берсе казны Ай читенә элә.
Берсе чайкый ап-ак болытта.
Күк кызының туңган бармакларын
Җир егете өреп җылыта.

Уен белән тормыш кушылган да
Бер хозурлык туган гамәлдә.
Бәхетле Ай гармун уйнап тора,
Җилләр бии әйлән-бәйләнгә.

Каз өмәсе бүген, наз өмәсе.
Ак бураннан күзләр камаша.
Әллә күктә казлар каңгылдаша,
Әллә яшь йөрәкләр аңлаша.
Күк йөзендә хәйран-тамаша...

Алданасы килми минең дә бер

Яфрак кына диеп өзгән идем,
Аны-моны һич тә шәйләми.
Әллә инде учым җылысыннан
Сайрап торган кошка әйләндең.

Колагымда – синең дәртле тавыш,
Уч төбемдә – синең талпыну.
Кемнәрнеңдер бәхетен урлагандай,
Күңелемә керде тартыну.

Шуннан бирле хәзер куркып йөрим,
Очып китәр диеп бу кошым.
Йә яфракка әйләнер дә кабат,
Ямьсезләнер кебек тормышым.

Юк, ачмамын, ахры, бу учымны,
Серем калсын әле, әйдә, бер.
Бу дөньяда мең кат алдандым бит,
Алданасы килми миң дә бер.

Күпләр әйтә: учың ачар идең,
Учыңда юк берни – учың буш.
Мин үзем дә әйтә алмыйм аны
Әллә яфрак анда, әллә кош.

* * *

Берәүләр үз кирәкләрен
Шуышып таба.
Икенчеләр -
Сугышып таба.

Ап-ак каеннарның йөзләренә
Сарылмады кара уйларым.

* * *

Сафлыкка шундый нык сусалган,
Зиһеннәр, акыллар чуалган.
Эчимче күзеңнең нурларын,
Яктырсын беразга уйларым.

Шатлыкка шундый нык сусалган,
Үткәннәр рәшегә уралган.
Эчимче туйганчы шатлыгың,
Йөземә күчмәсме аклыгың.

Сөюгә шундый нык сусалган,
Йөрәккә карурман моң салган.
Таратчы шул моңнар томанын,
Яктырсын мәхәббәт урманым.

Бәхеткә шундый нык сусалган,
Юллары ялкынга уралган.
Табалмыйм, табалмыйм, табалмыйм,
Юлларның очлары югалган.

Кызлар үтеп киткәч кенә

Миңа алтмыш тулган диләр,
Кем чыгарган бу сүзне.
Тутыра алмый әле йөрәк
Һаман да унсигезне.

Унбиш яшьлек кызларга да
Күз салмый үтәм әле.
Күз салмыйча үтеп шулай,
Бик кызык итәм әле.

Иң чибәр кызлар күреп тә
Төшмим әле коелып:
Калам шунда – читкә карап,
Коймагарак сыенып.

Йөрим горур, сер бирмичә,
Башны тотам югары.
Кызлар үтеп киткәч кенә
Йотам авыз суларым.

шигырь нечкәлек билгесе белән языла

Ул елларның моңлы кайтавазы

Тырыша-тырмаша торгач, мин, ниһаять, 1962 елның җәендә Казан дәүләт консерваториясенең композиция бүлеген тәмамладым. Кулыма диплом алгач һәм СССР гербы белән саз сурәте төшерелгән өчпочмаклы значок та күкрәгемә менеп кунгач, сөенеч-куанычларым эчемә сыймады, мин Салих Сәйдәшевләр, Нәҗип Җиһановлар кебек чын композитор, имеш! Ләкин тормыш дигән нәрсә бар бит әле. Шул ук җәйне, бала табу сәбәпле, хәләл җәфетемне туган якларына – Баулыга озаттым да, үзем җиң сызганып эшкә керештем. Дәүләт комиссиясе карары нигезендә мине Татарстан радиосының музыкаль тапшырулар редакциясенә мөхәррир итеп эшкә билгеләгәннәр иде. Радиода эшләп китү катлаулы да, шул ук вакытта җиңел дә булды кебек. Катлаулы, авыр яклары шуннан гыйбарәт: ни музыка училищесында, ни консерваториядә татар телен, әдәбиятын, сәнгатен бөтенләй укытмадылар. Югары уку йортын без барыбыз да татар теле һәм әдәбияты буенча чи наданнар булып тәмамладык. Ләкин мин, авыл малае, күп кенә татар язучылары, шагыйрьләре, зыялылары белән аралашканга, үзем дә күңелем белән шактый кызыксынучан, мавыгучан кеше булганга күрә, татар телен, әдәбиятын ярыйсы гына сукалый башлаган идем инде.

Җиңел булды, чөнки радиокомитетта студент елларыннан ук белгән танышларым шактый күп иде. Алар арасында дустым – шагыйрь Ләбиб Айтуганов, диктор Эльс Гаделев, мөхәррир-шагыйрь Марс Шабаев, тавыш режиссеры Исмай ага Шәмсетдинов һәм башкалар. Пединститутның Товарищеская урамындагы тулай торагына барып йөрим, баянчы буларак, еш кына кичәләрдә, концертларда катнаша идем. Берничә мәртәбә студент-яшьләр туйларында да баян тартырга туры килгәләде. Инде яшь композитор буларак та радиодан минем кайбер әсәрләрем яңгырый башлаган иде. Мәсәлән, "Фортепиано өчен сонатина", "Беренче кыллы квартет", Муса Җәлил шигырьләренә язылган "Карашларың", балалар өчен "Сәгать", Мәхмүт Хөсәен шигыренә "Онытмам", Энҗе Мөэминова шигыренә "Шомырт чәчәк аткан чакта" һәм Мостафа Ногман шигыренә "Таң йолдызы" исемле җырлар һәм башкалар. Редакциягә килгәч тә беренче эшем итеп миңа өлкән мөхәррир Маһинур Фәйзулла кызы Җиһаншина музыкаль фонотеканы җентекләп өйрәнеп, кимчелекләрен төзәтеп, яңа авторлар, яңа музыкаль әсәрләр, яңа башкаручылар кертеп картотека төзергә кушты. Бу эш беренче карашка гади генә күренсә дә, бик тә катлаулы, җитди булып чыкты. Радиокомитет фонотекасында йөзләрчә; меңнәрчә музыкаль язмалар тупланган: татар халык көйләре, композиторларыбызның иҗаты, Идел буе һәм Урал төбәге композиторларының әсәрләре, төрле музыка уен кораллары һәм башкаручылар, гомумән, бөтен дөнья музыкасы... Һәрберсен аерым бер системага кертеп, исемнәрен, авторларын, башкаручыларын, яңгырау вакытын теркәргә һәм номерлап яңадан эшләргә кирәк иде. Сүз уңаеннан шуны әйтеп китим, хәзерге вакытта музыкаль картотека бөтенләй башка принципта эшләнгән. Картотекага мин беренче мәртәбә Ренат Еникеев, Ифрат Хисамов, Фәтхерахман Әхмәдиев, Мирсәет Яруллин, Арслан Батыршин, Әнвәр Шәрәфиевларны һәм аларның төрле жанрларда иҗат иткән әсәрләрен керттем. Ул заманда бу шактый четерекле мәсьәлә иде. Хәтеремдә, сәнгать советының чираттагысында өлкән композиторларыбызның берсе тавыш чыгарып, мине тыйнаксызлыкта гаепләде, ләкин минем омтылышым дөрес булып чыкты, нинди талант ияләрен, нинди гүзәл чәчәк бәйләмнәрен күтәргәнмен бит! Беренче сентябрь көне җиткәч, өлкән мөхәрриребез Маһинур ханым Җиһаншина пединститутның музыкаль факультетына укыту эшенә күчте. Редакциядә без өчәү: Ләбиб Айтуганов – әдәби-музыкаль мөхәррир, Иркә Төхфәтуллина – үзешчән сәнгатьтә катнашучылар мөхәррире һәм мин – музыка буенча өлкән мөхәррир булып калдым.

Иркә Төхфәтуллина ул чагында әле генә пединститутның урыс филологиясе факультетын тәмамлаган, музыкага, сәнгатькә чын күңеленнән мөкиббән киткән бик тә тырыш кыз иде. Татар теле, әдәбияты һәм музыкасына белеме чамалырак булса да, ул бик тә зәвыклы һәм яңалыкны тоючан мөхәррир иде. Шул елларда ул кичләрен укып Казан музыка училищесын тәмамлады, үзе дә матур-матур көйләр иҗат итә башлаган иде. "Бишек җыры" дигән әсәре якты истәлек булып исемдә калган.

Ләбиб Айтуганов әдәби-музыкаль мөхәррир вазифаларын башкарды. Ул минем күңелемдә якты йөзле, җор сүзле, шаян, кешеләргә ифрат та ягымлы, игътибарлы, "аяклы энциклопедия" буларак саклана. Үзе шагыйрь, композитор, үзе сценарийлар язучы, тәрҗемәче, режиссер һәм үзенчәлекле артист, тирән белемле, күңеленә нинди уй-фикер килсә, шул эшне булдыра, тормышка ашыра белә торган шәхес; кыскасы, музыкаль фонотеканы биш бармагы кебек белә, безгә дә һәрвакыт булышырга вакыт таба, бигрәк тә теге яки бу әсәрне эзләп чиләнгәндә, ул: "915 нче номерны кара, Мансур Мозаффаровның "Кызлар җыры", – дип кенә куя иде. Ул башкаручыларның, композиторларның, шагыйрьләрнең телефоннарын беркайчан да белешмәләрдән карамады, барысын да күңелдән белә иде. Шул елларда ул танылган музыка әһелләре, музыканың төрле жанрлары, төрле музыка уен кораллары турында күпсанлы концерт-әңгәмәләр, музыкаль очерклар эшләде һәм музыкаль әсәрләрнең эчтәлеген, әһәмиятен гади халыкка гап-гади итеп аңлатып бирүне үзенең изге бурычы санады. Татар халык әкиятләре, риваятьләре нигезендә әдәби-музыкаль сценарийлар төзеп, аларны артистлар белән өйрәнеп нәни тыңлаучыларыбызны да сөендерә иде. Яңа җырлар өйрәтү дисеңме, көтелмәгән яңа тапшырулар тәкъдим итү дисеңме, бар да сагынып сөйләрлек матур истәлек булып калды. Радиотыңлаучыларның хатлары буенча концертларны да ул үзенчәлекле, үтемле итеп эшли торган иде. Ул елларда мәшһүр җырчыбыз Илһам Шакиров башкаруында үзешчән композитор Әкрәм Даутовның "Әниемә хат" дигән җыры аеруча абруй казанды. Йөз хат килсә, туксан тугызы "Әниемә хат"ны тапшыруыбызны сорап язалар иде. Ләбиб концерт төзегәндә халыкның рухи байлыгының үсешен, музыкаль тоемын, белемен үстерүгә йөз тотканлыктан, һәрбер хат авторы белән әңгәмә корып, үз фикерләрен яклап калуга ирешә ала иде. Соралган җыр урынына ул, татар композиторларының классик әсәрләренең өстенлеген билгеләп, радиотыңлаучыларга үзе сайлап алган әсәрне, мәсәлән, татар халык көе "Әнкәм кабере"н яки Заһид Хәбибуллинның Муса Җәлил шигыренә язылган "Сагыну" җырын тәкъдим итә, әмма ләкин концерт ахырында "Әниемә хат"ны да биреп куя иде. Ләбиб дөнья композиторларын да хәтереннән чыгармады. А.Алябьевның "Сандугач", Ф.Шубертның "Серенада", Э.Григның "Сольвейг" кебек популяр классик әсәрләренә нигезләнеп әдәби-музыкаль тапшырулар эшләде.

Әлбәттә, мин үзем дә тыңлаучыларның киң даирәсе эченә кереп, аларның ихтыяҗлары, таләпләре белән турыдан-туры танышып, халыкның тормыш-яшәешендә музыканың нинди зур урын тотуын күңелем белән тоярга, аңларга тырыша идем һәм гомерем буе халкымның музыкаль белемен, аның рухи байлыгын үстерүгә омтылдым.

"Кызым, сиңа әйтәм, киленем, син тыңла", дигәндәй, ул заманнардагы радионың сәнгать советлары турында берничә сүз әйтеп китмичә булмый. Беренчедән, худсовет түләүле түгел, икенчедән, сәнгать советына иң абруйлы, танылган сәнгать осталары – шагыйрьләр, композиторлар, рәссамнар, артист-башкаручылар, фән ияләре һәм җәмәгать эшлеклеләре чакырыла иде. Һәрбер худсоветта алар гел алмашынып тордылар. Худсоветка әсәрне тәкъдим иткәндә авторларның исем-фамилияләре бөтенләй күрсәтелми, худсовет әгъзалары өчен әсәр сер булып кала, һәрбер худсовет әгъзасы үзенең фикерен ачыктан-ачык әйтә ала һәм соңыннан авторлар аларга берничек тә үпкә белдерә алмыйлар иде. Шуңа күрә худсовет әгъзалары авторлардан югары һөнәри осталык, зур җаваплылык таләп итә алалар иде. Минемчә, бу – дөрес алым, шулай эшләргә кирәктер дә. Әмма ләкин мондый худсоветның икенче ягы да бар бит. Һәрбер композиторның, башкаручының үзенә генә хас эслүб-стиле, интонациясе, аһәңалымнары бар. Кайбер худсовет әгъзалары әсәрнең авторын яки башкаручысын белмәмешкә салынып, эт итеп сүккән, хурлаган яки юк кына әсәрне үтереп мактаган чаклар да, йә булмаса "күренекле" иҗатчы үзенең уртакул әсәрен ихластан мактап утырган чаклары да булгалады.

Ул заманнарда үзешчәннәрне сәнгать советларына бөтенләй кертмиләр иде, чөнки алар көй чыгаручылар гына, профессиональ осталыклары, белемнәре чамалы гына булу сәбәпле, редакция бу мәсьәләне үзе хәл итә торган иде. Шуңа күрәдер, профессиональ башкаручы белән үзешчән башкаручыны беркайчан да бергә бутамадылар, бер рәткә куймадылар, куела калса, профессиональ җырчы моңа үпкәли, үзен түбәнсетү итеп карый иде. Профессиональ композиторлар да үзешчәннәргә карата шундый мөнәсәбәттә тордылар.

1964 елның язында бик каты авырудан соң, кадерле дустыбыз – музыкаль тапшырулар редакциясенең терәге Ләбиб Айтуганов вафат булды, без бу вакыйганы бик тә авыр кичердек. Композиторлар Ифрат Хисамов, Бату Мулюков, Мирсәет Яруллин һәм мин Ләбибнең "Безнең күңелләр" дигән җырына нигезләнеп матәм маршы яздык. Ифрат белән Бату партитурасын, ә Мирсәет белән без клавирын эшләдек һәм бер төндә тынлы оркестр өчен, барыбыз бергәләшеп, партияләрен дә яздык. Ул марш Ләбибне соңгы юлга озатканда яңгырады. Кызганыч ки, мин ул әсәрнең язмышын белмим. Ләбиб үлгәннән соң музыкаль тапшырулар редакциясенең эше шактый саекты. Мөхәррир Иркә Төхфәтуллина редакциядәге эшнең авырлыгына һәм катлаулылыгына чыдый алмыйча башка эшкә күчәргә мәҗбүр булды. Бүлмәдә берүзем утырып калдым.

Хәер, ярты елдан университет тәмамлап, безгә әдәби-музыкаль мөхәррир булып Ленар Җамалетдинов килде. Ләкин, бик тырыш булса да, музыкаль белеме булмау сәбәпле, редакция эшен җанландырып җибәрә алмады. Чөнки Ленар язмышы һәм холык-фигыле белән нәкъ менә фән кешесе иде һәм ул шулай булып чыкты да.

Ул елларны мин үзем дә, иҗат кешесе буларак, иҗатка бик тә зур ихтыяҗ кичердем. Иҗат шартлары бөтенләй булмаса да, виолончель ансамбле өчен "Уйлану", тынлы агач музыка кораллары өчен "Квинтет", тынлы оркестр өчен "Сюита" яздым һәм җыр, романс өлкәсендә дә шактый нәтиҗәле эшләгәнмен. Шул ук елны уңышлы гына имтиханнар биреп, Казан дәүләт консерваториясенең аспирантурасына кабул ителеп, яңадан укырга керештем. Шул ук вакытта консерваториядә музыкаль-теоретик фәннәр буенча өлкән укытучы вазифаларын үти башладым...

Фасил ӘХМӘТ,
композитор, Татарстанның һәм Русиянең атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның һәм Русиянең халык артисты, Татарстанның Г.Тукай, Русиянең М.Глинка исемендәге Дәүләт бүләкләре иясе.

Бер сорауга – бер җавап

Ринат МӨХӘММӘДИЕВ, Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе, Татарстанның халык депутаты:

– Узган ел минем өчен иң элек Мөхәммәдъяр, Габделҗаббар Кандалый кебек бөек шәхесләрнең олы юбилейлары, аларның халкыбызга өр-яңадан әйләнеп кайтулары белән истәлекле. Язучылар берлеге идарәсе рәисе буларак та, зур бер вакыйга, шатлыклы мәшәкатьләр итеп кабул кылдым мин моны.

1998 елда исә Гаяз Исхакыйның тууына 120 ел тулуны билгеләп үтәчәкбез, аның татар әдәбиятына, татар халкына чын мәгънәсендә кайту бәйрәмен үткәрәчәкбез.

Ә язучы буларак, Яңа елга өметем шул: бүгенге заманны, киеренке-катлаулы заманны чагылдырган әсәремне төгәллисем бар. Аның исемен дә, җисемен дә хәзергә әйтми торам әле.

Яңа ел теләге итеп әйтәсем килә: киләчәктә һәркем үз язмышының дилбегәсен үз кулында нык тотсын.

● ***Ринат Мөхәммәдиев (уңда) туган ягында.***
Әсрар ШАКИРҖАНОВ фотосы.

Фазыл АГИШ: Сездә катнаш никахтан туган балалар нигәдер урыс була

Япь-яшь егет җырлый.
Күңелен ни тырный,
Нигә көе өзә бәгырьне?
Читтә гомер итсәң,
Туган яктан искән
Җилләренә тикле кадерле.
Сагынуны ник басмыйсың, Истанбул?
Туган җиркәйләрем чыкмый истән гел.

Бу җырны тыңлаганда, Фазылның күзләре дымлана, әмма чал ир еламый, сагышларын эчкә йотып, яшь аралаш елмая... Үзәкләрне өзә шушы җыр, тәкатьсез итә. Туган җирләреннән кайсы бәхет эзләп, кайсы качып киткән, кайсы куылган һәм төрле илләргә сибелгән мөһаҗирләр җыры. Сүзләре... әйтерсең лә сагыш, кайгы-хәсрәт, күз яшьләрен үзенә җыйган-җыйган да кәгазьгә моң булып түгелгән. "Тимер пәрдә" ачылганчы туган илләрен, тарихи ватаннарын бер күрергә тилмереп, күбесе яшәгән җирләрендә туфрак булганнарга моң һәйкәле.

Фазыл Агиш – Төркия татары. Төп чыгышлары Пинҗә төбәгеннән, шулай да ул тарихи ватаны дип Татарстанны исәпли. Инде яшәе илләгә җитеп, чәчләренә чал керсә дә, кайда фатирда, кайда тулай торакта яшәп татлы газап кичерә. Йотлыгып милли музыка тыңлый, концерт-кичә, спектакль, күргәзмәләргә йөреп туймый.

Фазыл Агиш борынгы Акки (Акыш)лар нәселеннән. Аның нәсел шәҗәрәсе Мөхәммәтәмин заманнарына барып тоташа. Мифтахетдин бине Газизулла морзаны Юнә авылында (хәзерге Мордовиянең Тәрби районы) өлкәннәр бүген дә хәтерли. Аны кенәз бабай дип йөрткәннәр. Кызганыч, Агишлар (Акышлар) нәселе чит илләрдәге туган-тумачалары белән генә аралаша. Ә алар зур агачның ботак очы гына бит, тамырлары исә тарихи ватаннарында калган. Агишлар нәселе Юнәдә бүген дә билгеле. Чувашиянең Комсомол районы Урмай авылында яшәүчеләрнең яртысы диярлек Акыш нәселеннән. Бәлки, өзелгән чылбыр шушы авылда ялганадыр?

Фазылның әти-әнисе Хәнифә белән Хәсән Агишлар революциягә кадәр, 1912 елда ук Кытайга күченеп килә. Биредә аларның мануфактура кибетләре була. Маньчжурия җирләрендә шактый озак яшәп, Япониягә киләләр. Чит илдә дүрт балалары туа. 1934-35 еллар тирәсендә Гаяз Исхакый Агишлар гаиләсендә яши. Ата-ана 1934 елда туган малайларына аның хөрмәтенә Гаяз дип исем бирәләр, Исхакый балага исемне үзе куша.

Ата-ана язмышын балалары да кабатлый. Биш туган – Ибраһим, Равил, Гаяз, Фәридә, Фазылны язмыш чүлдәге ком бөртеге кебек очыртып йөртә. Гаяз Канадада яши. Фәридә Ливиядә гомер итә, узган ел шунда вафат та була. Тагын берничә айдан, Конгресс барган көннәрдә Төркиядә әниләре вафат була. Фазыл аны күмәргә дә кайта алмый, Казанда кала. Өч ир туган бер-берсенең хәл-әхвәлен белешеп, үзара ярдәмләшеп Төркиядә яши. Фазыл Конья шәһәренең Сәлчук университетында борынгы татар әдәбияты тарихын укыта. Өченче тапкыр Казанга килүенең дә сәбәбе шул хезмәтенә бәйле. Ул Утыз Имәни, Таҗетдин Ялчыгол, Суфи Аллаһияр иҗатларын өйрәнергә дип килгән. Соңгысының Төркиядә өч кульязма, ике басма китабы саклана. Утыз Имәнинең исә Казанда басылган, Төркиядә сакланган бер китабы бар. Һәм галимнең максаты – бу әдипләрнең мирасын барлап, тирәнтен өйрәнү. Энциклопедик белемле, 13 тел белүче бу галимнең белемгә сусавын яңгырга тилмергән чүл агачы белән генә чагыштырып була.

– Фазыл әфәнде, Төркиядә нинди бәйрәмнәр уздырыла?

– Чын милли бәйрәмнәр – Рамазан, Корбан һәм Гашура бәйрәмнәре бик зурлап үткәрелә. Апрельнең бер якшәмбесендә Аналар көне, язын Аталар көне дә үткәрелә. 23 апрель – Төркия Бөек Милли Мәҗлесе ачылган көн. Ул көнне бөтен кыйтгалардан килгән балаларның иҗат бәйрәме үткәрелә. 6 майда – Сабан туен хәтерләткән Хыдрәллез бәйрәме. Ул кырларда уза. Сабан туйлары да бик күңелле була. 19 май – Ататөркнең Самсун шәһәренә аяк баскан көне – яшьләр һәм спорт бәйрәме. Анда бөтен ил тантана итә. 30 август – Зафәр бәйрәме, грекларны җиңеп, Төркиядән куып чыгарган көн. 29 октябрь – Җөмһүрият көне.

– Ә Яңа елны ничек бәйрәм итәсез?

– Башка вакытта бездә исерекләрне күрмәссең. Ә Яңа елда вино, шампан шәрабе, исерткеч эчемлекләр кулланалар. Кибет витриналары, урамнар бизәлә. Татарстандагы кебек, гаилә бәйрәме ул.

– Менә сезнең белән тәмләп чәй эчеп утырабыз. Чәйне башка илләрдә ничегрәк эчәләр?

– Урта Азия мөселманнары, гарбиләр җимеш салып эчәргә ярата. Ливанда, мәсәлән, чынаякка башта бик куе, хәтта ачы чәй салалар. Икенче чынаяк – сыеграк, өченчесендә күбрәк төрләвекләр салып эчәләр. Ә менә чәйгә алма турау бары татарларда гына дип беләм. Канада кешеләре инглизләр кебек, ә инглизләр татарлар кебек эчә, тик варенье капмыйлар, сөтләп яки лимон салып эчәләр. Кичке сәгать 5 тулдымы, эштән бушагач чәй эчәргә утырталар. Чәй янында сүз тәмле була бит.

– Сез инде Татарстанда өченче тапкыр. Татарча укый-язасыз, көндәлек матбугат чаралары белән дә таныш. Төркия матбугаты белән безнеке арасында нинди аерма бар?

– Аерма зур. Бездә хөкүмәт җитәкчеләрен бик нык тәнкыйтьлиләр. Вак хәбәрләр күп, журналистлар сенсация артыннан куа, шуңа күрә анда чабып йөриләр. Югыйсә, гәзитләрен укучы да аз. Дөрес, "Заман", "Төркия" гәзитләре җитди, башка бульвар гәзитләреннән аерылып торалар. "Милләт", "Динче" дигән гәзитләр дә үз вазифаларын тайпылмыйча үти. Ә башкаларында ялган күп. Тагын бер аерма – акча казасы тәэсир итә безнең гәзитләргә, шуңа күрә кибетләр, маркетинглар ачалар. Запас частьләр, кампитр, хуҗалык кирәк-яраклары саталар, шул исәпкә гәзит чыгаралар.

– Мин шуны аңлый алмыйм: Шәрекъта мөселман хатын-кызлары пәрәнҗә киеп йөри, ә биегәндә чишенеп бетә яза. Шул исәптән төрек кызлары да...

– Мөселман хатын-кызларына ачык җирләрен күрсәтү харам. Ә җырчы, биючеләрнең күпчелеге – чегәннәр. Гарәп илләрендә дә, Һиндстанда да, нигездә, чегәннәр башкара андый биюләрне. Алар үзләре мөселман динен тота һәм үзләрен лули дип йөртәләр. Ә чегән кайда да чегәндер инде ул, каннары шундыйдыр. Җиңелчә яшәргә яраталар. Базарларда аю биетәләр, фал китабы ачалар, җыр-биюгә маһирлыкларын әйттем инде. Чегәннәр үз мәхәлләләрендә туристлар өчен махсус "спектакльләр" оештыралар. Ике йорттан ике чегән хатыны чыга да юктан гына сүзгә киләләр, бер-берсен мәсхәрәлиләр. Әйтик, берсе поднос тоткан, икенчесе – палас.

– Синдә поднос бармы?

– Юк.

– Һи, хәерче, подносы да юк икән.

– Ә синең паласың юк. Палас – поднос кына түгел, шулай булгач син хәерче!

– Кем, минме? Күрсәтим әле мин сиңа!..

Шуннан китә ызгыш-талаш. Туристлар авыз ачып карап тора. Хатыннар бер-берсенең чәченә ябыша. Туристлар көч биреп, куәтләп тора. Сюжет бар, конфликт бар – спектакль шәп! Чегән хатыннары сугышып киемнәрен ертып бетерәләр. Һәркем канәгать. Туристлар урам спектакле карады, тегеләр акча җыйды. Сугыш өтәчләре диярсең.

– 1993 елда сез Татарстан Мәгариф министрлыгы чакыруы буенча килгән идегез. Белүемчә, министрлык Төркия милли мәгарифеннән үрнәк алыргамы, юкмы, дип кызыксындылар бугай...

– Мин кистереп "юк" дидем. Милли мәгариф системасында япон өлгесен кулланырга кирәк: анда балалар уен аша танып белергә өйрәнәләр. Кореяда исә һәр бала бишәр музыка уен коралында уйнарга өйрәнә. Мәгариф системасы Татарстанда әлегә камил түгел. Бу система әле яшь, һәм эшлисе эшләрегез күп. Бигрәк тә чит телләрне өйрәнү үз югарылыгында түгел. Урыс теленең чит илләрдә кирәге юк, чөнки аңа хаҗәт юк. XXI гасырда халыкара аралашу теле нигездә инглиз теле булачак.

– Үзегез нинди телләр беләсез?

– Мин унөч тел беләм, күбесендә иркен сөйләшәм, укый-яза беләм. Кызым Фазилә-Дәрья дә телләр өйрәнергә маһир. Төрек, татар, итальян, француз, инглиз, немес, япон телләрен камил белә. Ул Анкара университетының итальян филологиясе факультетында укый.

– Фазыл әфәнде,инде туганнарыгыз белән дә якыннан таныштырсагыз иде.

– Ибраһим абый полковник. Равил абый автомобильләр ремонтлаучы. Хәзер икесе дә пенсиядә. Гаяз абый эшмәкәр, Германиядә, аннан Япониядә яшәде. Хәзер Канадада төпләнеп калды. Хатыны Джерри җиңги немес, Канада Тышкы эшләр министрлыгында эшли.Фәридә апа Ливиядәге бер офицерга кияүгә чыккан иде. Өйдәше (ире) Ливия һава гаскәрләренең баш-командующие иде, соңрак дипломат булды.

– Катнаш никахка мөнәсәбәтегез ничек?

– Минем хатыным төрек кызы. Безнең дин, милләт мәсьәләсендә бернинди проблемалар юк, чөнки төрек ул барыбер кардәш халык. Татарларга ят итеп карамыйлар. Шуңа алар Япония, Кытайдан бирегә җыелдылар. Фәридә апа, мәрхүмә, шулай ук бу мәсьәләдә бернинди каршылык күрмәде. Гаяз абый да. Алар бу четерекле мәсьәләне аурупача, демократик юл белән хәл итәләр. Ләкин сездә катнаш никахтан туган балалар нигәдер барыбер урыс була.

– Революциягә кадәр татар мәгърифәтчеләре Урта Азия халыкларын агартуга зур көч куйган. Ә менә Төркиядә татар мәгърифәтчеләренең эзе ни дәрәҗәдә?

– Мәгърифәт ике халыкта да параллель үскән, аны татарлар гына алып килде дип әйтеп булмый. Ләкин мәгърифәтчелек фәлсәфәсе бары татарларда гына. Аны Утыз Имәниләр, Курсавилар башлады. Аурупада бер халыкта да мәгърифәтчелек агымы булмады. Һәм ни гаҗәп, урта гасырлар чоры караңгы түгел иде, бүгенге чорыбыз күпкә караңгырак. Маферлар (мафия) күпкә залимрәк, фашистлар, шулай ук коммунистлар халыкларны каты җәберләде, милләтләрнең мәгарифен, мәгърифәтен бетерү өчен күп көч куйды.

– Сүзегезгә куәт: сез, Төркия гражданы, Утыз Имәни, Таҗетдин Ялчыгол, Суфи Аллаһияр иҗатлары буенча диссертация әзерлисез. Аларның иҗатын биредә югары уку йортлары тәмамлаучыларның күбесе белми дә. Ә Сез чит илдән килеп, гаиләгездән аерым, тулай торакта ачлы-туклы яши-яши бөртекләп гыйлем җыясыз...

– Мин эшләмәсәм, кем эшләр? Бу, күрәсең, бабамнар каны аша сеңгән мәгърифәт нуры чаткысыдыр. Җан тартмаса, кан тарта, диләр бит...

Әңгәмәне
Рәсимә СИБГАТУЛЛИНА
үткәрде.

Бер сорауга — бер җавап

Салисә ГӘРӘЕВА Татарстанның Минзәлә районы Тулбай авылында 1938 елның 6 ноябрендә – Чаян йолдызлыгы билгесе астында Юлбарыс елында туган.

Шагыйрәнең иҗаты Уралда чәчәк атты. Ул 30 ел буе Чиләбе шәһәрендә яшәде, эшләде, иҗат итте, татар әдәбиятын, мәдәниятен пропагандалау белән шөгыльләнде, әдәби берләшмә оештыруда, аны җитәкләүдә күп көч куйды. Чиләбедә татар телендә беренче телевидение ("Чишмә") һәм радио ("Дулкын") тапшыруларын оештырды һәм алып барды. Татар һәм башкорт телләрендә "Дуслык" һәм "Туган як" гәзитен оештыручыларның берсе булды, Чиләбедән Казанга күчеп кайтканчы аларның җаваплы сәркәтибе булып эшләде.

Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.

1991 елдан бирле Салисә Гәрәева Казанда яши. Хәзерге көндә "Мәдәни җомга" гәзите редакциясендә эшли.

Салисә ГӘРӘЕВА

Үзем турында үзем

Яшәгәне — сихри дөнья аның,
Сихри дөнья сыймый җанына.
Тыелмаган дәртләр, моңнар белән
Узып бара көзләр ягына...

Кирәкмәгән чакта ояла ул,
Кеше көлгән чакта моңая.
Кеше торып басса, иелә ул,
Кеше иелгәндә... турая.

Бар дөньясын онытып гашыйк була,
Килешүләр белми нәфрәте.
Шатлыклары күзләренә чыга,
Күкрәгендә сыза хәсрәте...

Беркайчан да алдашмаска, дигән
Вәгъдә асларында туган ул.
Яздай дәртле, үләң кебек юаш,
Корыч кебек каты булган ул, -
Гел шигырьдән генә торган ул!..

Илдус ВАГЫЙДУЛЛИН, Чаллыдагы 29 нчы мәктәп-лицей директоры:

– Барлык шатлык-сөенечләрем дә, борчу-мәшәкатьләрем дә мәктәп белән бәйле. Узган елда мәктәпнең 20, педагогик лицейның 5 еллыгын билгеләп үттек. Мәктәбебез 3 ел рәттән Бөтенрусия күләмендә "Ел мәктәбе" дигән югары дәрәҗәле диплом алды.

Юлбарыс елына өметләребез зурдан. Илдә-көндә бары тик уңай үзгәрешләр көтәбез. Мин үзем ул үзгәрешләрнең иң беренче чиратта авылда һәм авыл хуҗалыгында булуын телим. Узган ел Татарстан бөртекле культуралардан моңарчы күрелмәгән югары уңыш алды. Әмма татар авылларының өхлагын савыктыру, рухын күтәрү өчен күп тырышырга кирәк әле.

Мосафир сәфәрдән кайтты

Майя ВӘЛИЕВА

Уссури урманнарында

Ни генә әйтсәң дә, үзеңне юлбарыс белән тиңләү, юлбарыс итеп хис итү рәхәт инде ул. Астрологлар язганны, төрледән-төрле йолдызнамәләр дә әйтелгәннәрне шаяртып кына кабул итсәң дә, үзеңдә ниндидер сәер теләк тугансын сизәсең: ирексездән, үз холкыңнан юлбарыс сыйфатларын эзли башлыйсың. Әһә, бармы миндә андый горурлык, андый батырлык-кыюлык, бармы миндә андый матурлык һәм затлылык, дисең. Кем белә, бәлки чынлап та, әлеге гороскопларда ниндидер хаклык та бардыр. Әмма, уйлавымча, аларны бик тә акыллы, белемле психологлар төзегән, алар һәр кешенең сыйфатын бик белеп "күзәтәләр".

Менә мин үзем дә Юлбарыс елында туганмын икән бит әле... Әмма мине, язучыны, элек зоолог булган, табигать һәм төрле җанварлар турында шактый язган кешене, чын, тере юлбарыс күбрәк кызыксындыра.

Үткән җәйдә хыялым тормышка ашты: мин быел Җир шарының иң затлы, иң матур бер җәнлеге – Амур юлбарысы яши торган Уссури якларына барып чыктым.

Авыл читендә үк юлбарыс эзенә тап булу, юлбарысның ишегалдыңнан яраткан этеңне "урлап" китүе, чак кына урман эченәрәк кергән атыңны ботарлавы мондагы халык өчен гадәти хәл. Әмма минем өчен Юлбарыслар илендә булган көннәр ниндидер бер ачыш, могҗиза булып әверелде. Менә без – Уссури тыюлыгының нәкъ үзәгендә, тайга буйлап аккан Майхэ елгасы ярында. Кыш көне бу тирәдә, ике баласын ияртқән ана юлбарысны күреп калганнар. Җәй көне исә Уссури тайгасы үтеп-сүтеп булмаслык чытырманлыкка әйләнә, монда инде юлбарысны күрермен дип уйлама да. Юлбарысны монда, гадәттә, кыш көннәрендә генә күрергә-очратырга мөмкин. Ләкин аның кайдадыр якында булуын шәйләве кыен түгел: яңгырдан соң йомшарып калган туфракта ап-ачык булып ярылып яткан эзләр моннан әле генә юлбарыс үтеп киткәнлеген сөйли. Менә монда, юан бер агач төбендә, юлбарыс үзенең "чик баганасы"н билгеләп куйган: агачның аскы бер өлешендә кайрысы кубарылган-тырналган, юлбарысның тырнак эзләре калган. Шул ук агач төбендә чокыр да казыган юлбарыс. "Кермәгез минем җиргә, йөрмәгез минем патшалыкта!" – дип кисәтүедер инде. Кисәтү-кисәтү белән, ә шулай да, кайдадыр янәшәдә, куе куак-үләннәр арасында шундый ерткыч булуын, сине күзәтеп-сагалап йөрүен күзаллау гына да йөрәккә шом сала...

Мондагы аучылардан, зоологлардан шушы көчле һәм җитез, хәйләкәр һәм акыллы ерткыч турында сораштырам. Юк, юлбарысның ерткычлыгы һич тә дөрес түгел икән бит. Юлбарыс, гадәттә, кешегә беренче булып һөҗүм итми. Әгәр дә аны яралаган булсалар, аның балаларына куркыныч тудырсалар – ул чакта инде юлбарыстан рәхим-шәфкать көтмә. Кеше ашаучы юлбарыслар турында да күп сөйләнде, әмма Амур юлбарыслары "тарихында" андый очрак теркәлмәгән. Ерак Көнчыгыштагы җирле халыкның юлбарыс белән "мөнәсәбәте" бик тә үзенчәлекле. Юлбарысны монда Амба дип атыйлар, хөрмәт итәләр. Юлбарысны үтермиләр, аның "күңеле хуш булсын" дип, йөргән юлларына ризык салалар. Бу якларда шундый бер ышану да бар: тайгада Юлбарыслар Патшасы яши, аны маңгаендагы буй-буй сызыкларыннан танып була, әлеге сызыкларда кытай иероглифы белән изге сүзләр язылган, Юлбарыслар Патшасын үтергән кеше мәңгелек каргышка юлыгачак... Әмма, кызганыч, Ерак Көнчыгышка соңрак күченеп килүчеләр, җирле халыкларның бу ышануларын санга сукмыйча, башкачарак кыланганнар. Кайчандыр тайгада шактый күп булган Амур юлбарысының саны хәзер нык кимегән, 450 чамасы гына калган. Үрчем өчен, нәсел-токымны саклау өчен бу бик аз. Амур юлбарысы дип аталган төрнең (ә бу дөньяда иң зур, эре токымлы юлбарыс) бөтенләй юкка чыгуы мөмкин дигән сүз бу. Юлбарысларның Тебит медицинасы өчен кыйммәтле чимал булулары да аларның үз бәхетсезлегенә күрә икән. Бөтен барлыгы белән – тырнакларыннан алып мыек очларына кадәр – юлбарыстан төрле дарулар ясыйлар һәм бу дарулар Көньяк-Көнчыгыш Азиядә бик кыйбат хакка йөри. Ә инде безнең браконьерлар, юлбарысларны атып, кытайларга сату ягын карыйлар. Бер юлбарыс аларга 2 мең доллар акча китерә бит. Закон буенча, юлбарысларны ату гомумән тыела. Әмма Русиядә кайчан да булса закон сакланганын кемнең күргәне бар?

... Шулай итеп, тәки күрми киттем мин юлбарысны бу тайгада. Ә менә тавышын гына булса да ишетеп калдым. Елан тавы янында, урман кардонында кунарга тукталган идек. Таң атканда мин, таң атуын киносурәткә төшереп алыйм әле дип, тау кыясына күтәрелдем. Һәм кинәт менә шушы таш-кыя артыннан мин моңарчы беркайчан да ишетмәгән тавыш яңгырап сузылды, аның кайтавазы мәһабәт кедрларның кәүсәләре буйлап узды. "Ма-а-а-у!.." Азатлык тавышы, көч-куәт һәм әйтеп бетергесез егәр-кодрәт иңгән тавыш иде бу. Мин башта аның каян килгәнлеген аңламый тордым. Аңлагач, кулымдагы кинокамераны чак кына кыя астына төшереп җибәрмәдем. Бу тавыш миндә соклану катыш курку хисе тудырды. Юк, юк, һич тә очрашасы килми иде урман сукмагында юлбарыс белән...

Ә инде астрология буенча юлбарыс булган кешеләргә һәм үземнең "юлбарыслыгыма" кайтып, шуны телисем килә: Юлбарыс елы безгә дә, чын юлбарысларга да мәрхәмәтле булсын. Шушы елда мин Уссури якларына сәяхәтем һәм Амур юлбарысы турында хикәятемне тәгаллләп, бастырып чыгарырмын дип өметләнәм.

Халык әдәбияты

Чәчләрең озын биленнән...

("Наза уены"нда җырлана торган җырлар)

Җырламый тормыйк әле,
Чәчәк кебек гомерне
Бушка уздырмыйк әле.

Их, тугай, тугайда...
Нигә үзең генә килдең,
Сөйгән ярларың кайда?

Карлыган каралары;
Алар нәселләре белән
Сандугач балалары.

Акны кияр чакларың;
Сайлап сөй, дустым, сайлап сөй,
Сайлап сөяр чакларың.

Матур син, күгәрчен син,
Кимә шушы киемеңне,
Күз тиеп үләрсең син.

Исемнәре Нәфисә;
Сиңа дигән сәлам җиле
Арча ягыннан исә.

Укучылар ял итә.
Укыганда ярлар сөйсәң,
Укуга мишайт итә.

Кар көрисең көрәксез.
Шушы яшеңә җитеп
Яр сөймисең, йөрәксез.

Чалбарыңның тарлыгы;
Йөзләреңә чыккан инде
Сөйгәнеңнең барлыгы.

Җилгә түгел, давылга;
Егетләр алып калыгыз
Үзебезнең авылга.

Кисеп алдым якалык;
Йөрдегез дә аерылдыгыз,
Кайсыгызда хаталык?

Исемнәре Лариса;
Үзебезгә килен итеп
Алырбыз, Алла боерса.

Җайлымы урыныгыз;
Егылып төшә күрмәгез,
Ябышып утырыгыз.

Чәчең озын биленнән.
Чәчләрең озын биленнән,
Чыгармаслар иленнән.

Чәчең озын – бер метр;
"Җаным-бәгърем" дигәннәргә
Серләреңне бирми тор.

Бу уен җырларын миңа 1989 елда Саба районы Казаклар авылыннан КДПИ студенты Г.Әскәрова язып алып тапшырган иде. Хөрмәтле дуслар, сезнең авыл яшьләре тагын нинди уеннарны җырлап уйныйлар. Аларны уйнауның тәртибе ничек, нинди җырлары бар? Шулар турында тулырак мәгълүматлар белән кичке уенда, клуб кичәләрендә уйнала торган җырлы биюле уеннар турында язып җибәрсәгез, бик шат булыр идек.

Аларны Татарстан китап нәшриятында "Татар халык уеннары" дигән күләмле китап итеп тә чыгару күз алдында тотыла. Сез язып җибәргән уен тасвирламалары, уен җырлары анда да урын алачак, искәрмәләрдә сезнең хезмәтегез күрсәтеләчәк.

Рәшит ЯГЪФӘРОВ,
фольклорчы галим.

Алтынчы юлбарыс

(Татарстанның һәм Русиянең халык артисты, Татарстан һәм СССР Дәүләт бүләкләре иясе Ринат Таҗетдинов белән әңгәмә)

– Ринат абый! Сез 1938 елның 1 гыйнварында – Юлбарыс елында тугансыз. Ул бәләкәй юлбарыс ничегрәк исегездә калган?

– Беренче юлбарыс бәләкәй булуына карамастан, холкы шактый кырыс иде, без – балаларга теш-тырнакларын еш күрсәтте. Минем балачак елларым шуңа да бик авыр вакыт булып хәтеремә уелып калды. Туйганчы ашарга-эчәргә булмады. Ярый әле безнең сыер бар иде, шул коткарды. Әти-әнинең ярлырак күршеләренне өебезгә алып кереп, сөт эчерткәннәре әле дә булса хәтеремдә. Авыр булса да, кешеләр бер-берсенә ярдәмчел, мәрхәмәтле иде, бәлки, шуңа күрәдер, ул елларда, безнең җиде мәхәлләле, бер меңнән артык хуҗалыктан торган авылыбыз, укыган мәктәбебез бик матур булып исемдә калган. Ничек кенә авыр булса да, мәктәптә укулар дәвам итте. Беренче укытучым Наҗия апа Хафизованы мәңге онытасым юк. Безнең йөрәкләребездә туган телебезгә, әдәбият-сәнгатькә мәхәббәтне ул кабызды. Урындыкка басып "тамашачы" алдында беренче мәртәбә шигырь укуым да шунда булды.

– Яңа елны ничек каршылый идегез?

– Яңа ел каршылау әлләни истә калмаган. Безнең халыкка хас бәйрәм түгел бит. Аннары, инде әйткәнемчә, тормыш та бик авыр булды. Яңа ел минем өчен туган көнем белән истә калган, чөнки туган көнемдә миңа әниләр бераәр тәмле әйбер, йә кызыл билле прәннек, йә ипигә калын итеп май ягып бирә иделәр. Хәзерге кебек, җиләк-җимеш, банан-манан юк иде.

– Ул чагында мәҗлесләр була идеме?

– Мәҗлесләр була, ләкин балаларны анда катнаштырмыйлар иде. Иң әүвәл, идәнгә утыртып ашаталар да, урамга куып чыгаралар. Тик шулай да табынга исерткеч куелганын, мәҗлестән кешеләр исерешеп таралышканын бер дә күргәнем булмады. Гомумән, тәртип нык иде.

– Икенче Юлбарыс Сезнең янга 1950 елны килде. Ул ниндирәк булды?

– Ул елны миңа 12 яшь тулды. Ул да миңа бик таләпчән булды. Апабыз кияүгә чыгып киткәнгә күрә без, 5 малайга, бөтен хатын-кыз эшләрен башкарырга, токмач кисәргә, су ташырга туры килде. Миннән кызлар мыскыллап көлсәләр дә, минем моңа әллә ни исем китмәде. Хезмәтнең ямен, ипинең тәмен татырга мин шулай өйрәндем. 1948-50 нче еллар бигрәк тә авыр, ачлык заман булды.

– Өченче Юлбарыс белән 1962 елны, Сезгә 24 яшь тулгач күрешкәнсез...

– О-о! 1962 ел – баш беткән, мине бәхетле иткән өйләнү елы ул. Рәисә, минем хатыным, Мәскәү кызы. Без аның белән Мәскәүдә, мин Щепкин исемендәге Кече театр каршындагы училищеда укыган чакта, гастрольгә килгән Илһам Шакиров концертында, колонналы залда таныштык. Һәм, менә могҗиза! – ниндидер илаһи көч, магнит димме, безне бер-беребезгә дәррәү тартты, без очраша башладык. Шулай итеп 2 ай үтүен сизми дә калдык. Мин, укуымны тәмамлап, бер дә теләмичә, Казанга кайтып киттем. Рәисә Казан вокзалында елап калды. Көн саен хат алыша башладык. Аһ, ул мәхәббәт хатлары. Шуннан да кадерле истәлек бар микән? Әле дә булса мин аларның бер-икесен күкрәк кесәмдә йөртәм, искә төшкән саен алып укыйм. Алар мине ерак калган яшьлегемә алып кайталар сыман... Әле дә булса хәтеремдә: театрыбызда "Күзгә ачы җилләр"нең репетициясе бара. Мин анда гармунчы егетне уйныйм. Иң беренче ролем. Йөзгә кызыллык китерергә һич тә ярамый. Ә миңа Мәскәүдә булырга, Рәисә белән ЗАГСка барып, язылышырга кирәк. Билет кесәдә анысы, әмма режиссер Габдулла Йосыповтан ничек сорап китәргә? "Авырмыйм да ичмасам!" дип уфтанам үз алдыма һәм үзем дә сизмәстән эчтән яна башлыйм. Ялкын битләремә бәреп чыга.

– Сиңа нәрсә булды, егет? – ди Габдулла абый борчылып.

– Хәлем бик үк әйбәт түгел, – дим, башым әйләнә башлап.

– Бетте улым, – дип Габдулла абый кырт кисә. – Мин сиңа 3 көн бирәм. Кайтып ят, дәвалан, яме!

Театрдан чыгып вокзалга очтым гына. Поезд "тук-тук ". Мәхәббәт җырын көйләп, мине Рәисәм янына алып китте. Менә шулай романтик рухта башланып китте безнең тормыш. Бик бәхетле булдым. Ике кызыбыз туды. Рәисә бер үзе диярлек (артист халкы һаман гастрольдә бит) аларны бик сөйкемле, кешелекле, әти-әнине хөрмәт итә торган кызлар итеп үстерде, тәрбияләде. Болар – Рәисә эше.

– Дүртенче Юлбарыс – 1974 ел. Сезгә инде 36 яшь тулган, ир уртасы булып барасыз. Үзегез дә, әйтер идем, аякларында нык басып торучы юлбарыска охшап торасыз.

– Ул елларда җәмгыятебездә яңа кеше, яңа яшәү рәвеше, дигән бер дулкын кузгалган, җанлану башланган чор иде. Шуңа күрә безнең дә, ил белән дигәндәй, үз илебезгә, үз халкыбызга, театрыбызга фидакарьләрчә бирелеп, иҗатта янып йөргән чагыбыз. Нәкъ менә шушы елларда Нурихан Фәттах үзенең "Кол Гали" драмасын театрыбызга китерде. Миңа борынгы болгар шагыйре Кол Гали ролен ышанып тапшырдылар. Без бу әсәрне сәхнәгә менгездек. Шулай итеп, без әлегә кадәр бернәрсә дә белмәгән тарихыбызга үз генә булса да эз салдык. Шулай ук Туфан Миңнуллинның "Канкай углы Бәхтияр" әсәре буенча куелган спектакльдә мин уйнаган мулла роле дә күңелемә хуш килде. Бу – дин әһелләре турында беренче уңай сүз иде. Нәкъ менә шулар безне динебезгә, иманыбызга кире кайтара башлады бугай. Гомумән, юлбарыс миңа гаҗәеп көч, дәрт бирде. Мин инде хәзер сәхнәдә нык басып торган, һәр нәрсәгә үз карашым, үз фикерем булган актер идем.

– Бишенче Юлбарысны 48 яшьтә, 1986 елны каршы алгансыз. Хәерсез "перестройка" башланып киткән заман.

– Мин аны бик үк "хәерсез" димәс идем. Татарстаныбыз өчен бераз мөмкинлекләр ачылды сыман. Мин моны үз язмышымда ачык тойдым. Мине ул елны өч ролем – А.Островскийның "Бирнәсез кыз"ындагы Карандышев, Туфан Миңнуллинның "Монда тудык, монда үстек"тәге Илфат һәм "Моңлы бер җыр" ындагы Муса Җәлил образлары өчен һич көтмәгәндә СССР Дәүләт бүләгенә тәгъдим иттеләр. Мин аны алуга ирешермен дип уйламадым да, ышанмадым да. Ниһаять, Мәскәүдән бик зур комиссия килеп, безнең спектакльләребезне өчәр кат карап,энә күзеннән үткәргәннән соң, бүләкне бирергә, дигән карарга килделәр. Билгеле инде, бу, актер буларак, үз-үземә ышанычны тагын да арттырды, күңелне үстереп җибәрде.

– Ә илдәге үзгәрешләр Сезгә ничек тәэсир итте?

– Менә шуннан соң үзгәрү чоры башланып китте. Карт башлыкларыбыз бер-бер артлы дөнья куя. Яңа җилләр исә башлагач, без бик сөенгән идек, халыкка яхшылык килер дип өметләнгән идек. Тик нигәдер алай булып чыкмады. Барысы да шулай асты-өскә килеп, әйләнеп капланыр, дип кем уйлаган. Кызганыч ки, дистә еллар буе ирешелгән нәрсәләребезне дә бер селтәнүдә җимереп ташладык. Бу өр-яңа революция ясау кебек иде. Ә халыкка файдасы тидеме соң аның?

– Бу җилләрнең сәнгатькә йогынтысы булдымы?

– Булмый калмады, әлбәттә. Дөрес, аның яхшы ягы да булды. Театр үзе теләгән һәр әсәрне кую бәхетенә иреште. Без моңа сөендек. Элек бит комиссияләр спектакльләребезне энәсеннән-җебенә хәтле тикшереп теңкәгә тия, берәр артык сүз булса үткәрми иде. Хәзер ул нәрсә бетте, иркенлек килде. Ләкин һәр нәрсәнең икенче ягы була бит: сәхнәгә бик күп йомшак спектакльләр чыга башлады.

– Шулай итеп, еллар аша тугры юлдашларыгыз – юлбарыслар белән иңгә-иң атлый торгач, Сез үзегез дә бик гайрәтле юлбарыска әйләндегез.

– Тешләр үсте, тырнаклар катты. Сәнгать нечкәлекләрен аңлауга, аларга ябышып ятуга ирешелде...

– Һәм менә бүген сезнең алда – алтынчы юлбарыс. Сез аңа нинди өметләр баглыйсыз?

– Әйе, бу мизгелдә Яңа, 1998 елга аяк басабыз. Озакламый вакыт Яңа гасыр, Яңа меңъеллык капкасын да шакыр. Алда безне ниләр көтә? Иң курыкканым – театрыбыз нишләр икән? Халык йөрми башласа, драматургларыбыз язмый башласа, туган телебез онытылса?! Ә шулай да җанда алга таба яхшы якка үзгәрү булыр дигән өмет бар. Өметсез шайтан гына бит.

– Ринат абый! Сезгә 1 гыйнварда нәкъ 60 яшь тулды. Шушы йолдызлык – Кәҗәмөгез йолдызлыгы астында туган кешеләргә хас сыйфатларны Ходай тәгалә сезгә учлап биргән. Сез бик тырыш, тугрылыклы, башлаган эшегезне җиренә җиткерүчән. Бу тормышта да, сәхнәдә сез тудырган образларда да нык чагыла.

– Беләсезме, шушы 1 гыйнварда тууым аркасында беркайчан да туган көнемне адәм рәтле үткәргәнем булмады. 31 декабрьдә халык Яңа елны каршы ала, көндез йоклый. Туган-тумача, дус-ишләр минем туган көнемә һәрчак соңгарып килә. Җитмәсә, сүккән булалар, "җүнле кеше 1 гыйнварда туамыни?!" диләр. Ә инде 60 яшькә килгәндә исә... Мин аны үзем сизмим дә. Әле уйнарга көч бар, егәр бар. Ходай тәгалә саулыктан аермасын да, сәхнәдән аермасын. Юкса, күзәткәнем бар, иҗат кешесен, яраткан эшеннән аерсалар, бик тиз үлә. Безнең театрыбызның бик әйбәт ягы бар. Ул олы-олы артистларны сәхнәдән җибәрми. "Инсаният" труппасында уйнау аларга җан азыгы, рухи ризык бирә, авыр хәлдә калган өлкән артистларыбызга матди ярдәм күрсәтергә мөмкинлек тудыра. Театрыбыз алга таба да гөрләсен, чәчәк атсын, безгә яңа драматурглар килсен. Татар театрының киләчәге өметле булсын. Илгә-көнгә, туган халкыма җан тынычлыгы, иминлек, рәхәт тормыш телим.

– Бирсен Ходай! Сезнең кебек юлбарыстай гаярь ир-егетләребез булганда халкыбыз һичшиксез яшәр, чәчәк атыр, иншаллa!

Әңгәмәне **Фирдәвес ӘҺЛИЯ** үткәрде.

Ринат Таҗетдинов һәм аның җәмәгате Рәисә ханым оныклары белән.

Бер сорауга — бер җавап

Рафаэль СӘХӘБИЕВ, Татарстанның халык артисты:

– Узган ел минем өчен бик авыр ел булды. Беренчедән, авырдым, җырчы кеше өчен тавыш җепселләренең ни икәнен кешеләр аңлыйдыр. Операциягә ризалашырга туры килде, югыйсә, бөтенләй тавышсыз калырга мөмкин идем. Консерваториядәге табибыбыз Нина Матвеевага зур рәхмәт, тавышымны кире кайтарды. Җырлап китүемә ышанам. Яңа елга да шул өмет белән керәм.

Фирая Солтанова-Жданова, халыкара класслы спорт мастеры:

– Мин 20 ел буе йөгереп, быел беренче мәртәбә ялга чыктым. 9 ай миңа зур ял кебек тоелды. Бу ялда зур бәхет-сөенеч кичердем: Ходай миңа угыл бирде. Беренчедән, аның малай булуы – зур сөенеч. Чөнки кыз булса, аны зур спортка җибәрмәячәкмен. Үзем булганы да җиткән. Ә малаем, Алла боерса, һичшиксез әтисе кебек үк йөгерешче булыр, дип ышанып калам.

Икенче зур сөенеч, 1997 елда ирем Виктор спортта үзе теләгән яңа уңышларга иреште.

Фәнзаман БАТТАЛ

БЕРЕНЧЕ ТАТАРНЫҢ ГАЛӘМГӘ СӘЯХӘТЕ

(Алдагы гасыр хикәясе)

Ниһаять, татар халкын кырык елга якын уйландырган, кимсетеп һәм өметләндереп килгән мәсьәләгә нокта куелды!

Хәер, вакыйга гадәттән тыш куанычлы, бинниһая дулкынландыргыч булса да, сүзне тәртибе белән сөйләү мәслихәттер...

...Ул таңда Татарстан радиосы гимн уйнатып вакыт әрәм итмәде.

Мондый сүлпән гимнны тыңлаганнан соң уяна башлаган адәмнәр дә кабат йокыга китәр, сөенечле хәбәрне ишетми калырлар, дип курыктылармы, әллә гимн көтүгән бүтән көтүк белән бутадылармы – белгән юк, һәр татарга канат бирердәй Сәйдәш маршын яңгыраттылар. Марш тәмамланып та өлгермәде, тыны капланган, каушаган диктор эфирга чыкты:

– Хөрмәтле иртә, хәерле милләттәшләр, туганнар, якташлар! Тыңлагыз, тыңлагыз, ишетми калдык, димәгез! Якын көннәрдә серлелеге белән ерак бабаларыбызны да уйландырган, шөбһәләндергән галәмгә беренче мәртәбә татар космонавты очачак! Ишетүебезчә, Русия Президенты ризалык биреп өлгергән инде. Кем очарга тиешлеген генә ачыклыйсы калган... Бу вакыйганы Русиянең Татарстан мөстәкыйльлеген тануы дип аңларга кирәк...

Хәбәр әйтелеп беткәч, гимнның үзен дә рәттән ике мәртәбә уйнаттылар да, тыңкыш тавышлы халык артистын җырлатырга керештеләр. Әмма халыкны, гадәттәгечә, тегесе дә, монысы да кызыксындырмый иде инде. Һәр баш миенә хәбәрнең үзе генә сеңеп калган иде:

– Кайсыдыр түрәнең малае очадыр әле. Безнең кебекләргә тәтемәс ул...

– Татарстан суверен икән, ни өчен чит ил президенты рөхсәте белән оча?

– Ике хөкүмәт ашатып яткач, каян калсын ул безгә хезмәт хакы...

Икенче бер халык булса, "ура" кычкырыр иде. Һәрвакыт көнче, бер-берсенә хәсет татар бу юлы да үзе булып калды. Аның уйлавынча, илдәге халык кебек үк, президентлар да ачлангач яшәргә тиеш.

Озак та үтмәде, хәбәрнең яңасы килде: галәмгә Минзәләдә яшәп ятучы кырык бер яшьлек Саттар Гаттаров очачак икән!

Шуны гына көткән кебек, Әлмәт, Түбән Кама, Чаллы, Чистай, Әлки һәм башка бик күп шәһәрләрнең, районнарның татарлары митинг мәйданнарына ыргылдылар. Казан халкын әйткән дә юк:

– Ни өчен Әлмәттән түгел?! Долой Минзәлә!

– Чистай татарлары цыпцыкмыни?! Мишәрләргә запретмыни?! Минзәләдән алган хатыннарыгызны аерыгыз!

– Без монда газ сулап, селте эчеп яшибез...Шулай да сан юк. Түбән Камадан бер кешенең булса да саф һава сулап кайтырга хакы юк микәнни ? Яшергән бомбаларыгызны алыгыз да, алга! Космонавты-ние белән Минзәләне күккә очырабыз!

– Казан халкы фән өлкәсендә Минзәлә кешеләреннән өстен булды...

Моның ниндидер яшерен хикмәте булырга тиеш, җәмәгать!.. Минзәлә башлыгы Мәскәү агайга ришвәт биргәндер...

Мондый коткыдан соң митингның койрыгына ут капкандай була:

– Минзәлә башлыгын – отставкага!

– Отс-тав-ка! Отс-тав-ка!! Отс-тав-ка!!!

Казандагы галимнәрнең саны Чыңгыз гаскәреннән ишләрәк булуга карамастан, гап-гади чынбарлыкны аңларлык бер генә акыл иясе дә табылмады. Хикмәт шунда, мондый "отс-тав-ка!"ларга карап кына әле бер түрәне дә эштән чыгарганнары булмады гына түгел, берәүнең дә бер генә йоны да селкенмәде.

Инде дә Минзәлә башлыгына килсәк, ул теге яңалыктан бөтенләй хәбәрдар булмаган хәлдә, Бикбау басуларындагы урак эшләрен тикшереп йөри иде. Булачак космонавт исә бу сәгатьләрдә, "шанцевый инструментын" – шомарып беткән саплы каен себеркесен кочаклап, канауда йоклап ята иде.

Аны йортлар идарәсе управы каерып утыртты:

– Тор тизрәк, хурлыкка калдырасың! Космоска очасың, кос-мос-ка!

Ләкин Саттар, иләс-миләс күзләрен бер генә ачты да, дөньягызны күрәсем килми, дигәндәй, мыгырдана-мыгырдана, кабат ауды:

– Әйе, космаска кирәк, космаска... Шуңа күрә космадым да мин... Косканым да юк... Юк минем косканым, юк... Булачак та түгел...

– Галәм, димен мин сиңа, галәм!

– Каләм дә кирәкми, сәлам дә кирәкми... Аракы кирәк!

Гомер буе айнымас булса да, шушы Саттар йортлар идарәсендә генә түгел, бөтен Минзәләдә сөекле шәхес иде. Ул таң тишегеннән үк бер-ике шәхси йортның ишек алдын себереп чыга. Хуҗалар аңа туйганчы аракы эчертәләр. Шуннан соң аруталу белмәс Саттар, яхшы заправкалы машина кебек, бөтен шәһәр урамнарын себереп китә. Чөнки як-ягына баш күтәреп карамый, аяк астын гына күрә. Ә инде үз участогын эшенең беренче сәгатендә үк себереп бетергән була... Егерме кешелек эшли Саттар!

Управның бер стакан аракы юнәтеп салдыруы булды, Саттар айнып китте. Айнып та китте, себерә дә башлады. Җитәкчесе аны көч-хәл белән туктатты.

– Ашыкма, диләр сиңа! Торып тор! Космоска җибәрәбез сине, командировкага!

– Ярар, барып кайтырмын... Хәзер үк түгелдер бит...

– Күрше авылга димим мин сиңа, космоска, димен!

– Соң, аңладым бит инде, аңладым. Гагарин очкан космоскадыр... Анда чәчбикәләр дә очты бугай бит инде. Син кушкач, барам инде, барам!

– Мин кушмыйм! Русия Президенты куша!

– Алайса бармыйм! – дип киреләнде дә куйды Саттар. – Теләсә кем кушканга йөгеримме?! Ахмак түгел лә мин...

– Гагарин белән икегез беренчеләр булачаксыз икән...

– Нинди беренче?! – Саттар, күзен акайтып, ярсый башлады. – Анда бармаган урыс та, чуаш та калмады инде. Берничә парны бала ясарга да менгереп төшерделәр ул космоска...

– Аңлап бетер: Гагарин – беренче, ә син меӊ дә беренче! "Беренче" дигән сүзе бар!

– Ну, ярый... себереп чыгыйм да Минзәләне...

Ләкин ике-өч мәртәбә дә селтәнергә өлгермәде, себеркесе өстенә машина килеп менде. Каршында Саттарның күзенә алты булып күренгән өч милиционер басып тора иде.

– Ташла себеркеңне, киттек. Космос экспертлары килеп җитте анда. Сине көтәләр.

– Сезнең космосыгыз хакына җандай күргән себеркемне ташларгамы?! Анысы булмас!..

Себеркене буш утын сараена кертеп куйгач кына, аның ишегенә ике йозак салгач кына, милицияләр уртасына кереп утырды Саттар.

Минзәләгә махсус самолет белән килеп җиткән экспертлар төркеме милиция начальнигы бүлмәсендә түгәрәкләнеп утыра иде инде.

– "РСФСРның атказанган урам себерүчесе" дигән мактаулы исемне алган татар Саттар Гатгаров син буласыңмы?

– Мин. Ну и што?.. – диде Саттар, урысларның сөйләшү культурасына охшатырга тырышып. – А вам какое дело?

– Есть важное дело, – диде экспертлар башлыгы. – Космосны себереп, чистартып төшәргә кирәк.

– Тузаны, чүбе күбәйгәнмени?

– Әйе, тузан да, чүп тә җитәрлек анда... Ишеткәнең бардыр, соңгы кырык ел эчендә космоска меңнәрчә спутниклар, кораблар, станцияләр җибәрдек. Инде алар күгәреп, череп беттеләр. Шуңа күрә бөтен дөнья президентлары безнең президентка протест белдергәннәр, әгәр дә үз чүбегезне үзегез себереп алмасагыз, Берләшкән Милләтләр Оешмасыннан да, Аурупа Советыннан да куабыз, дигәннәр. Шулай итсәләр, чит илләрдән тауар керү туктаячак, хезмәт сөючән бөек урыс халкы ачлыктан, ялангачлыктан кырылып бетәчәк...

– Себереп төшсәм, миңа да берәр файда булачакмы соң? Моңа хәтле йә генерал, йә герой иттеләр...

Эксперт, биш бармагын җәеп, учын өстәлгә ябыштырды:

– Һичшиксез булачак! Президент бу хакта тантаналы рәвештә үзе вәгъдә бирде. Эшеңне җиренә җиткереп төшсәң, бер айлык минималь хезмәт хакы сиңа! – Ә үзе күңеленнән сүгенеп куйды ("Карале син бу яптырмалахайны! Татар башы белән исән каласы, кабат җирдә йөрисе килә! Юк инде, анысы тәтемәс, чарасын табарбыз! Җирдә бер татар булса да кимрәк булыр, ичмасам.) – Бәлкем, ефрейтор да итәрбез сине...

Саттар сикереп диярлек урыныннан калыкты:

– Минималь хезмәт хакы икән, киттек, алайса, вакыт сатып тормыйк.

Галәм белгечләре ыгы-зыгы килеп алдылар:

– Алай ашыгу килешми.

– Төрле ягын кайгыртасы бар...

– Җаваплы эш ул... Әйтик, мәсәлән, ашарыңа нинди ризыклар тутырыйк корабка? Консервлармы яки ипи, шоколад кебек нәрсәләрме?..

Һәр ризык исемен ишеткән саен, башын як-якка селкергә керешә Саттар:

– Юк-юк! Мин экологик яктан шикле ризыклар кабул итмим. Мин бары тик Минзәлә аракысы белән хушланам.

– Закускага нәрсә ? Кабымлыкка, дибез...

– Ике стакан аракыдан соң бер стакан аракы кабып куярга яратам. Корабка бер мичкә аракы куйсагыз, бүтән берни дә кирәкми.

"Әйбәт, бик әйбәт. Димәк, "Мир" станциясендәге бәдрәф пычранмас, чиста торыр. Хәер, ул станция болай да җимерек бәдрәф хәленә килеп бетте бугай инде", – дип нәтиҗә ясады баш эксперт. Ә үзе мәсьәләнең икенче тарафын кайгырта башлады:

– Яхшы, яхшы... Себеркең яңамы? Тагын ничәне ясатыйк?

– Бер дә борчылмагыз, татар каеныннан бәйләнгән ул. Космостан соң бөтен Җир шарын себереп чыксаң да тузарлык түгел.

– Тәк-тәк... Сиңа космик станциядән чыгып эшләргә туры киләчәк бит. Шулай булгач, корычтан нечкә трос ясатырбыз. Себергәндә бил каешыңа бәйләрсең. Анысы станциядән ычкынып китмәү, аерылып калмау өчен кирәк. Тагын...тагын... Бөтен чүпләрне, ягъни спутникларны, корабларны, ракеталарны тутырып бару өчен дә шундый ук тростан җәтмә бәйләтербез...

Айный башлаган Саттар, кулларын селти-селти, ризасызлык белдерде:

– Бернинди трос та кирәкми! Мин үзебезнең сукырлар җәмгыятендә сүс бау иштерәм. Җәтмәсен дә шул баудан бәйләттерәм. Алар миңа бушлай эшләячәкләр. Үземнең дә аларның ишек алдын себергән өчен бер тиен дә алганым юк... Мин Русиядә эшләнгән әйберләрнең сыйфатына ышанмыйм. Алар һәр әйберне "ну его на хир, и так сойдет", дип кенә ясыйлар.

Экспертлар бәхәсләшеп тормадылар, чөнки татарны галәмгә очыруның иң беренчел максаты – татар халкын булдыксыз итеп күрсәтү, Татарстанның мөстәкыйльлек яуларга сәләтсез булуын һәм моңа лаек та түгеллеген бөтен дөнья алдында исбатлау иде. Очыру өчен нәкъ менә сәрхуш татарны сайлап алу да тикмәгә түгел...

Шулай да Мәскәүдән килгәннәрнең берсе, күңелендәге агуын тышка чыгармаска тырышып, сорау бирде:

– Минзәлә кешеләре аракыны күп эчәләрме соң?

– Безнең уртак законыбыз бар: эшләгәндә – эчмибез, эчмәгәндә – эшлибез!

... Икенче көнне шәһәргә сәер хәбәр таралды. Кунакханәгә урнашкан экспертларның икесе акылдан шашкан, имеш. Төне буе әлеге уртак законның очына чыгарга маташып караганнар.

– Эшләгәндә эчмибез, диде бит ул. Димәк, тәртипле халык яши монда.

– Ә син ул законның икенче яртысына игътибар ит! – дип каршы төшкән икенчесе. – Эчмәгәндә генә эшлиләр булып чыга түгелме соң?! Бәлки, алар гел эчеп кенә яталардыр, бөтенләй эшләмиләрдер... Хикмәт җөмләнең беренче яртысында. Эшләгәндә эчмиләр икән, димәк, эшлиләр булып чыга.

– Ә мин әйтәм, эчкечеләр законы бу! Эчә торгач, эш өчен вакытлары да калмыйдыр...

Шулай итеп, бер үк сүзләрне кабатлый-кабатлый, һәркайсы үз хаклыгын исбатлый-исбатлый, сугыша башлаганнар, бу законның Мебиус тасмасы кебек үк очсыз, ахырсыз икәнлеген шәйли алмаганнар. Ниһаять, башларындагы кайбер шөрепләре ычкынып китеп, шәрә килеш Минзәлә урамына чыгып йөгергәннәр. Берсе "эшләгәндә – эчмибез", икенчесе "эчмәгәндә – эшлибез", ди-ди, атына-атына, такмаклый-такмаклый йөгереп баралар икән.

(Дәвамы бар).



Батулла баганасы

Яшь мәсьәләсе

Сара ханым Садыйк беркайчан да үзенең ничә яшьтә икәнен әйтмәгән, диләр. Туган елын күрсәтмәс өчен ул хәтта юбилей бәйрәмнәре дә ясатмаган, имеш.

Композитор Нәҗип Җиһан белән Сара ханым Садыйк бервакыт бик нык ачуланышалар. Бәхәснең соңгы сүзен Сара ханым әйтә:

– Син, Нәҗип энем, миңа кизәнмә! Син капка астыннан ыштансыз чабып йөргәндә Сара апаң күптән атаклы җырчы иде, күп көйләр авторы иде! – дип чыгып китә.

Нәҗип Җиһанның алтмыш яшьлек бәйрәмендә Сара ханым чәчәк бәйләме алып, сәхнәгә менеп, Нәҗип Җиһанны кочаклап үбеп:

– Чын күңелдән котлыйм сине, яшьтәш! – дигән, имеш.

Ә бервакыт Исәнбәттән сораганнар:

– Нәкый ага, Сара апа ничәнче елгы ул?

Аксакал болай җавап биргән, имеш:

– Без шәкерт чагында ул атаклы җырчы иде инде!

Нәкый ага 1900 елда туган. Шулай булгач, Сара апа ничәнче елгы була инде?

Үпкәләү

Урал ягында, Асбест дигән шәһәрдә татар артистлары "Сүнгән йолдызлар"ны уйнап йөриләр икән. Сәрвәрне Сара ханым Садыйк башкара. Баш режиссер Газиз Айдарский (Сара ханымның ире) һәр кичне спектакльдән соң хатынын күтәреп тора икән. Ләкин бер көнне Сара ханым урамга чыкса, аптырап кала. Халык кайтып беткән. Артистлар юк, Газиз Айдарский да күренми. Сара ханым иренә бик нык үпкәли; аның үпкәләве шул кадәр тирән була ки, ул кайтып җиткәч, торакка керми, төнге урамда йөри. Уңышлы спектакльдән соң башка артистлар шаулаша-шаулаша чәй эчәләр. Театрның мәхәббәт гүзәле, җырчы, Сәрвәрне өздереп уйнаучы мәшһүрә Сара ханым Садыйк үксеп җылый-җылый кара урамда ялгызы гына йөри дә йөри. Шулчак Газиз Айдарский аны эзләп таба:

– Сарушым, Аллага мең шөкер, син табылдың! – ди ул. – Гафу ит, зинһар, Сабир Өметбай белән театрыбызның киләчәге турында сөйләшә-сөйләшә сине каршы алырга соңга калганмын. Сәнгать корбаннар сорый, кичер мине, Сарушым!

Сара ханымның үпкәсе шундук юкка чыга.

Бармактан чыккан көй

Бервакыт композитор Рөстәм Яхин белән Сара Садыйк сөйләшеп утыралар икән.

– Сара апа, сез бит көйләрегезне чын күңелдән чыгарасыз, шуңа күрә сезне халык сөя.

– Син, Рөстәм, үзең дә бик матур көйләр язасың! – ди Сара ханым.

– Шулай шул, мин көйләрне язам, ә сез көйләрне чыгарасыз! Сез күңелдән чыгарасыз, ә мин бармаклар белән көй язам! – дигән Рөстәм бәй.

Шаман кытыклары

Аны еш кына Шаман дип тә атап йөртәләр. Дөресрәге, ул үзе шаян әсәрләрен Шаман исеменнән бастыра. Танылган шагыйрь, язучы, матур-матур җырлар авторы Шамил Мәннап үзе юлбарыс елында туган. 1998 елның 1 гыйнварында аңа 60 яшь тулды. Бүген дә Шамил Мәннап үз бәйрәмен яшьләрчә елмаеп каршылый.

Бу юлбарыс үзенең шаян әсәрләре белән кайчак дусларын-каләмдәшләрен дә "тешләп-тешләп" ала. Әмма, тешләве ихлас булганлыктан, аны без нәкъ менә елмаючан юлбарыс дип атыйбыз. Каләмдәшебезне Яңа ел белән дә, түгәрәк бәйрәме белән дә кайнар котлыйбыз!



Кыек атып туры тидерү

Җор сүзле, үткен каләмле Мирсәй ага Әмирнең Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе булып эшләгән чагы. Шунда Мәскәүдән бер язучы-түрә килеп төшә. Һәм аның күзе Мирсәй Әмирнең башындагы искерә башлаган бүрегенә төшә.

– Нигә сез менә шундый шәп бүрек алып кимисез, Мирсаяф Масалимович? – ди ул, үзенең башындагы ондатра бүрегенә ымлап.

Мирсәй ага елмаеп, әйтә:

– 500 сумлык бүрек киеп кенә биш тиенлек башның бәясе артса икән аның... – ди.

"Мать"мы, "мат"мы?

Шәйхи ага Маннур шахмат уйнарга тотынса, бөтен дөньясын оныта. Аны шахмат тактасыннан кубарып алу мөмкин булмаган бер эш иде. Әмма ул бервакыт башлаган уенын тәгәлләмичә торып китә. Юк, бу көрәш кырын ташлап китү булмый, сәбәп башкада. Хикмәт шунда ки, аның уендашы, урыс телендә язучы бер татар журналисты һәр йөреше саен "Мать!", "Мать!" дип һаман ямьсез сүзләр кыстыра икән. Шәйхи ага моңа түзеп-түзеп утырса да, ахыргача тәкате җитми. Аяусыз селтәнеп, шахмат фигураларын туздырып ташлый да нечкә иреннәре арасыннан мондый сүзләр кысып чыгара:

– Һаман "Мать!" та "Мать!" Юк! Мин мондыйларга мат куйганчы уйный алмыйм, бигайбә!

Шәйхи-шахматчы тормышында беренче тапкыр ахыргача уйналмаган партия булып кала бу уен.

Ислам һәм хатын-кызлар

Заманында Татарстан китап нәшриятында Ислам абый Беляев мөхәррир булып эшләде. Үз эшен җиренә җиткереп һәм яратып башкарганлыктан, нәшрият җитәкчеләре белән аның арасында аңлашылмаучылык яки низаг шикелле нәрсәләр булмаган иде. Әмма бер көнне ул директор бүлмәсенә бик дулкынланып килеп керә.

– Гарәф Низаметдинович, зинһар мине адәм көлкесенә калдырмагыз! – ди ул.

– Аңламыйм. Кем сине көлкегә калдыра әле? – ди директор.

– Перспектив планны сез раслагансыз бит. Күрмәдегезмени соң?

– Нәрсәне күрергә тиеш идем соң мин? – ди директор тәмам аптырап.

– Соң... соң, анда "Ислам һәм хатын-кызлар" дигән китап та бар бит.

– Ну, булса ни?

– Соң, аны бит монда бөтенесе минем белән нәшрият хатын-кызлары арасында булган хәлләр дип аңлаячак, көләчәк!

Гарәф Шәрәфетдинов, Ислам Беляевнең гаҗиз кыяфәтенә карап, көлеп җибәрә. Аннары:

– Ярар алайса, бар, әйт баш редакторга, китапның исемен "Дин һәм хатын-кызлар" дип алыштырсын, – дип, Ислам абыйны тынычландырып чыгарып җибәрә.

Чәче шәп!

Озын итеп чәч үстергән бер шагыйрь трибунадан чыгыш ясый.

– Ну баш моңарда! – ди тыңлап утыручыларың берсе.

Моны ишеткән Мөдәррис Әгъләм әйтә:

– Башы бардырмы, юктырмы, белмим, әмма чәче шәп!

Иң зур поручение

Тукайның түгәрәк юбилеена әзерлек барган көннәрдә Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе бүлмәсенә бүрек асты җылынган бер шагыйрь килеп кергән дә:

– Туфан Абдуллович, бәйрәмне каршылаганда миңа да берәр поручение бирегез әле, – дигән.

Туфан Миңнуллин әлеге шагыйрьнең шактый таушалган кыяфәтенә күзлегенең калын пыяласы аша карап алган да әйткән:

– Иң зур поручение, энем, шул сиңа: Тукай юбилее көннәрендә бу тирәдә буталып, эшләргә комачаулап йөрмәскә! – дигән.

К.МАЛЬЦЕВ рәсеме ("КП").

Дүртьюллыклар

***
Яшьлек мәхәббәтен онытырга
Мөмкин түгел икән һич кенә. -
Хатын-көнче синең исемеңне
Гел төшереп тора исемә.

***
Тормыш шундый: җил-давыллы
Дәрьядагы кебек,
Чиста агым тирәндәрәк,
Өскә чыга күбек.

***
Әдәби телдә – тигәнәк,
Ә мишәрчә – кырмавык.
Яшьлектә барыбер иде -
Арасында кызлар кочтык,
Кырмавык дип тормадык.

***
Акыллы буласың килсә,
Бер киңәш бирим, тыңла:
Өйлән син... җүләр хатынга,
Шул утыртыр акылга!

***
Үзгәртеп корулар, дисең,
Ни ул үзгәртеп кору?
- Үзгәртеп кору шулдыр ул -
Уртак йортны җимерү һәм
Үзеңә ташып тору.

***
Элек читкә картын җибәрмәде,
Ул вакытта син бит чибәр, яшь...
Хәзер инде картың җибәрсә дә,
Каһәр төшкән картлык җибәрмәс...

***
Элек дәшми-тынмый яшәдек,
Инде
Өйрәндек без сөйләп яшәргә.
Һәм өйрәндек кулыбыз белән түгел,
Телебез белән борчак чәчәргә.

***
Бер шагыйрьнең шигырьләрен
Укыдым. Бетте күзләр.
Соңра калды исемдә тик:
"Диңгез буе. Иҗат йорты.
"Күктүбә..." – дигән сүзләр.

***
Начальник булуның шунысы начар,
Картаясың җәяү йөрмичә.
Начальларнең күбесе үлеп китә
Чын дусларын хәтта белмичә.

***
Арзанлы күлмәгеңне ки
Мәрмәрдәй яшь тәнеңә.
Картайгач, хөллә кисәң дә,
Гүзәл булырмын димә.

***
Зәңгәр күзләр – зәңгәр ялкын,
Кара күзләр – кара күмер.
Шулар ялкынында янып,
Үтте дә китте гомер.

***
Үзен белдеклегә санап,
Белгәннең тетмәсен тетә. –
Хакимне тәнкыйтьләп кенә
Хаким булып булса икән!

***
Дөбер-шатыр күкрәп килде болыт,
Тик яумады, китте җилләр куып,
Кем буш вәгъдә бирә урык-сурык,
Күренә шундый кысыр болыт булып.

Бер сорауга – бер җавап

Мәсгудә ШӘМСЕТДИНОВА, композитор:

– 1997 ел минем өчен гел сәфәрләрдән генә торды кебек. Миңа Ирландия, Норвегия, Швеция халыклары фольклоры, авыз иҗаты белән танышып йөрү насыйп булды. Кайда гына йөрсәм дә, туган халкымның моңы күңелемнән китмәде. Чит халыклар җырларын тыңлаганда үзеннән-үзе чагыштырулар ясала: безнең татар көйләре һич тә Аурупа халыкларыныкыннан ким түгел, киресенчә, үзәкләрне өзәрдәй моңы, ә кайвакыт дәртле ритмнары белән күпләрне сокландыра, дигән нәтиҗәгә киләсең. Әмма ни кызганыч, шушы уртак байлыгыбызга җитди мөнәсәбәт юк, халык көйләрен язып алып, эшкәртеп, дөньяга чыгарырга омтылыш сизелми. "Кара урман"нарыбызны, "Тәфтиләү"ләребезне дөньяга күрсәтеп, лекцияләр укып йөрердәй кешебез, белгечләребез булмавы бик кызганыч. Иң аянычы шунда – аларны әзерләргә тырышу, шуның хәстәрен күрү дә юк.

Чит илләрдә йөргәндә тагын бер нәрсә күзгә ташлана: Аурупада балалар тәрбияләү искиткеч югары дәрәҗәгә куелган, һәр бала президент булам, дип үсә. Бездә исә бала бик кысынкы шартларда тәрбияләнә, кимсенеп, мескен булып яши. Бала тәрбиясе белән шөгыльләнергә атаның да, ананың да вакыты юк – алар иртәдән кичкә кадәр эштә. Физика, химия, математика, астрономия буенча чит илләргә бәйгегә барып лауреат исеме алып кайткан өчен мактыйсы урынга, бездә баланы бәрәңге күп чүпләгән дип күккә чөеп үсендерәләр.

Мин авылларга еш чыгам, татар балаларының басынкылыгын күреп җаным әрнеп кайта. Үзенең татарлыгы, милләте, аның уңышлары белән горурлана белгән балалар юк дәрәҗәсендә. Бу бик тә, бик тә кызганыч. Ә бит болар барысы да бишектән тәрбияләнә барырга тиеш.

Китап күңел үстерә

Нәшрият күчтәнәчләре

Яңа ел табынында Татарстан китап нәшриятының ни катнашы бар, аннан ни "алма", ни "ярма" диярсез. Чү, каты бәрелмәгез! "Пар алма", "үстереп" бирдек без бәйрәм өстәленә, "Кызыл розалар" да бүләк иттек. Яңа ел табынына йолдызлы күктә йөзүче "Тулган ай" да (Әхсән Баян) нәшрият күчтәнәче. Күп инде алар, шулай да сезне иң сөендергәне "Күңелдәге җырлар" булыр, мөгаен. Нәни генә бу китапчыкны без махсус табын әзерләп тупладык. Тукта, без әйтәбез, күңелгә-телгә иң башлап нинди җырлар килә икән. Берәвебез "Татар ашлары" альбом-календареннан өйрәнеп пешерелгән ризыкларны кисә тора, икенчеләребез авыз итә, өченчеләребез бербер арты җыр башлый. "Айдар Галимов"ка (мөхәрриребез Илшат Хәлиуллин (тавышы, йөзе-кыяфәте, үзүзен тотышы белән яраткан җырчыбызның нәкъ үзе инде) кушыла һәм өздереп баянда уйнап җибәрә. Ә мин үзем шушы җырларны шыпырт кына теркәп бардым. Менә дигән җыентык килеп чыкты. Яңа ел табынында күпләр кулында шул китап булгандыр, дип уйлыйм.

Әлбәттә, Татарстан китап нәшрияты узган елны җырлап кына утырмады, милли әдәбиятыбыз хәзинәсен тулыландыру җәһәтеннән Мөхәммәдъярның "Нуры содур", Кол Шәрифнең "И күңел, бу дөньядыр...", Ә.Кәримуллинның "Тел – милләтнең сакчысы", Р.Әмирханның "Иманга тугрылык", М.Хөсәеннең "Якты моң", И.Юзеевнең "Уйлый күңелем төрлесен" һ.б.ш. дистәләгән саллы-саллы китаплар чыгарды.

Быел исә нәшриятыбыз эшчәнлегендә мәшһүр язучыбыз Гаяз Исхакыйның тууына 120 ел уңаеннан аның хезмәтләре төп урын алачак. Шул ук вакытта, еллык план нигезендә, укучыларыбызны балалар әдәбиятыннан, Әмирхан ага Еники, Шәүкәт Галиев кебек бүгенге заман әдипләре иҗатыннан да авыз иттерергә исәп тотабыз.

Шушындый махсус сәхифәдә катнашудан файдаланып, тагын шуны әйтер идем: әдипләргә, шагыйрьләргә бай халык без. Кат-кат басылган әсәрләрен туплаган калын-калын китаплары белән түгел, ә укучыларыбызга аларның өрьяңа әсәрләреннән торган кечерәк, әмма матур-матур басмаларын тәкъдим итәсе иде. Көттерәсе түгел иде аларның чал юбилейлары җиткәнен. Бер шагыйрь урынына бишесен сөендерәсе иде. Китапларның бәяләре дә укучыны куркытмас иде. Шигърият сөючеләр даирәсен киңәйтер идек. Шигърият белән янәшә атласак, киләчәгебез өметле булыр, ягъни әле дә булса хәвефле көннәр кичергән нәшриятыбыз сакланып калыр, иншалла.

Язилә АБДУЛКАДЫЙРОВА,
Татарстан китап нәшриятының сәнгать бүлеге мөхәррире.

Язилә Абдулкадыйрова



Вахит ИМАМОВ,
Чаллы язучылар оешмасы җитәкчесе:

Таудай таләбең булганчы, түмгәктәй эшең булсын

Яңа ел күчтәнәчләре нинди дисезме? Төрлесеннән әзерләргә тырыштык инде. "КамАЗ" гәзит-китап нәшрияты оешканда ук өч юнәлештә эшләүне максат итеп куйган иде: язучылар әсәрләрен, тарихи китапларны һәм дәреслек, уку-укыту әсбаплары, методик кулланмалар бастырып чыгару. Шул күзлектән караганда, иң шәп, иң кызыклы, иң тәмле куян күчтәнәчләрен балаларга өләштек. 1 нче сыйныф укучылары 1 нче сентябрьдә кулларына "Өмет" дигән китап алдылар. Альтернатив нигездә төбәк авторлары әзерләгән "Әлифба" буенча укырга өйрәнделәр. Урыс телле балалар өчен "Татар теле" китабы да бар, шуңа күрә алар матур итеп татарча сөйләшә беләләр. Чаллы мәктәпләренең күбесе алдынгы метод, Рәхимов методы буенча эшли. 3 нче сыйныф өчен "Математика" шул концепциягә нигезләнеп басылды. Алабуга, Чаллы пединститутлары галимнәре әзерләгән дәреслекләр, алдынгы мәктәпләрнең эш тәҗрибәләре дә дөнья күрә. Барлыгы 40лап китап басылып чыкты.

Тарихи китапларга килсәк, Равил Фәхретдинов, Дамир Исхаков, Локман Закиров һ.б авторларның китаплары игътибарыгызны җәлеп иткәндер инде. Ә менә Рафаэль Бәзертдиновның "Татары, тюрки — потрясатели вселенной" дигән өч китабы яңа ел алдыннан дөнья күрде. Бу хезмәт — авторның зур уңышы.

Чаллы язучылар оешмасында 21 язучы бар. Арада иң өлкәне — Нәҗип ага Мадъяров.Быел аңа 70 яшь тула. "Көлке көлтәсе", "Әптән Гәрәе мәзәкләре", "Кара аккош", "Ай яктысы", "Әби күзлеген эзли" һ.б. китаплары янына "Җырлап яшик, дусларым" да өстәлде. Кадыйр Сибгатуллин матур келәмдәй тукылган "Намазлык" китабын күрә алмый китеп барды. Уразада аны бик яратып кабул итәрләр, шөт. Мәрхүм Ямаш Игәнәй рухына да дога кылырбыз. Мәхмүт Газизов шигырьләре дә Яңа ел табынын бизәр, дигән өметтә калабыз.

Менделеев, Әлмәт, Сарман, Түбән Кама, Алабугада яшәп иҗат итүче авторларның да күңелләрен күрергә тырышабыз. 1991 елдан алып ел саен ким дигәндә 7-8 китап дөнья күрә.

Ярты ел элек мине Чаллы язучылар оешмасы җитәкчесе итеп сайладылар. Шул уңайдан иң зур шатлыгыбызны сезгә дә җиткерим әле: быел мэрия безнең бинага 300 миллионга (яңача 300 мең) төшереп ремонт ясатачак. Һәм Яңа елда Рәфкать әфәнде Алтынбаевка рәхмәтебезне, иң изге теләкләребезне ирештерәбез.

Бина юкны сылтау итеп кул кушырып утырмадык, әлбәттә. Данис Хәбибуллин, Николай Алешков, Факил Сафин, Заһирә Гомәрова һ.б. язучыларның юбилей кичәләрен уткәрдек. Айдар Хәлимнең "Гомеремнең ун көне" дигән яңа китабын тәкъдир итү дә байтак кешеләр күңелендә матур истәлек булып сакланадыр.

Разил Вәлиев, Газиз Кашаповлар заманында биредә "Ләйсән", "Орфей" әдәби берләшмәләре гөрләп эшли иде. 4-5 ел элек алар таркалды. Иң беренче булып шул берләшмәләр эшен җайга салдык. Айдар Хәлим — "Ләйсән", Николай Алешков "Орфей" берләшмәләрен җитәклиләр. Чаллы пединститутында әдәби түгәрәкне Факил Сафин җитәкли, ә "Көмеш кыңгырау" гәзите (мөхәррире Нәсимә Садыйкова) укучы балалар иҗатына җитди игътибар бирә.

Инде Казан, Яшел Үзән һ.б. төбәкләрдә яшәп иҗат итүче авторларга мөрәҗәгать итәбез. Күңелебез киң — рәхим итегез, сезнең китапларыгызны да чыгарырга булышырбыз. Язучылар башына төшкән афәт китапларның тамырына балта чапты — хәзер китап чыгару нигездә түләүле. Әмма бездә ул өч тапкыр арзанрак. Бер мең тиражлы китап чыгару өчен табагына — нибары мең сум акча түләргә кирәк.

Килегез, көтәбез!

Татарстан Милли банкы рәисе Евгений Богачев телефоннан сөйләшә. Билгеле инде, аннан акча сорыйлар.

– Юк, күп бирмим, – ди Евгений Борисович. – Без монда уйлашырбыз да хәл итәрбез. Кисәтеп әйтәм, күп бирмим. Өч-дүрт миллион һәм – вәссәлам!..

...Бүгенге хезмәт урынына беренче адымны Татарстанның баш банкиры әле элекке СССРда базар сүзе телгә дә алынмаган чакта ук ясады. Урманда, ау вакытында булды бу. Нәкъ менә шушында кыйммәтле финанс кәгазьләренең кеше тормышында никадәр мөһим булуын аңлады ул:

Евгений БОГАЧЕВ: Акчаны сак тотарга кирәк

– 20 ел элек кулыңда лицензия булмый торып ауга чыгу турында уйларга да ярамый иде. Судка илтә торган хәтәр адым иде ул. Артыңнан күзәтүче йөри – егерь, ау барышы өчен җаваплы кеше. Берзаман без дустым һәм, әлбәттә инде, әлеге егерь белән урманга киттек. Машина капотына өйдән алган коры-сары ашамлыкны таратып салдык, ау алдыннан күп эчәргә ярамый – бер-ике йотым аракы эчтек. Һәм... китте ау. Этләрне җибәрдек, "загон"га куабыз. Ауның иң кызган чагында егерь сорап куймасынмы:

– Туктагыз әле, рөхсәт кәгазегез (лицензия) бармы соң сезнең?

Лицензия миндә иде. Әмма минем дус өлгеррәк булып чыкты: кесәсеннән бер язу алып күрсәтә бу. Егерь карады да әйтеп куйды: " Әһә, ярар, кәгазь булгач, эш икенче..."

Дуска әйтәм:

– Рөхсәт язуы миндә бит, син аңа ни күрсәттең?

Көлә бу:

– Табиб биргән кәгазь – эштән авыру сәбәпле азат булуым турындагы белешмә. Егерьның грамотасы шуның кадәр генә, кәгазьләрнең төсләре охшаш бит...

Кәгазьдән башка бер эш тә бармый.

– Аучы трофейларыгыздан иң истәлеклесе нинди иде, хәтерләмисезме?

– Лаеш районында ауга чыкканыбыз хәтергә уелып калган. Охотовед Анатолий Иванов – җирле Дерсу Узала белән бергә киттек. Кабанны табу кыен, ул азык эзләп, уннарча чакрым йөри, бүген монда, иртәгә – икенче урманда. Шулай да эзе белән чыктык бит кабанга. Аланда ята бу. Мин тизрәк карабинны алдым. Кабан начар күрә, әмма исне зәһәр сизә. Сизде бит кеше исен. Мин туры башына аттым. Тиде, егылды кабан. Ята. Киттек карарга. Мин карабинны җилкәгә астым, нидер сөйлим. Кабан янына 4-5 адым калгандыр, кинәт күрәм: бу ипләп кенә аякларын җыя һәм... минем өскә сикерә. Без аны үлде дип уйлаган идек бит.Мин карабинны җайлап та өлгермәс идем, аучылар мәргәне Анатолий күз ачып-йомганчы атып җибәрде. Кабан аягым янына ук килеп ауды. Шәп кабан иде, һич хәтердән чыкмый.

– Кызык, аучы белән банкир хезмәте арасында уртаклык бармы икән?

– Бар кебек. Мәсәлән, саклык тегендә дә, монда да кирәк. Ә болай банкир эше ул шахматка якынрак: 2-3 йөрешне алдан ук уйлап куярга кирәк. Шулай булмаганда, таратырсың акчаңны – җыеп ала алмассың.

– Кем соң ул банкир? Шахмат тактасындагы пешкамы, ферзь яки филме?

– Банкирлар – авыр фигуралар. Бөтен мәгълүмат бездә. Бүгенге статистика органнары да без белгәнне белми. Банкирлар республикадагы һәм Русиядәге хәлләрне – реаль чынбарлыкны үз кулларында тоталар. Кайчак бездәге мәгълүматлар рәсми мәгълүматлардан шомлырак, ә кайчак – яктырак булалар. Дөресен әйтим, без бүген тоннель очында яктылык күрәбез.

– Акчасы күп кешеләргә нинди киңәш бирер идегез?

– Акчаны тотарга кирәк. Җитештерү предприятиеләренә кулланырга, эш урыннары оештырырга. Аракы эчү, гыйш-гайрәт, кирәккәннән артык зиннәткә тотып "яндырмаска", акыл белән, алга карап фикер йөртергә. Акча... бер аркан борылса, аны кире җыю авыр.

– Сезнең "хобби"егезне дә беләсе килә. Банкирлар тимер акча җыялардыр инде, коллекционерлардыр...

– Алай түгел. Мәсәлән, минем коллекциямнең эшемә бер катнашы да юк. Дөрес, сирәк һәм борынгы акчалар бар миндә. Хәтта уч зурлыгындагы 100әр сумлык ике көмеш акчам бар иде. Русия Үзәк банкы аларны нибары мең данә генә чыгарды. Ләкин икесен дә бүләк иттем. Минем коллекция шундый инде – килә дә китә. Чит ил банкирлары килгәндә нәрсәдер – гадәти булмаган сувенир кирәк бит.

– Банкир буларак, Сезнең өчен кәгазь акча бәялерәкме, металл акчамы?

– Банкир буларак, мин карточкаларны уңайрак күрәм. Ләкин аларның үз уңайсызлыгы бар. Хәтта Көнбатышта да. Анда, мәсәлән, ресторанда карточка белән исәп-хисап ясарга уйласаң, йөгерешә башлыйлар, банкка шалтырататалар, тикшерәләр...

Евгений Богачев үз хезмәте белән бәйле булган бик күп мәзәкләр, төрле кызык хәлләрне хәтердә тота. Шуларның берсе мондый: Украина колхозларының берсендә мужик склад мөдире булып эшкә урнашырга килә. Аңа әйтәләр:

– Хезмәт хакың 60 сум булачак....

– Ярар, мин риза.

– Гариза яз.

– Мин язарга оста түгел бит. Саный беләм, яза белмим.

– Алайса, эшкә алмыйбыз.

Утыз еллап үткәч Нью-Йорк шәһәрендә бер бай кеше бриллиант муенсага карап тора. Йөз мең долларлыгын сайлап ала бу, акча саный. Кассир гаҗәпләнә: "Гафу итегез, сумма зур, чек кына язып бирегез". Сатып алучы җавап бирә: "И, мин яза белмим бит, колхозда кладовщик булып эшләдем!.."

("Конец недели").

Бер сорауга – бер җавап



Мөдәррис ӘГЪЛӘМ, шагыйрь:

– Узган ел минем өчен киләчәк турында кайгырту һәм "Яңа гасырга кем булып керәбез?" – дигән сорауга җавап бирергә теләүчеләрнең күбәюе белән истәлекле булды. Чаллыга баргач, бернәрсәгә сөендем – ул да булса, мәктәпләрдә, гимназияләрдә, көллиятләрдә һәм пединститутта булган очрашуларда миңа гел шул сорауны бирделәр һәм татарча бирделәр. Казанда булган очрашуларда, Тукай музеенда, Горький музеенда, "Казан" милли мәдәният үзәгендә булган очрашуларда да сорауны киләчәк турында бирделәр. Андый сорау бар икән, димәк, киләчәгебез бар. Киләчәк турында сорыйлар икән, димәк, үткәнебезгә битараф булмаячак халык. Үгез елы мине шуның белән сөендерде. Ә Юлбарыс елы – үзебезнең акбарыс елы булсын иде!..

Галия ХАНТИМЕРОВА, филология фәннәре кандидаты, тәрҗемәче (Мәскәү шәһәре):

– 1997 ел нәтиҗәләренә килгәндә, мин, тулаем алганда, канәгать. Беренчедән, гаиләбездә татулык хөкем сөрде, барыбыз да исән-сау булдык. Аннары Мәскәүдә якшәмбе мәктәбе урынына даими рәвештә татар мәктәбе эшли башлавы да бик сөендерде. Бу бик әһәмиятле вакыйга, чөнки, иманым камил, сабыйларны кечкенәдән тиешенчә тәрбияләп кенә татар телен, татар мәдәниятен саклап була. Тагын бер мөһим вакыйга: Мәскәү татарлары общинасы гәзите – "Татарские новости" хәзер айга бер түгел, атна саен чыгып барачак һәм анда татар телендәге язмаларга да урын биреләчәк.

Тагын бер шатлыгым: ноябрь азагында "Азатлык" радиосы мин әзерләгән "Хатын-кыз сәясәтче була аламы?" исемле тапшыруны бирде, аны бөтен дөнья тыңлады. Әйтергә кирәк, татар хатын-кызының җәмгыятьтә билгән урынына искечә карау әле дә булса гадел законнар эшләүгә комачаулый, ул законнар күбесе ир-атлар мәнфәгатьләрен күздә тотып кабул ителә. Ә бит хатын-кыз бала табу, ирен тәрбияләүгә генә сәләтле дип уйлау зур хата.

Таныш булыгыз: Динә ӘХМӘТ

Бусага

1. XX гасырны озатканда

Төнлә чыгып урман чатларына,
Күтәп торам гасыр азагын.
Капка бикле, әле өч еллап бар,
Кушме каерсаң да кадагын.

Зур урамнар буйлап үтәм төнлә,
Шәһәр тыкрыклары буйлап та.
Узган гомер азагында шулай
Кемнәр йөрде икән Болакта?

Күпер катларына килеп басам,
Күрергә дип күктә кичкырын
Гасыр белән гасыр ялганганда
"Кыска ялгану"лар очкынын.

Чыгып басар өчен мәйданнарга
Төнлә туган булу тиешме?
... Көпә-көндез гасыр азагында
Сугышулар бер дә килешми!..

Саклык белән гасыр капкаларын
Шакып карыйм – әле иртәдер.
... Ай тирәли әйләнергә теләп,
Безнең уйлар очып китәдер...

Учларымны сузам зур галәмгә,
Әллә анда... күзләр дерелди.
Җиһан серен чишү беркемгә дә
Бирелми шул җиңел, бирелми.

Гасыр капкаларын кемнәр шакый,
Бармы икән әйтер сүзләре?
Сынап карап тора төнге күктән
Гасыр азагының күзләре.

2. XXI гасырга аяк басучыларга

Бусаганы атлап кергән чакта,
Барча адәмнәргә таләп бер:
Узган гасыр тузаннары кунган,
Өс-башыңны бераз кагып кер!..

Исәнләш син аннан үз телеңдә,
Гасыр әле яшь-яшь булса да.
Хаҗәте юк рәсми кәгазьләрнең -
Һәркем атлап узар бусага.

Нәфрәтегез ничә мегатонна,
Тавышыгыз ничә децибел?
Кем булсаң да чама белү кирәк,
Татармы син, яки федерал.

Яхшы белсәң иде тик өч сүрә,
Төгәл фәннәр, тарих, икътисад...
Ә фикерең саллы булсын иде,
Актуаль һәм полипредикат.

Бу гасырда булыр гармония,
Әйткән сүз һәм эшнең синтезы.
Мин – малае булсам әдәплекнең,
Әхлак законының син – кызы.

Тикшергәләр өчен геннар кодын
Потенциаль көчең җитәрме?
Менталитет, үзаң, традиция,
Үсеп, чәчәк атып китәрме?

Ап-ак карлар явып үтер ул төн,
Өч-дүрт айдан эреп таралыр...
Бу гасырда синең йөрәккәең
Кемнәргә соң булыр параллель?

Бик тә кирәк акыл, белем плюс
Сәламәтлек дигән ассорти.
Бу гасырда яшәр кешеләрнең
Уңай биотоклы шәп сорты ла,
Гөрләп торыр бәхет аккорды!

3. Яңа гасырның беренче көне

....
....

● Динә ӘХМӘТ Татарстанның Актаныш районында туган. Казан дәүләт университетын тәмамлаган. Хәзер Чабаксар шәһәрендә яши. Шигырьләр язу белән берәттән, проза өлкәсендә дә каләмен сынап карый.

Президент атлары

Татарстан Президенты М.Шәймиев, атларны бик ярата, дип сөйлиләр. Янәсе, аның шәхси ат абзарында дәүләт хисабына яшәүче 30лап гарәп чабышкысы бар икән. Хайваннарны ярату әйбәт анысы, тик акча бүгенге көндә кешеләргә кирәгерәк түгелме?

М.СТЕПАНОВ.
Ижау.

Билгеле булганча, Татарстанда Президентның ат көтүе дигән сүз гомумән юк. Күпләр аңа ат бүләк итсәләр дә, алар барысы да дәүләтнеке исәпләнә. Шулай булгач, билгеле инде, алар турында хөкүмәт кайгырта.

Минтимер Шәймиевкә бүләк ителгән атларның күпчелеге Казан ипподромының ат абзарларында тотыла. Бүген аларның саны алтыга җитте. Болар – Казакъстан Президенты бүләк иткән нәсел айгырлары Хуш Килде һәм Нурлы, Э.Россель бүләк иткән Орлов токымлы ат Кузбасс, Р.Аушев тарафыннан бүләк итеп бирелгән чиста меңге токымлы Олимп, шулай ук күрше Мари Иленнән йөк ташучы ат Журавушка, Чуашстаннан – Танечка кушаматлы пони.

Атларга ипподромда тик кенә ятарга ирек бирмиләр. Республика көнендә Н.Назарбаевның Хуш Килдесе, Шәймиевне һәм үз җайдагын сөендереп (призга "Ока" бирелде), үз токымындагы атлар арасындагы чабышта җиңүче булып калды. Шәймиев атлары башка узышларда да катнашалар.

Итекләрдә кояш җылысы

Әбием кечкенә чагымда миңа киез итекләр кидертә, ул саулык өчен әйбәт, дип әйтә иде. Бу дөресме?

К.КОКОШКИН.
Пермь.

Әбиегез хаклы. Галимнәр, 12 яшенә кадәр генә булса да киез итек киеп йөргән бала сабый чагында салкын тиюләргә бирешми, дип исбатлады. Андый кешегә балигъ булгач, импотенция куркынычы да янамый. Йоныннан киез итекләр басыла торган тәкә ир-ат көчен һәм җенси потенцияне белдерә. Киез итекләр өлкәннәрне ревматизмнан саклый. Йонның дәва һәм җылылык бирү чыганагы нәрсәдә соң?

Фаразларның берсе буенча, сарык йоны үскәндә үзенә кояш җылысын сеңдерү үзлегенә ия. Моннан тыш, киез итекләр өчен тере сарыктан кыркылган йон гына кулланыла.

XVIII гасырда киез итек бигрәк тә кыйммәтле һәм абруйлы аяк киеменнән исәпләнгән. Петр Беренче махмырдан чыкканда киез итекләр кия торган булган: сарык йоны аякларын җылыткан, кан тамырларын киңәйткән, кан әйләнешен яхшырткан. Екатерина Икенче үзенә махсус чүсинкә бастырган. Совет җитәкчеләре Ленин, Сталин, Хрущев та бу аяк киеменең кадерен белгәннәр. Бүгенге җитәкчеләргә килсәк тә, югары урында утыручының һәр өчесенең берсе ауда, дачада киез итекләр кия.

Безнең солдатлар гомер-гомергә киез итекләрдән йөриләр. Фин сугышында җиңелүнең төп сәбәбе дә киез итекләр җитмәүдән иде, дип сөйлиләр. Наполеон белән Гитлерны да без киез әйберләр җитәрлек булганга күрә җиңдек.

Минем хокукым юкмыни?

Миңа 13 яшь, бала көтәм. Зинһар өчен мине гаепләмәгез. Минем баламны табасым килә, әтисен дә яратам. Аңа 17 яшь. Хатын-кызлар консультациясе табибе миңа, баланы табу-тапмау, аборт мәсьәләсен минем өчен әти-әни хәл итәргә тиеш, диде. Бу нинди ахмаклык инде? Ул бит минем бала. Минем бернинди хокукым да юкмы икәнни?

Марина.
Чаллы.

Табиб хаклы. Ана булу турындагы мәсьәләне сез 14 яшьтән генә үзегез мөстәкыйль хәл итә аласыз. Сөйгәнегезгә хисләрегез ихластан булса да, бу адымны ясауга бик җитди карарга һәм әти-әниләрегез белән киңәшергә кирәк. Соңгы чиктә сезне матди яктан нәкъ менә алар тәэмин итәчәк бит. Моннан тыш, бары тик әти-әниегез генә сезнең бу җаваплы эшкә әзер яки түгел икәнлегегезне белә. Сезнең физик хәлегез дә әһәмияткә ия. Әти-әниләрегез бу очракта да сезнең өчен җаваплы.

Иң изге сәфәр

Быел теләгән һәр кеше Мәккәгә хаҗ кылырга бара алырмы икән?

М.МИҢСАФИН.
Чабаксар.

Узган ел Русия 20 мең хаҗ кылучыга норма билгеләгән иде. Әмма Мәккәгә 16 мең кеше генә бара алды. Күп кенә мөселманнарның Исламның изге урыннарына барырга акчасы җитмәде. Быел исә Русия тарафыннан хаҗга баручылар саны 18 мең итеп билгеләнде.

Әмма 1998 елда хаҗ кылучылар санын норма түгел, ә бәлки аларның матди хәле билгеләр, дип уйлыйбыз.

Салымнар да камилләшә

Керем салымын түләү киметелә, дип сөйлиләр. Моңа ышанасы да килми. Бәлки, сез бу турыда аңлатып язарсыз.

Г.ХӘКИМОВА.
Шәмәрдән бистәсе.

Әйе, быел Русия Федерациясендә керемгә салым бераз азрак булачак.

Үзегезнең еллык керемегезне исәпләп карап, күпме керем салымы түләргә тиешлегегезне чамалагыз.

20 миллионга кадәр 12 процент.
20дән – 40 млн.га кадәр 15 процент.
40тан 60 млн.га кадәр – 20 процент.
60тан 80 млн.га кадәр 25 процент.
80нән 100 млн.га кадәр 30 процент.
100 млн.нан артса 35 процент.

Билгеле, бу саннарда деноминация исәпкә алынмаган. Шулай да деноминациядән соң да шундый керем насыйп итсә, шәп булыр иде бит.

Амнистия. Ул кем өчен?

Амнистия була икән, дип ишеткән идем. Ул кайчан гамәлгә керер икән?

С.МИХАЙЛОВА.
Мамадыш.

Шактый шау-шу куптарган амнистия проекты Дәүләт Думасында беренче укылыш стадиясен узды. Һәм яңа елда, мөгаен, рәшәткә артында җәфа чигүчеләргә, авыруларга ирек бүләк итәрләр. Әмма проектны җентекләп өйрәнгәндә, гаҗәпләнми мөмкин түгел.

Башта, гадәттәгечә, амнистиягә эләгә торган тоткыннарның категориясе тасвирлана. Анда инвалидлар, ветераннар, балалы хатыннар саналып үтелә. Аннары җәза үтәү вакыты кыскартылырга һәм шулай ук җинаять эшләре һәм суд процесслары алып бару туктатылырга тиешле кешеләрнең категорияләре күрсәтелә. Иң ахырдан җинаять кодексының амнистиягә эләкми торган маддәләре исемлеге бирелә.

Бу җәһәттән 7 нче пунктның "Г" өлеше аеруча сәер булып күренә. Үзегез уйлап карагыз: "Суд, әлеге карар үз көченә кергәнче кылынган һәм аның өчен өч елдан артык вакыт иректән мәхрүм итү җәзасы каралган җинаять эшләре буенча иректән мәхрүм итүгә бәйле булмаган җәза бирүнең кирәклеген таный икән, хөкем ителүчене җәзадан азат итә". Моны гадәти телгә тәрҗемә итсәк, ул мондыйрак мәгънә аңлата: хәзерге вакытта тикшерү һәм суд стадиясендә булган уртача авырлыктагы һәм авыр җинаять эшләре буенча суд үз ихтыяры белән гаепләнүчене җәзадан азат итәргә хокуклы. Башкача әйтсәк, суд кына, бары тик суд кына, җинаятьнең авыр яки җиңел булуына карамастан, җәзадан азат итү турында карар кабул итә. Хәзер амнистиягә кайсы маддәләрнең туры килмәвен карыйк. Биредә, табигый ки, кеше үтерү, бандитлык, талау, көчләү һәм башка авыр җинаятьләр. Ләкин бу исемлектә шактый гыйбрәтле статьялар юк. Аерып әйткәндә, 171 – законсыз эшмәкәрлек, 198, 199 – салымнар түләүдән качу, 285 – хезмәт урыныннан явызларча файдалану. 159 нчы статья – караклык, урлашу (мошенничество) турында өлешчә генә искә алына. Бу хәзерге вакытта бизнес, финанс махинацияләре, салымнар өлкәсендә аеруча киң таралган җинаятьләр амнистиягә эләгә яки ул коррупция белән тотылган кешеләргә кагыла дигәнне аңлатмый. Шулай икән, һәртөрле хәйләле пирамида коручылар ("МММ", "Чара", "Хопер", "Гранд-траст"), ялган аракы җитештерүчеләр һәм башка кыек эшләр башкаручыларга, шулай ук югары урындагы чиновникларга, экс-прокурор Алексей Ильюшенкодан алып күптән түгел генә кулга алынган Валерий Сидоровка кадәр – төрмәдән качарга искиткеч зур форсат туа. Бары тик судка аларны "амнистияләвен" генә көйләргә кирәк.

Казан Мәскәүдән өлкәнрәкме?

"Казанның кайчан салына башлавын ачыклаучы акчалар табылуы турында ишеткән идем. Шул турыда ачыграк язсагыз иде.

М.ЗАКИРОВ.
Кукмара.

Фәнни концепцияләрне кирелей әйләндереп куярлык табылдыклар, гадәттә очраклы рәвештә килеп чыгалар. Борынгы Троя хәзинәсе, 908-910 елларда Идел буе Болгарстанында сугылган беренче акчалар уйламаганда-көтмәгәндә Новгород өлкәсендә генә табылды. Быел шулай ук көтмәгәндә Казан Кремле биләмәсендә чех акчасы табылды. Аның Казанга нигез салыну вакытын XII гасырдан XI гасырга күчереп куюы бик тә ихтимал.

"Без бу акчаның табылуын бик озак көттек", – диделәр, Прага университеты галимнәре. Казан археологлары әлеге уникаль табылдыкның якынча килеп чыгышы турындагы соңгы җавапны киләсе елның гыйнварында алачаклар. Чехлар әлегә аның 1003 елга, ягъни XI гасыр башына кадәр сугылганын гына расладылар. Табылдыкның тагын бер үзенчәлеге бар – ул X гасырда чыгарылган чех акчаларыннан берденбер булып санала.

Акчаның әһәмияте чех нумизматикасында мөһим роль уйнауда гына түгел, билгеле. Акча әлегә беркайчан да өйрәнелмәгән, монгол чорына кадәрге булган катламда табылган. Бу чех акчасы белән бер үк вакытта икенче акча – гарәп дирһеменең дә яртысы табылган. Кызганыч, дирһәмнең сакланган өлешендә әллә ни мәгълүмат – сугылган вакыты һәм урыны, хакимлек иткән патшаның һәм хәлифнең исемнәре – юк. Әмма якынча экспертиза нәтиҗәләренә караганда, дирһәмне X гасырның беренче чирегендә сугылган дип билгеләргә мөмкин.

Әйтеп үткәнебезчә, бу акчаларның икесе дә монгол чорына кадәрге борынгы катламда табылган. Бу якынча X-XI гасырлар чиге. Аларны Президент сарае артындагы Казансу елгасына якын гына урнашкан калкулык сөзәгендә таптылар. Ихтимал, ул чорда анда сәүдәгәрләр күчеп утырган булгандыр. Әлегә археологлар табылган акчаларны һәм шушы ук катламдагы торак бинаны Казанның килеп чыгу вакытын билгеләү өчен файдаланып булу-булмавын анык кына белмиләр. Бернәрсә ачык: X-XI гасырларда Идел буе Болгарстаны белән Чехия арасында сәүдә мөнәсәбәтләре булган. Болгарларның тышкы элемтәләре күптармаклы булуын безнең элекке дәүләт тупрагында табылган Каролинг кылычлары да раслый. Аларның Аурупада 120 данәсе, борынгы Русь территориясендә – 16сы, шуның 8е болгарлар җирендә табыла.

Казанга нигез салынуны XI гасырга кертеп булу-булмавы турындагы төгәлрәк җавапны киләсе археологик сезон бирергә тиеш. Чөнки Казан кайчан нигез салынуы билгесез булган аз санлы шәһәрләрнең берсе. Димәк, ачышлар да әлегә алда.

Алсу ВӘЛИУЛЛИНА.
("Татар-Информ").

Әйе шул, 1998 елда без, ниһаять, Аллаһы боерса, "Исә Болгар җилләре" исемле кинокыйссасының беренче ике сериясен карый башлыйбыз. Икешәр серияле өч фильмнан торган бу кыйсса татар халкының, ул аралашып яшәгән халыкларның бөек үткәне хакында. Бүген без әлеге кыйссаның сценарий авторларыннан берсе – шагыйрь, прозаик һәм драматург Гәрәй РӘХИМ белән әлеге фильм турында сөйләшәбез.

– Гәрәй әфәнде, сүзне иң элек фильмның исеменнән башлыйк әле...

– Фильмның исеме, мөгаен, моннан ун ел элек тугандыр.

– ?!

– Моны, әлбәттә, мактану дип кабул итмәсләрдер. Минем нәкъ менә "Исә Болгар җилләре" дип аталган, китапларыма да кергән шигырем бар. Болгар иле турындагы шигырь иде ул. Шагыйрь Равил Бохараев аны "Теплые ветры Булгар" дип тәрҗемә дә иткән иде. Менә, күпмедер вакытлардан соң (фильмның исеме бәхәсләр дә уятканын беләсездер), без бу яңа фильмны җәмәгатьчелек каршына чыгарырга җыенабыз.

Исә Болгар җилләре...

– Бәхәс дигәннән, фильмның тууы бәхәсләр аша гына түгел, киртәкаршылыклар аша да үтте кебек. Тыюлар аша түгел, ә нәкъ менә каршылыклар аша.

– Безнең татарда шундый бер холык бар инде ул, юньле әйбер туа башласа, аны туганчы ук кыйнап үтерергә тырышабыз. Үз-үзенә шундый зур киртәләр куйган халык тагын бар микән? Менә бу фильмны куйганчы ук күпме киртәләр аша үтәргә туры килде. Мин үзем гомерем буе татар өчен, татар халкы өчен җан атып яшәгән бер кеше. Яздым, иҗат иттем, Татар шагыйрьләре антологиясен дә төзеп чыгардым, тарихи әсәрләр дә яздым. Һәм беләм: беркайчан да халкыма тап төшерерлек эш эшләмәячәкмен. Бу – минем яшәү асылым, иҗат кануным. Шуңа күрә, "Исә Болгар җилләре" фильм-кыйссасының сценарий авторларыннан берсе булуымны табигый бер хәл итеп карыйм, горурланам да хәтта.



– Сценарийны сез танылган кинорежиссер Булат Мансуров белән бергәләп яздыгыз. Укучыларыбызны, мөгаен, шул да кызыксындыра: бу хәтле материалны – ерак гасырлардан ук килгән тарихны ни рәвешле туплап өлгерә алдыгыз?

– Беренчедән, безнең халыкның тарихы бик бай, ул тарих төрле халыкларның елъязмаларында да, тарихи документларында да чагылыш тапкан. Борынгы ата-бабаларыбыз бик күп халыклар белән аралашып яшәгән. "Исә Болгар җилләре" фильмы бары тик Болгар чоры турында гына түгел. Бу фильм IV гасырдан (һуннардан ук алып) Болгар чорына кадәр булган вакыйгалар турында сөйли. Монда безнең бабаларның гына түгел, башка дәүләтләр, башка халыкларның да тарихы яктыртыла – шунсыз мөмкин дә түгел. Кыскасы, IV гасырдан алып, 1236 елга кадәр тарихны бары тик татар тарихы итеп кенә күрсәтергә теләмәдек тә. Чөнки, әйткәнемчә, татар халкы Евразиянең барлык халыклары белән бәйләнешкә кергән, бәйләнештә торган, аралашып яшәгән. Әнә шуларны, шул бәйләнешне күрсәтми торып, без татар халкы тарихын дөрес күрсәтә алмаячакбыз. Шуңа күрә дә, фильмда Евразия халыкларының уртак тарихы чагыла. Әлегә кадәр мондый тарихны әле беркемнең дә күрсәтә алганы юк иде. Ә инде сезнең сорауга төгәл җавап бирсәк, шунысын әйтик: безнең халыкның иҗтимагый, язма, тарихи-мәдәни байлыгы шулкадәр зур, ул материалны хәтта "эзләп" тә торасы түгел. Әллә ничә буын иҗатчылары, тарихчылары өйрәнерлек әле ул. Тарихи материалларга һич тә кытлык юк, аларны бер тәртипкә, системага гына салырга кирәк. Дөрес тәртипкә, дөрес системага.

Без нәрсәләрдән, ничек файдаландык? Турыдан-туры Мәскәүнең элеккеге Үзәк китапханәсенә, Ленин исемендәге Үзәк китапханәсенә, Казан дәүләт университе- китапханәгә, Татарстанның Милли ты китапханәсенә, мөрәҗәгать иттек. Без китапханәсенә мөрәҗәгать иттек. Без файдаланган тарихи материалларның исемлеген генә җыйсаң да, үзе бер китап булыр иде.

Икенчедән, Булат Мансуров – бик тә тәҗрибәле, талантлы режиссер, төрки халыклар турында бик күп фильмнар авторы. "Бейбарс" фильмын гына искә төшерик. "Төркмәнфильм"ның атасы – Булат Мансуров. Ул "Казахфильм"да да, "Үзбәкфильм"да да бик күп эшләгән, көч куйган кеше. Төрки халыкларның тарихын яхшы белгән, моңа гомерен багышлаган кеше. Аның белән эшләү җиңел, аңа "әлифба өйрәтеп" торасы юк.

Аннан соң, үзебезнең бик көчле, тирән белемле галимнәребез бар бит. Альфред Халиков кына да ни тора! Бар бездә галимнәр! Шулай ук фильмның рәссамы Горлик та бик белемле кеше, үзе рәссам, үзе зур галим. Мәскәүдә яшәүче рәссамыбыз төрки халыкларның атрибутикасын – киемнәрен, хезмәт һәм сугыш коралларын бик ныклап өйрәнгән. Хәтта кайсы чорда нинди бизәнү әйберләре, бизәк-орнаментлар, тәңкә-төймәләр булганын яхшы белә, үрнәкләрен үзендә саклый. Аның махсус остаханәсе бар, ул безгә нык ярдәм итте.

Башта без Болгар тарихын гына күрсәтмәкче идек. Фильмның исеме дә шуңа бер ишарә. Әмма, тора-бара, вакыйгалар да, чорлар офыгы да киңәйде. Фильм әнә шул IV гасырдан башлап, Болгар дәүләтенең чәчәк ату чорына кадәр сузыла. Ә инде монголларның Болгар дәүләтен җимерүе – монысы икенче бер тема, монысы яңа бер фильмны, трагедия жанрында эшләнгән фильм булуын сорый.

– Димәк, инде искәрткәнебезчә, "Исә Болгар җилләре"нең жанры трагедия түгел?

– Халык язмышы турында кыйсса дип әйтер идем мин аны. Фильмның исеме урысча ничегрәк яңгырар – әле худсоветта тикшерәсе бар. "Сага о древних Булгар" булырмы ул, әллә башкамы. Саго – төрки сүз. Сагыш, сагыну, саго – бер тамырдан.

Май аенда беренче ике фильмны күрсәтәчәкбез. Ләкин алар уртадагы фильмнар булачак. Дөресрәге, 2 нче фильмның беренче һәм икенче серияләре булачак ул. "Исә Болгар җилләре"нең тагын бер үзенчәлеге шунда, һәр фильм үзенә аерым, һәр фильмны аерым-аерым күрсәтеп була. Һәр тарихи катламны, һәр чорны аерым күрсәтү шундый мөмкинлек тудыра.

– Гәрәй Әфәнде, моннан ун еллар элек, Мәскәүнең тузанлы архивларында "югалып" яткан беренче татар фильмы "Булат батыр"ны Казанга алып кайттылар. Әлеге фильм, "тавышсыз кино" булса да бик күпләрне тетрәндерде. Егерменче еллар ахырында ук туган татар киносының беренче карлыгачы, "Булат батыр" – ике сериядән торган, гаҗәеп катлаулы язмышларны чагылдырган, татар халкының милли азатлык көрәшен яктырткан бер фильм, трагедия жанрындагы фильм иде. Менә шул чакта да шактый бәхәсләр булып алды. Әйтик, фильмны иң элек телевидение аша күрсәтеп халыкка җиткерергәме, әллә кинотеатрларга, прокатка чыгарыргамы? Ул чакта әле халык кинотеатрларга йөри иде...

– Анысы шулай. Тик бүген без икенчерәк шартларда яшибез. Монда безгә дөнья кинемотографиясенең зур тәҗрибәсен истә тотарга туры киләчәк. Шуңа күрә, фильмны иң элек кинотеатрларга чыгарырга уйлыйбыз. Аны төшерү өчен дәүләт акчасын тотасы бит. Ләкин бу халыктан җыелган акчаны дәүләткә кайтару дигән сүз түгел, бу һич тә дөрес булмас иде. Әйтик, фильмны төшерүдә башка илләр дә катнашты. Без алар белән контракт төзибез. Мәсәлән, Италия белән шундый контракт бар. Без фильмның андый илләргә җибәреләчәк вариантларын эшлибез, аларда шул ил халыкларының тарихын купайтыбрак күрсәтәбез. Бу фильм белән гарәп илләре дә бик кызыксына. Монда бит Ибн Фадланның сәяхәте, Болгарның Ислам динен кабул итүе дә шактый киң яктыртыла. Төркия бездән шушы фильмның телевизион версиясен сорый. Без, бер үк вакытта, унике серияле телевизион версия дә эшлибез. Без моны берьюлы, бер үк күренешләр барышында төшерәбез – шул ук җиһазлар, шул ук халык, шул ук атрибутика. Кино варианты да, телевизион вариант та бергә төшерелү, үзегез беләсез, шактый очсызгарак төшә. Бу очракта шул безнең кинотасмалар гына күбрәк тотыла инде.

Аннан соң, Казагыстан, Төркмәнстан, Үзбәкстан кушылды хәзер бу эшкә. Менә тагын Башкортстан белән Чуашстан да кушылырга тора.

– Әгәр шулай икән, әгәр бу фильм чит илләрдә дә, башка тугандаш дәүләтләрдә дә сатып алына икән – ул үзен, һичшиксез, матди-матери-аль яктан да аклаячак. Ә инде аның татар халкы язмышында, аның рухын үстерүдә, дөньяга танытуда, дөрес тарихын күрсәтүдә булган әһәмиятен әйтеп тору да кирәкмидер! Ә бит акча юкка әрәм ителә, дигән фикерләр күпме йөрде. Фильмның үз вакытында финансланмавы турында да ишетеп тордык.

– Менә, быел беренче ике серияне күрсәтәбез, дидем бит әле. Без инде аны моннан ике ел элек үк күрсәтә алган булыр идек. Әнә шул финанс булмау сәбәпле, без моны эшли алмадык. Әйе, финанслау тоткарлык белән барды. Үзегез беләсез, кино төшерү өчен календарь план төзелә. Әйтик, кыш көне төшереләчәк кадрлар өчен акча җәйдән үк күчерелгән булу шарт. Чанаңны – җәйдән, арбаңны – кыштан ук әзерлә, диләрме әле? Менә шулай булмаганда, календарь план бозыла, эшлисе эшең соңара. Менә без дә ике елга соңга калдык, кичектек.



– Гәрәй әфәнде, безнең татар артистлары беренче тапкыр кинофильмда шулай күпләп уйный, катнаша. Бу – зур уңыш. Аларның үзләре өчен дә, безнең өчен дә. Ә менә чит ил артистларының катнашуы эшкә кыенлык кына китермиме?

– Кайчак безгә шулай дип әйтүчеләр бар: нишләп фильмда үзебезнең артистлар гына уйнамый, нигә урыс артистлары катнаша, диләр. Фильмда үз театрларыбыздан – Камал театрыннан, опера һәм балет театрыннан, Тинчурин исемендәге, Качалов исемендәге театрлардан 48 артист катнаша. Шәүкәт Биктимеров, Ренат Таҗетдин, Ренат Ибраһимов һәм башкалар, һәм башкалар. Барысының да исемен санап үтә алмыйм, үпкәләмәсеннәр, фильмда һәркайсы күренәчәк.

Ә инде бу фильмда урыс геройларын – урыс артистлары, итальяннарны – итальян артисты, татарларны татарлар уйный икән, бу бик тә табигый хәл дип саныйм мин. Алар сценарий буенча үз телләрендә сөйләшеп уйныйлар, соңыннан тәрҗемә сүзен генә яздырасы кала.

– Гәрәй әфәнде, бик күпләр әле бу фильмны төшерүдә-эшләүдә катнашучыларга үз рәхмәтен, ихлас рәхмәтен җиткерер дип ышанабыз. Ә Сезгә, үз чиратыбызда, шушы әңгәмә өчен рәхмәт әйтәбез. Һәм тагын шул: бу сөйләшүебез – Яңа ел алдыннан. Фильм төшерү мәшәкать-борчуларыннан, сөенеч-шатлыкларыннан тыш, узып барган ел нәрсәсе белән истәлекле булды, киләсе елда, алдагы елларда, яңа гасырда үзегезгә, кешеләргә, халкыбызга нинди теләкләр теләр идегез?

– Узган ел дигәннән, бу ел татар халкы өчен бик истәлекле ел булды бит әле: август аенда Конгресс узды, Казанга Кубрат ханның хәзинәсе кайтты. Кубрат хан безнең фильмда төп геройларның берсе бит.

Ә үземә килгәндә, миңа быел җәй 56 яшь тулды. Конгресс алдыннан, августта, безнең гаиләдә тагын бер татар артты – улым туды. Аңа Кубрат дип исем куштык. Ни өчен Кубрат (Гәрәй Рәхим бу урында көлеп куйды. – ред.), чөнки без малайны нәкъ менә Татар Конгрессына багышладык. Һәм нәкъ менә шул вакытта Кубрат ханның хәзинәсе кайтты безгә. Ә ул хәзинә бик зур бит.

– Анда сезнең улыгызның да өлеше бар булып чыга инде, болай булгач...

– Әйе! (Гәрәй Рәхим тагын елмаеп куя) 1998 елда улыма бер яшь тулачак. Кубрат хан хәзинәсеннән аның процент дәгъваларга хакы бар, мирас рәвешендә. Ә ул мираска әле тагын берничә фильм төшереп булачак.

Олы улым Давытка алты яшь тула. Анысы да бик зур вакыйга – мәктәпкә керә торган ел. Давыт – пәйгамбәр исеменнән алынган. Давыт дигән исем сигез халыкта бар: татарда, урыста, яһүдләрдә һәм башкаларда.

Аннан соң, минем әле кызым да бар. Ул – беренче хатынымнан. Кызым хәзерге хатынымнан бер яшькә өлкәнрәк, шуңа күрә аңа "әни" дип эндәшә алмый. Инде оныкларым да бар минем.

Тагын ниләр әйтим? Менә тагын бер шаяртуымны язып куегыз шунда, укучы аны дөрес аңлар дип уйлыйм. 1998 елда Югары Совет ирләргә берничә хатын белән торырга рөхсәт итә торган законны караячак. Гәрәй Рәхим бу турыда ни уйлый? Законнан файдаланырга исәп. 60 яшькә кадәр өлгерәм әле.

Ә Яңа елга, яңа гасырга теләкләр шул: саулык бирсен, иҗат бирсен Ходай. Үземә дә, башкаларга да. Мин үзем 1941 елда туган кеше. Әтине мин беренче мәртәбә биш яшем тулганда гына күрдем, кырык алтынчы елны. Әти сугышка китеп өч көн үткәч туганмын мин. Минем, шуңа күрә, туган көнемне үткәрәсе килми кайчак, үткәрмәдем дә. Әллә нинди каһәрле көннәр, сугыш башланган көннәргә туры килә бит. Шул иҗатым белән бәйле булган, юбилейга бәйле көннәр генә билгеләп үтелде инде. Шуңа күрә дә, иң элек тынычлык-иминлек телисем килә кешеләргә. Элек безне әллә каян чыгачак сугыш белән, "салкын сугыш" белән, Америка белән куркытып яшәделәр. Ә менә хәзер ул сугыш дигәннәре якын-тирәләрдә генә йөрүен аңладык. Ичкерия, Таҗикстан... Русиянең империячел сәясәте тудыра сугышларны. Шуңа мин яңа елларда халыкларга иң элек иминлек, таза тормыш, мул тормыш, афәтсез тормыш телим.

Әңгәмәне **Нияз АКМАЛ** һәм **Илһам ФӘЙЗЕРАХМАН** үткәрде.

● ***Гәрәй Рәхим – шаяннар-шуклар мәҗлесендә.***

● ***«Исә Болгар җилләре» фильмын төшерү күренешләре.***

Бер сорауга – бер җавап

Рәзим ВӘЛИУЛЛИН, шагыйрь һәм композитор, Әлмәт` язучылар оешмасы җитәкчесе:

– 1997 ел минем өчен зур иҗади күтәренкелек елы булды. Беренчедән, март аенда, үземә 55 яшь тулу уңаеннан, Әлмәттә зур иҗат кичәсе үтте. Анда бик күп профессиональ артистларыбыз, күренекле сәхнә осталарыбыз чыгыш ясады, минем хор, оркестр өчен язылган әсәрләрем, җыр һәм романсларым башкарылды, күп кенә шигырьләрем яңгырады. Ерак җирләрдән, чит илләрдән безне якын итеп килгән кунаклар да күп булды. Июнь аенда үзебезнең милли хәрәкәт, "Ватан" җәмгыяте, Әлмәт районы хакимияте белән берлектә төрек дусларыбызны, ә бераздан япун кунакларын колач җәеп каршы алдык, япун профессиональ музыкасы фестивален бер көне бездә үтте. Нәкъ менә шулчакны төрек һәм япун эшмәкәрләре, композиторлары һәм музыкантлары белән таныштык, дуслашып калырга насыйп булды. Июль аенда Төркиягә сәфәргә баргач, иҗади элемтәләрне тагын да ныгытырга тырыштым. Алар үзләре дә мине якты чырай белән каршы алдылар, хәттә "Уч төбендә кояш" исемле китабымның кулъязмасын нәшер итү өчен алып калдылар. Мин үзем дә бурычлы булып калмадым, мәшһүр япун шагыйре Исикава Токубокуның 400 шигырен татарчага тәрҗемәләп, китап итеп чыгаруга ирештем.

Гомумән, минем тормышым әдәбият-сәнгатькә, аеруча музыкага бик нык бәйле булды, үзем байтак кына җитди әсәрләр язып, Үткән ел Татарстан Композиторлар берлегенә кабул ителдем. Алай гына түгел, ел буена Әлмәттә Татарстан Композиторлар берлегенең бүлекчәсен ачу белән мәшгуль булдым.

Үткән елны җәмәгать эшләреннән дә читтә калмаска тырыштым, Татар халкының Милли Мәҗлес депутаты итеп сайлануым рухыма көч бирде.

1998 елны исә үзем башлаган эшләрне дәвам итәргә уйлыйм. Мәсәлән, гыйнвар аенда Әлмәттә зур чара – татар симфоник музыкасы көннәрен уздыру күздә тотыла. Аны үткәрүдә безгә мәгълүм "Рухият" фонды ярдәм итәр дип көтәбез.

Бу ел да музыка дөньясында олуг вакыйгаларга бай булыр кебек. Март аенда Казан һәм Әлмәттә узачак классик музыка фестивalenә 15ләп чит илдән, хосусән Америка, Англия, Франция, Япония, Польшадан мәртәбәле кунаклар килер, дип көтелә.

Мәгълүм булганча, 1998 ел ул әле Әлмәт язучылар оешмасы төзелүгә 35 ел туласы ел да. Бу тантананы Тукай көннәренә туры китереп үткәрергә ният бар.

Рамазан ае башланды

Гарәпләрдә бу айның баштагы исеме "туван" булган. Хәзрәте Исмәгыйль пәйгамбәр заманында Бәни Хариҗем дигән залим шаһ Мәккә-Мөкәррәмәне басып алу өчен яу белән килә һәм җиңелә. Көн шул хәтле эссе була, сугышчыларның аяк тиреләре пешеп кабара. Һәм сугышчылар арасын-
да шундый тәгъбир тарала: "Вә рамазан, вә рамазан, әхарака колүбәна билгатөши вәкыдамәна бил хәйри" (Ай-вай янды безнең йөрәкләребез сусамактан, аякларыбыз ком-таш эсселегеннән). Шушы вакыйгадан соң бу айны "рамазан" дип атый башлыйлар.

1 – ***ләүхел-мәхфүздән*** (кешеләргә дөньяда вакытта нинди эшләр булачагы, кешеләр ни эшләячәкләре турында язылган тактадан, ягъни язмыш тактасыннан) ***Коръән иңдерелгән көн.***

3 – ***Ибраһим пәйгамбәргә "Зиндәги"*** (тереклек, җанлылык, тормыш турындагы бүлек) ***иңдерелгән көн.***

Бу айның башыннан алып ахырынача бәйрәм. Мөселманнар ай буена бер-берсенә кунакка йөреп, Коръән укып, зиярәт кылып, изге гамәл өстендә үткәрергә тиешләр.

21 – ***Фәтхе Мәккә көне.***

25 – ***Кадер кичәсе.***

26 – ***Кадер кичәсе көне.***

Бу көн рәсүлебез Мөхәммәд Рамазан аеның ахыр дистәсенең бер так кичәсендә булыр, дигән.

Роза КОЖЕВНИКОВА, шагыйрә:

"Дога кылсам, тоям галәмне..."

Бу шигырьне мин урыс телендә язган идем. Аны татарчага 1991 елда шагыйрь Ләбиб Лерон тәрҗемә кылды һәм ул җыр булып әверелде. Дөресен әйткәндә, "Болгар" ансамбле ул чакта Бөтенрусия конкурсында катнашырга әзерләнде һәм аңа шәп-әйбәт җырлар кирәк иде. Шигырьгә көйне нәкъ менә шушы ансамбльнең яшь композиторы Язнур Гарипов язды. Мәскәүдә узган әлеге конкурста "Дога" җыры беренче урынга лаек булды. Ә аннан соң бу җырны Эльвира Розали да Алматыда узган халыкара бәйгедә – "Азия тавышы" бәйгесендә җырлады. Мин шул җыр белән һәм дә Юлбарыс елында тууым белән горурланам. Барча кешеләргә яңа көндә яңа бәхетләр теләп дога кылам...

Дога

"Бисмилла иррахман иррахим..." -
Тоепмы ниндидер көч барын,
Әйтәләр шул сихри тәкъбирне
Йокыга талганда кичләрен.

Шып-шыксыз, кап-кара төннәрдә
Сырхаулап ятканда өйдә мин,
Әнием тибрәтте бишекне:
"Бисмилла иррахман иррахим..."

Хәтерли борынгы заманнар:
Килгәндә куаныч, йә кайгы,
Айга шул сүзләрне пышылдап,
Ничәмә ирennәр ялварды...

Кайвакыт – ышанып йөрсәң дә
Юк, диеп гайре көч, илаһи -
Үзең дә сизмичә әйтәсең:
"Бисмилла иррахман иррахим..."

Кәҗәмөгезләр, сезнең өчен!

(22.12-20.01)

Бу билге белән Сатурн идарә итә. Ул Кәҗәмөгезләрдә алдан күрә белүчәнлекне, гамәлилекне, пакьлекне формалаштырган планета. Шул ук вакытта алар оялчан һәм үзләренең эчке дөньяларына башкаларны кертергә бик ашыкмыйлар.

Кәҗәмөгезләрдә тагын бик үк әйбәт булып бетмәгән сыйфатлар да бар: алар гомер буена меланхолия, тынычсызлык, ышанычсызлык белән көрәшәләр, тиз депрессиягә бирeләләр, сәламәтлекләре аз гына какшаса да, үлемнән куркалар, төшенкелеккә бирeләләр. Аларның шаянлыгын, балалардай көлү сәләтен шуңа юнәлтәсе иде дә бит. Нәкъ менә шул көлү Кәҗәмөгезнең меланхолиясенә каршы торырдай энергетик көч бирә.

Әлеге билгенең энергетик тозы – ачы фосфорлы кальций. Шуның бер тамчысы да Кәҗәмөгезнең физик хәлен яхшыртып җибәрә ала. Бу тоз аеруча кәбестәдә тупланган. Чи кәбестә ашау сәламәтлекне яхшырта. Йогурт, йомырка сарысы, грейпфрукт бу тозга шулай Кәҗәмөгез тәүлегенә кимендә 1,5 литр су эчәргә тиеш. Әгәр ул гади су икән, аны бары тик кайнатып, җәсмин өстәп, бал белән эчәргә кирәк.

Борычлы, ачы тәмләткечләр, керән, горчица, томатлардан Кәҗәмөгез сакланырга тиеш.

Яшәү энергиясен тәэмин итү өчен бу билгегә майсыз ит аксымы, эремчек, сыр таләп ителә.

Елына ике мәртәбә билегезгә һәм аякларыгызга массаж ясата алсагыз да бик шәп булыр иде.

Кәҗәмөгез спортта йөгерү, йөзү белән шөгыльләнә ала.

Айга бер мәртәбә чәчләрне кычыткан төнәтмәсе белән чайкау кирәк.

Кәҗәмөгезләрнең оешканлыгын һәм алдан күрә белүчәнлеген искә алсак, гаиләләрендә күңелле күтәренке рух та өстәсәләр, алар барлык авырлыкларны җиңеп чыгачак.

Мәхәббәттә Кәҗәмөгезләр кызыл шәрабка тиң. Картайган саен шәбрәк. Чөнки ул соң ачыла, әмма яратыру сәләтен картайгач та киметми. Бик күп "романнар" авторы булса да, зур авырлык белән гашыйк була. Күпләр ялгызы гына гомер кичерә. Ә аннары дистә еллар үзләре каршы торган нәрсәгә буйсыналар, тулысынча бирeләләр, ихластан ачылалар.

Кәҗәмөгезнең ташлары: оникс, хризопраз, агат. Аның төсләре барысы да карадан.

Кәҗәмөгез гыйнвар аенда Арыслан, Үлчәү белән яңа мөнәсәбәтләр урнаштыра, бәлки, бер-берсенә омтылу барлыкка килер. Ә Чаян, Укчы белән булган интим мөнәсәбәтләренә таркалу яный. Кәҗәмөгезнең Игезәкләр белән булган хисләре саклanса да, арада зур бәхәсләр куба.

Җырлаучы кедрлар сере

Юлбарыс, ниһаять, Себер тайгасында, кедр урманында яшәүче Анастасияне эзләп тапты һәм капыл гына сорау бирде.

– Син Тарзанмы әллә?

– Тарзан да, түгел дә, – диде урман гүзәле. – Мин әниемнең күкрәк сөтен имеп үскәнмен. Әтиемнең көчле куллары бишек булган. Алар яшьли үлгәч, бабам белән картәти тәрбияләде. Табигать, урман җәнлекләре, ерткыч хайваннар да чит күрмәде. Аю, бүре өннәре туган йортым булды, тиеннәр, күпме телим, шуның кадәр чикләвек җыеп китерделәр.

– Син кыргый җәнлекләр, балыклар, гөлләр, агачлар телләрен беләсең. Итальян, француз, немес, инглиз, татар телләрендә дә сөйләшәсең. Ә үзең мәктәптә бер класс та укымагансың.

– И, дустым, Табигатьтән бөегрәк укытучының булганы юк әле. Ә мин – Илаһи Табигать баласы.

– Шулай да нигә сез – туксаннан узган бабаң, йөз егермедән узган картәтиең һәм син – 27 яшьлек сылу – урманда яшисез, кышлык ризык та әзерләмисез. Кыш карыны озын вә ач, салкын җилләр исә, монда кешеләргә түгел ерткыч хайваннарга да бик кыен... Моның сәбәбе ни?

– Сәбәпсез яфрак та селкенми. Безнең нәсел гомер-гомергә, ничәмә-ничә гасырлар буена урманда яшәгән. Һәм Табигать минем ерак әби-бабаларыма бер-бер артлы үзенең серләрен ачкан. Кешеләр мәхәббәтеннән чыккан якты нур секунд эчендә галәмгә аша, яңадан җиргә кайтып, барча тереклек ияләренә тормыш бирә.

– Ә кеше ачулы булса?

– Ул чагында кара нурланыш чыга, ул галәмгә күтәрелә алмый, Җир эченә китә. Үзәктән сугыш, җир тетрәү, вулкан булып яңадан җир өстенә кайта.

Менә кедр. Кешеләр аны гади бер агач дип кенә беләләр. Көзен җыйнаулашып урманга киләләр дә, агачны тукмаклар белән кыйный-кыйный чикләвеген коеп җыеп китәләр. Ләкин күп нәрсәне белмиләр. Кедр – галәмнән килгән энергияне туплаучы резервуар ул. Ул үзенең миллионлаган энәләренә якты энергиянең барлык спектрларын туплый, аны саклый. Хаҗәте чыккач галәмгә, димәк, кешеләргә дә, барлык тереклек ияләренә кире кайтара, тормыш бирә.

Без шул кедр серләрен, аның тылсымлы көчен беләбез.

– Тайгада "җырлаучы" кедр бар, диләр, дөресме?

– Дөрес. Һәм без шундый кедр үстерәбез. "Җырлаучы" кедрлар бик сирәк очрый. Андый кедр космостан алган энергияне үзендә туплый да туплый, ә кире кайтармый. Биш йөз ел үткәч, яңгыравыклы тавыш чыгара – "җырлый" башлый, кешеләрдән үзендә тупланган энергияне алуны сорый. Өч ел "җырлый". Әгәр шул вакыт эчендә кешеләр аны кисеп, тупланган энергияне алмаса, егерме җиде ел буена аны үзендә яндыра да бик интегеп корып үлә.

– Әгәр кешеләр ул көчне алса?

– Ул чагында алар теләсә нинди авырудан терелә.

– Андый кедрлар тагын кайларда үсә?

– Геленджик тирәсендә 100 яшьлек кедр бар. Аны изге күңелле кеше – язучы Владимир Короленко утырткан.

– Рәхмәт, туганым. Сорауларым өчен гафу ит. Китмәгез сез урманнан. Нәни улыңны да үзең кебек итеп үстер. Җырчы кедрлар серен киләчәк буыннарга сөйләсен. Ә мин сезнең турыңдагы шушы китапны кешеләргә укырга бирермен, алар да җырлаучы кедр һәм башка бик күп могҗизалар белән танышыр.

* * *

Юлбарыс, Анастасия кулында изрәп йоклаган сабыйны ялап алды да, саубуллашып үз юлына китте.

ЙОЛДЫЗНАМӘ

(1-11 гыйнвар)

КУЧКАР (21.03-20.04). 3 гыйнвар көнне мөһим карарлар кабул итмәү хәерле. Ике бәхәсле көнегез бар: 4 һәм 10 гыйнвар. Акчагызны әрәмшәрәм итү дә ике көнгә туры килә – 6 һәм 11 гыйнвар. Нәрсәдер хәл итәргә тотынып, бәхәсләргә керергә ашыкмагыз. Ул сезнең өчен файдалы түгел. Сезне эшлекле элемтәләр (8 гыйнвар) һәм уйламаган, көтелмәгән очрашулар, сөенечле хәбәрләр, мавыктыргыч башлангычлар көтә. 9 гыйнвар көнне үзегезгә җан азыгы хәзерләгез. Серле көчләр сезгә ярдәмгә килер, язмышыгызда юл күрсәтер.

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04-21.05). Акчагызны, матди байлыгызны саклагыз. Кешеләрнең йомшак, ягымлы сүзенә ышанмагыз, бурычка бирмәгез, хәтта туганнарыгызга карата да таләпчәнлек күрсәтегез. 1, 2, 10 гыйнвар көнне чит кешеләргә ишек ачарга ашыкмагыз. Гомумән, бу көннәрдә өйдә саклык чаралары күрү хәерле. Юл йөргәндә, транспортта игътибарлы булыгыз, тәртип саклагыз, чөнки 3 гыйнвар көнне сәламәтлегегезгә зыян килү ихтималы бар. Гыйнвар башы сезнең өчен күп өлкәдә сакчыл, игътибарлы булуны таләп итә. 6, 8 гыйнварда җаныгыз теләгән эшләр белән шөгыльләнегез, рухи ихтыяҗыгызны үтәгез. Сезгә ул көнне гыйбадәтханә ишекләрен ачып керү, әрвахлар өчен хәер-сәдака бирү дә зыян итмәс. Атна ахырына кәефегез күтәрелер, эшләрегез уңга китәр.

ИГЕЗӘКЛӘР (22.05-21.06). Гыйнвар башы сезнең өчен бик уңышлы башлана. Сез үсеш кичерәсез, яңа эшләр башлыйсыз һәм шул хезмәттән матди керем аласыз. 4, 9 гыйнвар сезнең рухи тупланууыгызны таләп итәчәк. 6 гыйнварда күңелсез хәлләр булуы ихтимал. Сәламәтлек сагында уяулык таләп ителә. Алдан чара күрелгәндә авыруны, бәхетсезлекләрне булдырмый калырга мөмкин.

КЫСЛА (22.06-22.07). Яңа елның беренче көннәреннән акча әрәмшәрәм итүгә йөз тотасыз бугай. Сак булыгыз. (1, 7 гыйнварда финанслар белән уйлап эш итегез). 3, 4, 5, 6, 10, 11 гыйнвар көннәрендә сез иң бәхетле кешеләрнең берсе. Ул уңыш, хезмәттә үсеш, рухи канәгатьләнү китерә торган чаклар. 8, 9ы көнне юлда, транспортта саклык таләп ителә, сәламәтлек турында кайгыртучанлык күрсәтү кирәк. Илаһи көчләр сезгә ярдәмгә килә, тик аларны аңлый белү, акыл белән эш итү, гамәлгә ашыру сорала. Гомумән, гыйнвар ае сезнең өчен шәфкать, изгелек ае.

АРЫСЛАН (23.07-23.08). 1 гыйнвар сезнең өчен узган елның бәйрәм дәвамы булып тора әле, эшкә тотынудан файда юк, гаиләгез, балаларыгыз белән бергә булыгыз. 2, 3, 8, 11е сезнең өчен иң уңышлы көннәр. Эшлекле мөнәсәбәтләр, хезмәттәшлек, элемтәләр нәтиҗә бирми калмас. 4, 6, 7, 9, 10 гыйнварда сезнең бәхәскә керүегез, көтелмәгән начар вакыйгаларда, күңелсез хәлдә калу ихтималы зурдан. Бу көннәр сездән сабырлык, оешканлык таләп итә. Авырулардан, аеруча салкын тиюдән сакланыгыз. Рухи таянычны туганнарыгыздан, якыннарыгыздан эзләгез, алар төшенкелеккә бирелүдән саклап калыр.

КЫЗ (24.08-23.09). 1 гыйнвар көнне вакыйгаларның көтелмәгән юнәлеш алуы һәм сезгә шактый мәшәкать, борчылу китерүе ихтимал. 2, 3, 8, 10 гыйнвар сезнең ихтыяр көчегезне туплауны таләп итә. Әлбәттә кешеләргә карата ышанычыгыз киму куркынычы да бар. Бәхәсләр булуы да ихтимал. 5, 6, 11е сезнең өчен уңай көннәр. Бу көнне эшләрегез, сәфәрләрегез уң булыр, кылган гамәлләрегез сизелерлек нәтиҗә бирер.

ҮЛЧӘҮ (24.09-23.10). Тормышыгызда үзгәрешләр көтелә. Ул вакыйгалар бәхәсләр аша узарга мөмкин. Шуңа күрә дә эчке тойгыларыгыздан элек, мәсьәләнә аек акыл белән хәл кылу кирәк. Сезгә серле илаһи көчләр ярдәмгә килер, шул авазга колак салыгыз, ялгышмагыз. Сезне юллар көтә. Әмма 6 гыйнвар көнне юл йөргәндә, транспортта саклык күрү кирәк. 7 гыйнвар акча мәсьәләсендә игътибар таләп итәчәк.

ЧАЯН (24.10-22.11). Чаян үз-үзен белештермичә юлда, сәяхәттә йөрер, тик тормас, җан тынычлыгы күрмәс. 3, 7се көнне ул акча мәсьәләсендә югалту кичерә, финанска корылган килешүләре гамәлгә ашмый. Үзе алдауга сәләтле булган кебек, аны да сүз белән генә "тукландырып" калдыралар. Ул гадәттәгечә үзен генә хаклы саный, илаһи көчләр авазына, дуслары киңәшенә колак салмый, нәтиҗәдә күңелсез вакыйгаларга юлыга.

УКЧЫ (23.11-21.12). Яңа ел сездән эчке ресурсларыгызны тулы көчкә җигүне таләп итә һәм уңышка, эштә үсешкә, күтәрелешкә, даими хезмәттәшлеккә илтә. 3, 4, 5, 6, 8, 11е сезнең өчен уңышлы көннәр. Башлангычларыгыз гамәлгә ашар, нәтиҗә бирер, рухи канәгатьләнү кичерерсез. 7се көнне акча эшендә сак булыгыз. Югалту кичерүегез ихтимал.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12-20.01). Гыйнвар башы сезгә серле илаһи көчләрне юллый. Сез аларны игътибар белән тыңлагыз вә аңлагыз. Алар сезгә уңыш вәгъдә итә. Сез бу арада иң бәхетле кешеләрнең берсе. Эшлекле мөнәсәбәтләр урнаша, зур үсеш кичерәсез, байтак табыш керә. 8,10ы көнне бәхәсле хәлләргә юлыгуыгыз ихтимал. Сабырлык күрсәтегез, акыл белән эш итегез, яхшылыкның һәммә нәрсәдән өстенлеген онытмагыз. Мескен-бәхетсезләр өчен изгелек кылыгыз, гыйбадәтханәгә кереп, эчке кичерешләрегезне тәртипкә китерегез.

СУКОЯР (21.01-19.02). 3, 4, 6, 7, 10 гыйнвар сезнең өчен уңышлы көннәр. Эшләрегезне, мөһим проектларыгызны, коммерция мәсьәләләрен шул арада башлагыз. 10 гыйнвар көнне рухи ихтыяҗыгызны канәгатьләндерердәй изге башлангычлар белән шөгыльләнегез. Бу көнне серле көчләр сезгә юлдаш, ярдәмче, киңәшче. 2, 8 гыйнварда акча мәсьәләсе игътибар, сакчыллык таләп итә, чөнки югалту, урлату ихтималы бар. 1, 4 гыйнварда бәхәскә кермәскә тырышыгыз, үзегезне кулда тота белегез.

БАЛЫК (20.02-20.03). Яңа ел бәйрәме сезгә шактый зур акча чыгымнары китерә. 2, 5 гыйнвар көнне зур эшләргә тотынырга ярый. Атна ахырына сез көтелмәгән очрашулар, вакыйгалар, эшләр шаһиты булырсыз. Ул сезгә шатлык, уңай нәтиҗәләр бирер. Әлбәттә, төшенкелеккә бирелү өчен сәбәпләр дә туар. Әмма иң мөһиме 5 гыйнвар көнне сәламәтлек турында кайгыртучанлык күрсәтү кирәк булыр. Эштә, юлда, өйдә бәхетсезлекләрдән сакланыгыз. 8, 9ы көнне сез илаһи көчләр ихтыярында.

Гомергә – төрмәгә

Француз контрразведкасының ике хезмәткәрен һәм аларга мәгълүмат бирүче ливанлыны үтергән 48 яшьлек террорчы Рамирес Санчесны (Ильич, Карлос, Шакал кушаматлары бар) Франция суды гомерлек төрмәгә хөкем итте.Ильич исемле бу кеше башта Кубада, аннары СССРда Халыклар дуслыгы университетында укыган. (Начар укуы һәм тәртипсезлеге өчен университеттан чыгарылган). Бу суд утырышыннан соң Карлосны, элекке җинаятьләре өчен, берничә суд процессы көтә.

Үзенә үзе табут бүләк итә

Барнаул шәһәрендә (Алтай крае) берәү үзенең 55 яшьлек юбилее уңаеннан үзенә үзе агачтан эшләнгән табут бүләк итә. Ярар, итсен дә, ди. Ә бит ул "бүләген" бөтен күршеләре күз алдына – тимер рәшәткәле балконына чыгарып куя. Болай да яшәргә рәт калмаган заманда гел үлемне искә төшереп торучы табутны күреп эчләре пошкан күршеләр табут иясе өстеннән ЖКУга шикаять язалар. Комиссия килә. Табут иясе әйтә, табутның кешегә зыяны юк, аннары Русия ирләренең уртача яшисе гомер сызыгын ул инде үткән – бигайбә, янәсе. Зур гәүдәле, сәламәт, 1,5 центнер авырлыктагы бу кеше үләргә җыенмый. Комиссия дә бернинди чара күрә алмый. Урыс холкы менә шундый инде...

Җинаятьчел төркем тотылды

Воронежда милиция машина урлап сату белән шөгыльләнүче җинаятьчел төркемне кулга алды. Караклардан 10 урланган машина, бик күп запас детальләр табылган. Милициянең әйтүенчә, хәзер җинаятьчеләр урлаган машиналарның саны ачыклана. Җинаятьчеләрнең кулга алынмаганнарын эзләү бара.

("СР").

Шоферлар, сак булыгыз!

Казан-Чаллы юлында шоферларны талау белән шөгыльләнүче 3 җинаятьчегә суд алдында җавап тотарга туры килде. Коммерция йөкләрен йөртүче шоферлар төнге юлда ашханәдә ашап чыгарга булалар. Анда башка машиналар да тора. Ашап чыгуга шоферларны 3 "крутой егет" көтеп тора: юлда төнлә тыныч йөрү өчен йөзәр мең (һәр машинадан) акча таләп итәләр. Бу сөйләшүнең шаһиты – корал белән кизү торучы сакчы әңгәмәгә катнашып китә. Ул арада "крутой"ларның берсе сакчыга ата. Сакчы да ата башлый. Беренче ядрә һөҗүм итүче егеткә эләгә, ул шундук үлә. Икенче ядрә "крутой егет"нең җан җиренә килеп тия. Табиблар әйтүенчә, ядрә ирнең җенес органнарын өзеп ташлый. Яралы җинаятьче көчхәл белән машинага утырып кача һәм юлдагы ДАИ постында "Ашыгыч ярдәм" машинасы чакырта. Соңыннан милиция җинаятьчене шул пост буенча эзләп таба.

"Җенси хезмәт күрсәтү"

Чаллы гәзитләрендә "Танышу" рубрикасы астында ике мәгънәдә аңлашыла торган игъланнар даими басылып тора. Хәбәрчеләр хатлары буенча, Чаллыда проституция ачыктан-ачык диярлек бара. "Төнге күбәләкләр"нең иң югары бәяләрен бер сәгатькә 200 мең сум түлиләр. Милиция, әлеге "тәтәйләр"не тоткач, әхлак турында әңгәмә үткәрәләр. Ләкин ул әңгәмәләрнең файдасы юк – урам кызлары милициядән котылу белән, "эш урыннарына" ашыгалар.

Фатир өчен үлем

Казанда А.Зиядуллина югала. Туганнары милициягә мөрәҗәгать итеп эзләтә башлыйлар. Альбина өенә дә кайтмый, берничә көн эшкә дә чыкмый. Милиция шуны ачыклый: Альбинаны үз туганы Айдар үтергән булып чыга. Әниләре үлгәннән соң ике туган фатир бүлешә алмыйлар. Ямьсез ызгыш вакытында Айдар Альбинаны үтерә дә, эзне яшерү өчен сеңлесенең аякларын чабып өзә. Гәүдәсен соңыннан юк итмәкче була. Җинаятьче кулга алынды.

Кызыл балык бәласе

Мәскәүдә 62 яшьлек эчкече һәм садист 82 яшьлек әнисен кыйнап үтерә. Элекке фатирын сату шатлыгыннан ул әнисе фатирына уңышлы операцияне "юар" өчен аракы белән килә. Аракы беткәч, әнисен кибеткә җибәрә. Ике шешә аракы аласы урынга, карчык "закуска"га кызыл балык һәм бер шешә аракы алып кайта. Ачуы чыккан ир әнисен кыйный башлый. Кыйнау сәгать ярым бара, һәм ана карчык вафат була. Җинаятьче кулга алынды.

("МК").

"Дуңгыз" дигән өчен

Нимес полицайлары үзләрен хайван исеме белән атаганда бик нык хурланалар. Закон да алар ягында. 46 яшьлек бер автомобиль йөртүчене полицайга "дуңгыз" дигән өчен 400 маркага штрафка тартканнар. Ә икенче берәүгә, полицайга "сыер" дигәне өчен, 1000 марка штраф түләргә карар чыгарганнар. Ни гаҗәп, бәяләре төрлечә. Әллә аның күләме хайванның зурлыгына карап билгеләнә микән?..

Юлбарыс үче

Приморье краеның Пожарский районында Соболь бистәсе янындагы умарталыктан кайтып килгәндә аучы В.Марковка юлбарыс ташлана. Фаҗига булган урынга контроль-инспекция патруле төркеме килә. Алар ботарланган аучы янында ана юлбарысның кешеләрне күзәтеп торуын күрәләр.

Фаҗига булыр алдыннан урман кисүчеләр бу юлбарысны кечкенә баласы белән күргәннәр. Ерткыч баласы белән күргәннәр. Ерткыч җәрәхәтләнгән булган.Бу – В.Марков эше булса кирәк. Ул моңарчы да браконьерлыкта гаепләнгән булган. Бу юлы юлбарыс үзе аңардан үч алган.

Болай да була...

Воронежда саклык банкы янында була бу хәл. Ниндидер егетләр долларны сумнарга алыштырырга теләүчене куралар. Саклык банкыннан файдалырак алыштыру шартларында, әлбәттә. Валютачыларның берсе купюраны "тикшергәндә", күрше подъезддан бер төркем яшьләр килеп чыга да үзләрен эчке эшләр хезмәткәрләре дип таныштыра, акча алыштыручыларга үзләре белән милициягә барырга тәкъдим итә. Законсыз валюта операциясе ясаулары турында беркетмә төзергә кирәк, янәсе.

"Тотылган" җинаятьче чит ил купюрасын клиентка тоттыра да, үзе "милиционерлар" белән китеп бара. Бер минуттан, күз буяучылар үкчәләрен ялтыратканнан соң, акча алыштырырга теләүче айнып китә. Ни күрсен – кулына зур суммадагы банкнот урынына... бер доллар тоттырганнар.

("Труд").

Иң зур шеш

1991 елда АКШтагы Стэнфорд университеты хастаханәсенә күкәйлегенә 136,5 килограмм авырлыкта шеш үскән бер хатынны китерәләр. Операциядән соң 200 килограмм авырлыктагы пациент 74 килога кала. Бу – медицина дөньясында уңышлы кисеп ташланган иң зур шеш.

Казыкка кадалу

1989 елның июлендә Джулио Кастилло урамда дуслары белән бейсбол уйнаганда, аягы таеп китеп, чуен рәшәткәгә барып төшә. Рәшәткәнең казык кебек очлы тимере ияк астыннан кереп, авызыннан тишеп чыга. Бу бәлагә тарыган егет 90 минут, ягъни эретеп ябыштыру аппараты белән коткаручылар килгәнче, шушы хәлдә торырга мәҗбүр була. Аппарат белән рәшәткә тимерен кисеп алып, Джулионы хастаханәгә озаталар. Табиблар егетне көчхәл белән генә казыктан ычкындыралар.

Авырыйм, дип авырый

Ипохондрия – табибларны иң борчыган авыру. Барон Мюнгхаузенда ипохондриянең иң авыр варианты булган, диләр. Мондый авыру медиклардан һаман-һаман үзен тикшерүне, операция ясауны таләп итә. Бу мәсьәләдә Уильям Макилра дигән бәндә бигрәк тә аерылып тора. Ул 50 ел эчендә үзен 100 клиникада 400ләп операциягә дучар итә. Ниһаять, ул 1983 елда картлар йортында вафат була.

("Я – молодой").

Татар энциклопедиясе битләреннән

АЛИМБӘК Әхмәт Вәлиулла улы *(1896-1957) 1 нче татар укчылар бригадасын оештыручы. 1919-20 нче елларда Үзәк мөселман хәрби коллегиясендә остаз. 1920-21 нче елларда Бохара җөмһүриятендә хәрби күзәтүче. 1931 елдан Ташкент шәһәрендә фәнни педагогик эштә.*

АЛИМБӘКОВА Әминә Вәлиулла кызы *(1896-1938). Сембер губернасында үзе теләп . гаскәргә килүчеләрне теркәп оештыручы. 1918-19 елларда Сембер РКП шәһәр комитетында татар бүлеге мөдире. 1922 елдан фәнни-педагогик эштә. 1935 елдан Согуд Гарәбстанында табибә.*

АЛИШЕВ Сәлам Хатип улы *(1929 елда туган), тарих белгече. 1990 елдан тарих фәннәре докторы, 1991 елдан Тел, әдәбият һәм тарих институтының бүлек мөдире. 1996 елдан ТРның атказанган фән эшлеклесе.*

АЛКИН Абдуллатиф *(1817-1867), 1865-66 елларда Чистай төбәгендәге чукынган татарларны . мөселманлыкка күндерү эшләрен оештыручы. 1867 елда кулга алынып Турухан якларына җибәрелә, шуннан соңгы язмышы билгесез.*

АЛКИН Сәедгәрәй Шаһиәхмәт улы *(1867-1919), хокук белгече. "Иттифак" мөселманнар фиркасен оештыручы һәм аның җитәкчесе. 1894 елдан Казан хөкемдарлар палатасында адвокат. 1906 елдан "Иттифак" үзәк комитеты әгъзасы. 1905-1908 елларда "Казан мөхбире" гәзитенең рәсми мөхәррире. 1906 елдан 1 нче Дәүләт Думасы депутаты. Беренче бөтендөнья сугышы вакытында ярлы мөселманнарга ярдәм итү комитеты мөдире.*

АЛКИН Ильяс Сәедгәрәй улы *(1895-1937), милли азатлык көрәшчесе, икътисади география белгече. "Татар учагы" түгәрәге җитәкчесе. 1917-18 елларда Хәрби Шура рәисе, Милли Мәҗлес депутаты. Г.Шәрәф белән берлектә Идел-Урал штаты проектын төзи. 1918 елда Хәрби Шура тыелгач, Коммунистлар мәктәбе коллегиясе әгъзасы. 1919 елда Советлар ягына күчә. 1921 елдан Мәскәүдә фәнни-педагогик эштә. Икътисади географиягә багышланган хезмәтләр яза.*

АЛКИН Җанһир Сәедгәрәй улы *(1897-1919), милли азатлык хәрәкәте тарафдары. Петроградта "Татар учагы" түгәрәге эшендә катнаша. 1917 елда Хәрби Шураны оештыручы һәм аның җитәкчесе. Казанда чыгучы "Безнең тавыш" гәзитен нәшер итүчеләрдән берсе.*

АЛКИН Шәйхулла Сибгатулла улы *(1893-1918), язучы, милли азатлык хәрәкәте тарафдары. 1913-1917 елларда Мәскәү коммерция институтында укый һәм "Ил", "Ак юл" гәзитләре белән хезмәттәшлек итә. 1917 елда Милли Шура әгъзасы. Милли-мәдәни автономия нигезләрен өйрәнү коллегиясендә катнаша. 1917-18 елларда Милли Мәҗлес депутаты, милли фонд әгъзасы. Балалар өчен хикәяләр яза.*

АЛМАЕВ Мәхмүт Сираҗетдин улы *(1874-1907), язучы. 1902 елда басылган "Сиксән сигез фикер", 1906 елда "Талчукчылар китабы" авторы.*

Атналык манзара

Дүшәмбе

5 ГЫЙНВАР

"ТАТАРСТАН"

7.00-8.00 "Чулпан".
17.40 Балалар өчен "Тамчы".
18.10 "Бизнес TV" (R).
18.45 "Җиһан". Хәбәрләр.
19.00 "Замандаш" циклыннан. "Узганы сагындыра". Галимҗан Сафин.
19.30 "Соңгы мәхәббәт". Рестәм Зарипов җырлары.
19.45 Яңалыклар.
20.00 "Чишмәләр". Азнакай районы.
20.30 "Әлли-бәлли-бәү".
20.45 "Җиһан". Хәбәрләр.
21.00 "Ирек мәйданы". Информацион-аналитик программа.
21.45 Яңалыклар.
22.00 Камера музыкасы концерты. В.Моцарт. "Дивертисмент".
22.15 "Карт-баланш". /R/.

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 "Хәерле иртә".
9.00, 12.00, 15.00, 18.00, 1.30 Яңалыклар.
9.15, 18.20 "Роковое наследство".
10.00 Мультфильм.
10.20 "Могҗизалар кыры".
11.20 "Өй китапханәсе".
11.30, 19.35 "Көйне белегез!"
15.20 Мультсериал.
